А.Г. ЯХИН

Әдәбият

6

«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

А.Г. ЯХИН Әдәбият 6


МЕТАФОРА

ЭЧТӘЛЕК

А. Г. ЯХИН

Әдәбият

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
6 нчы сыйныфы өчен дәреслек

Яңадан эшләнгән өченче басма

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы
рөхсәте белән басыла

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2006

УДК 373.167.1 : 821.512.145*06
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Я 89

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

УКЫТУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Шушы дәреслек белән эшләү өчен, А. Г. Яхинның «6 нчы сыйныфта әдәбият дәресләре: Укытучылар өчен методик кулланма» дигән китабы ирекле сатуга чыгарыла.

«Мәгариф» нәшрияты чыгарган методик кулланмаларны сатып алу өчен, түбәндәге адрес белән мөрәҗәгать итегез:

420111. Казан шәһәре, Бауман урамы, 19. «Мәгариф» нәшрияты.
Телефоннар: 292-60-19, 292-39-14.

Яхин А. Г.

Я 89 Әдәбият : Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 6 нчы с-фы өчен д-лек / А. Г. Яхин.— Яңадан эшләнгән өченче басма.— Казан : Мәгариф, 2006.— 255 б.: рәс. б-н.
ISBN 5-7761-1548-5

ISBN 5-7761-1548-5

© «Мәгариф» нәшрияты, үзгәрешләр белән, 2006
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2006

ӘДӘБИ ТӨРЛӘРГӘ АНАЛИЗ ЯСАУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

КЕРЕШ

Быелгы уку елында өйрәнәсе төп темага ачыклык кертик. Әдәби төрләр дип без нәрсәләрне атыйбыз?

Әдәби әсәрләр төрле-төрле була. Ләкин аларның барысына да хас уртак сыйфатлары бар. Әсәрләрнең берише безгә гыйбрәтле вакыйга тәкъдим итә:

— И мине яратып укучы шәкертләр! Безне укыгыз да уйланыгыз! Яманнардан гыйбрәт алыгыз, яхшыларга охшарга тырышыгыз! — дип киңәш бирә. Андый әсәрләргә **мәсәл** диләр.

Күләме ягыннан бик кыска булса да, тирән мәгънә белдергән матур әсәрләрне **мәкаль** дип атыйлар. Мәкальләр дә безгә үгет-нәсыйхәт бирергә яраталар.

Әсәрләрнең берише хыял дөньясына алып керә, тылсымнары белән сокландыра. Андый әсәрләр безне кызыктыралар:

— Бездәге дөньяның читен генә күрсәгез дә, аргы ягына чыкмый торып, кулыгыздан китап төшмәячәк,— диләр. Мондый әсәрләрне **экиятләр** дип атыйлар.

Ә кайбер әсәрләр укучыга:

— Безнең эчебез тулы хис. Укыгыз, без сезне искиткеч бай күңел дөньясы белән таныштырырбыз. Шагыйрьләр күңелендәге байлык сезгә дә күчәр. Ярдәмгә мохтаҗларны кызганырга, башкалар бәхетен күреп шатланырга өйрәнерсез,— диләр.

Бу төр әсәрләрне **лирик шигырьләр** диләр.

Шул рәвешле, охшаш әсәрләрне төркемнәргә җыя торгач, романнар, повестьлар, комедияләр, трагедияләр, балладалар һ. б. барлыкка килгән. Бу төркемнәргә уртак исем дә уйлап тапканнар: әдәби әсәрләр, **жанр-жанр булып, төркемнәргә җыела** дигәннәр.

Тора-бара жанрларның үз араларында да охшаш сыйфатлары барлыгы беленә. Мәсәлән, лирик шигырь, поэма, баллада кебек жанр әсәрләре сүзләрне рифмалаштырып иҗат ителгән. Ә драма, трагедия, мелодрама, комедия жанрлары исә сәхнәдә уйнау өчен җайлаштырылган. Галимнәр охшаш жанрларны, берләштереп, өч төркемгә бүлгәннәр. Һәм аларга әдәбиятның **тезмә, чәчмә, драма** төрләре дип исемнәр биргәннәр. Аннары, берничә гасыр уйланганнан соң, **юмор-сатира** төрен дә кушыйкмы дип бәхәсләшә башлаганнар. Әле дә бәхәсләшәләр.

Быелгы уку елында сез әнә шул зур төркемнәрне өйрәнәчәксез. 6 нчы сыйныфта да төп эшебез әсәрләргә анализ ясау булачак. Ләкин анализны әдәби төркемнәр үзенчәлеген истә тотып ясаячакбыз.

Бирем

Китабыгызга карамыйча, берничә жанр исемен һәм әдәбият төрләрен дәфтәрләрегезгә язып куегыз. Әдәбият төрләрен сез бөтенлек итеп өйрәнәчәксез.

Бөтенлек

Бөтенлек төшенчәсен алдагы сыйныфларда өйрәнгән идек. Бу төшенчәгә тагын бер кат ачыклык кертик. Бөтенлек безгә адым саен очрый. Кар яугач, чаңгы шуарга чыктыгыз, ди. Чаңгыны аяк киеменә беркетеп, кулыгызга таяклар алу белән, сез чаңгычы буласыз. Өч өлешнең бөтенлеккә әйләнүен сизми дә каласыз.

Сез шундый тиз шуасыз, хәтта юыртып барган җигүле атны да узып киттегез, ди. Җигүле атның бөтенлек булуына игътибар да итмәдегез. Сезнең алда чана да, ат та, чанада утырган кеше дә түгел, ә тәялгән олау иде бит.

Олау шул өлешләрнең бәйләнешендә генә барлыкка килә. Өлешләрнең кайсын гына алсагыз да, олау олау булудан туктый. Әнә нинди кызык күренеш ул бөтенлек.

Менә сез арып-талып өегезгә кайттыгыз. Әтиегез, әниегез, сеңлегез, абыегыз, әбиегез, бергәләп чәй

эчәргә дип, сезне көтеп утыралар, ди. Монда да искиткеч матур бәйләнеш — туганлык бәйләнеше бар. Ә туганлык бәйләнеше ул — мәхәббәт бәйләнеше. Сез барыгыз да бер-берегезне яратасыз. Хәтта үсеп җитеп, төрлегез төрле якка таралсагыз да, мәхәббәт хисе сезне барыбер бербөтен гаилә итеп саклап торачак. Сезнең гаиләдә балалар, өлкәннәр һәм картлар да бар бит. Җитмәсә әле, гаилә ирләр белән хатын кызларга да аерыла. Ләкин мәхәббәт аларны барыбер бербөтен тату гаилә итеп җыя. Хәзер инде сез өстәл артында чәй эчеп утыручы туганнар гына түгел, ә бербөтен гаилә. Гаилә ул — иң бөтен җәмгыять.

Без бөтенлекнең мөһим бер сыйфатын белдек. Ул бертөсле өлешләрне кушу гына түгел икән. Шырпы кабына бер-берсенә охшаган бик күп шырпы тутырылган. Алар, анда тип-тигез булып ятсалар да, яңа эчтәлек тудырмыйлар. Шырпылар гына булып калалар.

Төрле, хәтта капма-каршы өлешләр бәйләнеше генә яңа эчтәлек тудыра ала. **Бөтенлек** дип шундый бәйләнешләрне атыйлар.

Җиңел машинаны башта берәү уйлап чыгара. Икенче кеше вак-вак өлешләрен җыеп, гайка, болтлар белән беркетеп куя. Машина бөтенлеккә әйләнде. Йөргәндә аның барлык өлешләре дә эшли. Бер генә тәгәрмәчен алып ташласаң да бармый. Шуңа күрә без машинаны да бөтенлек дибез. Ләкин аны белү өчен, сүтелгән хәлдә, һәр өлешен аерым-аерым өйрәнергә, аларның урынын, башка өлешләр белән бәйләнешен күрергә кирәк.

Әдәби әсәр эчтәлеген табу өчен дә, машинаны сүтеп караган кебек сүтеп, эчендәге өлешләрне, алар арасындагы бәйләнешләрне өйрәнергә кирәк була. Әсәрне сүтеп тикшерүгә **анализ ясау** диләр.

Әдәби әсәр дә бөтенлек. Ул да өлешләрдән төзелә. Аның өлешләре — төрле предметлар, күренешләр, вакыйгалар, капма-каршы фикерләр, хисләр. Алар да, үзара бәйләнешкә кереп, өр яңа эчтәлек тудыралар.

Бөек шагыйрь Һади Такташ сүзләрен искә төшерик:

«Әсәрдә бер генә вакыйганы да, бер генә образны да әсәрнең төп идеясен җанландыруга хезмәт итмәгән хәлдә кертмәскә, бер генә образны да «безработный» калдырмаска кирәк».

Димәк, бөтенлек эченә кергән өлешләр бар да эшли, бар да яңа мәгънә тудыруда катнаша.

Матур әсәрләрнең эчтәлеген аңлап уку — үзе яшәү бит ул. Бервакытта да күрә алмаячак вакыйгалар эчендә йөрү, ишетә алмаячак сүзләрне ишетү, ә иң мөһиме, кичерә алмаган хисләрне кичерү нинди рәхәт. Ләкин бу бәхеткә өлешләрне бөтен итеп күрә алганда гына ирешеп була.

5 НЧЕ СЫЙНЫФТА ӨЙРӘНГӘННӘРНЕ ИСКӘ ТӨШЕРҮ

ӨЛЕШЛӘРНЕ БӨТЕН ИТҮЧЕ СҮЗЛӘР

«Җирнең уртасы кайда?» диелә табышмакта. Без Җир шары турында уйлыйбыз, чөнки «җир» сүзенең эчтәлеген күз алдында тотабыз. Ә табышмак бу сүзнең үзен дә предмет итеп карый. «Җир» сүзенең уртасын эзләтә. Ул — «и» хәрефе, ди.

Сораулар

1. Түбәндәге табышмакларда каршылык ничек ясалган?

а) Тыкрык башында ни бар?

ә) «Без»дә бар, «сез»дә бар, «ил»дә юк. Нәрсә бар? Нәрсә юк?

Шәүкәт Галиев

Безнең безләр

Без безсез яшәмибез,
Безсез без эшләмибез,—
Итекче без өчебез,
Өчебезгә — ике без.

Бүлешмибез безне без,
Безсез калгач беребез,
Без бирәбез аңа без;
Икебез без эшлибез,

Без көтә өченчебез —
Юк безнең өченче без.
Һәм киләбез сезгә без,
Сез бирегез безгә без!

Бирем

«Без» сүзе урынына «үзебез» сүзен куеп, ә эш коралы безне «энә» сүзе белән алмаштырып, шигырьне яңадан язып карагыз. Әдәби әсәр килеп чыкмый. Ни өчен?

Фәннур Сафин

Өлге

Бәхәс чыкты шулай беркөн!
Кем елдам да кем өлгер?
Шушы бәхәс ачып бирер:
Кем арада бердәнбер?

Хәсән әйтте:
— Билгеле бит,
Иң өлгере — мин — Хәсән!
Йөгереп мин куянны да
Тота алам теләсәм!

Айсылу сүзгә кушылды:
— Хәсән, син өлгермени?
Укуыңда өлгермәгәч,
Син безгә өлгемени?

Сорау һәм биремнәр

1. Хәсән кебек мактанчык малай турында сез ничек язар идегез? Үзегезнең бәяне шигырьдәге бәя белән чагыштырыгыз. Аермада автор табышын күрерсез.
2. Әсәрне икегә бүлүче сүзне табыгыз. Ничек бүлүен аңлатыгыз.

Хәсән Туфан

Зәйтүн җиргә бөгелгән

(Өзек)

Зәйтүн җиргә бөгелгән,
Чәчәк җиңел түгелдән.
Безнең хәл дә аермасыз
Җирнең шушы гөленнән.

Саубуллашыйм гөл белән,
Сибелә чәчәк җил белән.
Бер күрергә тилмергәннәр
Бер без түгел — ил белән.

Биремнәр

1. Шигырьне ике өлешкә бүлегез.
2. Өлешләрдә катнашучыларның сыйфатларын дәфтәрләрегезгә язып куегыз.
3. Төп өлешне табып, аңа икенче өлеш сыйфатларын өстәгез.
4. Шигырьнең эчтәлеген сөйләп бирегез.

Ә хәзер үзегез иҗади фикерләгез

Сүзләрдә икешәр, хәтта өчәр эчтәлек булырга мөмкин. Әйдәгез шул эчтәлекләрне каршылыкка китерик. Әдипләр шулай эшлиләр бит.

Түбәндәге сүзләрнең берсен файдаланып, каршылык тудырып, кыска гына әсәр языгыз.

Сүзләр. *Җәен, тиен, утыртты, тарта, сый, тел, сыер, эт, кит, май, ис килә, ис китә, казан, бәйли, кара, булмә, көту, көл, сый, килде, китте* һ. б.

БӘЙЛӘНЕШ

Әсәр эчендәге бәйләнешләр күзгә күренмиләр. Укучы бәйләнешне күрми, ләкин таба ала. Мәсәлән, охшашлык бәйләнешенә бер мисал китерик:

Тәрәзә төбе асылташ,
Фирәзә белән аралаш;
Бармагың камыш, йөзең кояш,
Акылларың камил, үзең яшь.

Халык җырында сурәтләнгән асылташ матурлыгы белән берәүнең яраткан кешесенә булган мәхәббәте арасында бернинди дә бәйләнеш юк кебек. Алар бары тик янәшә торалар гына. Ләкин янәшәлек тә бәйләнеш. Уйлап карыйк әле: асылташ һәм берәүнең гыйшкы төшкән кыз — икесе дә матурлар. Димәк, алар арасында охшашлык бәйләнеше бар. Бу бәйләнешне без метафора (баштагы ике юл) аша таптык. Егет яраткан кызын асылташ матурлыгына тиңли.

Халык иҗаты әсәрләренең иң кыска жанры булган мәкальләргә игътибар итик. Мәсәлән, «Сөтнең — сөзмәсе, сүзнең кыскасы яхшы» мәкален алыйк. Мәкальне, сөт һәм сүз турында дип, ике өлешкә бүләбез. Ләкин мәкальне уйлап табучы аларны янәшә куйган. Бербөтен әсәр иткән. Автор безгә сөт һәм сүз өлешләре арасындагы бәйләнешне табарга куша.

Беренче өлештә сөтнең, ә икенче өлештә кешенең мөһим сыйфатлары мактала. Хәзер ике өлешне бер җөмлә итеп языйк: *Сөтнең сөзмәсе сөттән яхшырак булган кебек, сүзнең кыскасы озын сүздән яхшырак.*

Нәтиҗә ясар өчен, уйны эшкә җигик. Димәк, мәкаль сөт турында түгел, ә күп сөйләүче кеше турында.

Бирем

«Бауның — озыны, сүзнең кыскасы яхшы» мәкалендә каршылык бар кебек (озыны да яхшы, кыскасы да яхшы). Ләкин ул барыбер бөтенлек. Шуны исбат итегез.

Габдулла Тукай

Туган тел

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы.

Иң элек бу тел белән әнкәм бишектә көйләгән,
Аннары төннәр буе әбкәм хикәят сөйләгән.

И туган тел! Һәрвакытта ярдәмең берлән синең,
Кечкенәдән аңлашылган шатлыгым, кайгым минем.

И туган тел! Синдә булган иң элек кыйлган догам:
Ярлыкагыл[1], дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, Ходам!

Сораулар һәм биремнәр

1. Беренче икеюллык строфаны бер тапкыр уку белән истә калдырырга тырышыгыз. Китабыгызны ябып, эчтән генә үзегезгә сөйләгез.
Беренче юлда ни турында әйтелә? Икенче юлда ни турында әйтелә? Икесе бергә ни турында?
Җавапларыгызны түбәндәге аңлатмага күз салмыйча табыгыз. Аннан соң үзегезнең уйларыгызны аңлатмадагы җаваплар белән чагыштырыгыз.

Аңлатма

Беренче юл лирик геройның (бу юлы «авторның» дию дә дөрес булыр) туган телгә мәхәббәте турында. Ничек белдек? Шигырьне дөрес һәм оста итеп сөйләгәндә, бу юлда авторның туган теленә мәхәббәте ятуын үзебез дә тоябыз. Ләкин безгә шуны исбат итәргә кирәк.

[1] Ярлыкагыл — кимчелекләрне кичер дип үтенү.

Болай исбат итәбез. Габдулла Тукай үзенең хисен тел сыйфатларын кабатлау аша чагылдыра. Телнең гүзәллеген белдерүче «туган» һәм «матур» сыйфатлары бер-берсен көчәйтеп киләләр.

Габдулла Тукай, өстәвенә, «и» кисәкчәсен дә кабатлый. Ә кисәкчәләрнең төп вазифалары авторның хисен көчәйтү булуын без инде беләбез. Юл ахырындагы өндәү билгесе хиснең югары дәрәҗәсен тагын да арттыра төшә. Әгәр шигырьнең беренче юлын сәнгать алымнарыннан арындырсак, «минем туган телем матур, чөнки ул ата-анам теле» кебек хиссез гап-гади хәбәр булыр иде.

Бирем

Икенче юлны да, бер тапкыр уку белән, хәтерегездә калдырырга тырышыгыз. Ятлагач, беренче юл белән кушып сөйләгез.

Хәзер икенче юлның эчтәлеген табыйк. Монда телнең тагын бер матур сыйфаты әйтелә. Татар теле мине күп нәрсәгә өйрәтте, ди Габдулла Тукай. Бу юлда хис күренми кебек. Ләкин шагыйрь строфаның ике юлын, рифма һәм ритм белән бәйләп, көйгә салган. Шушы бер генә строфаны кычкырып укысагыз да, көй белән укуыгызны үзегез дә сизми калырсыз.

Уртак көй беренче юлдагы хисне икенчесенә дә күчерде. Ничек күчмәсен, бу юл туган телнең матур сыйфатларына тагын бер сыйфат өстәде бит. Шагыйрь туган телне яраттыра торган тагын бер сәбәп әйтте: күп нәрсәгә өйрәтте, диде.

Аңлатманы укыдыгыз. Инде җавапларыгызның кимчелеген табыгыз. Танышуны дәвам итик.

Икенче строфаны да шул рәвешле өйрәник.

Бу строфаның беренче строфа белән тыгыз бәйләнешен эзлисе дә юк — күренеп тора. Ул беренче строфадагы «күп нәрсә белдем» сүзләрен ачыклап килә. Автор туган теле аркылы ниләр белгән соң? Әнисе, җырлый-җырлый, нәни шагыйрьгә туган телен өйрәткән.

Нәтиҗә ясыйк: туган тел шагыйрь өчен, беренче чиратта, әнисе өйрәткән сүзләр һәм җөмләләр. Бу сүзләргә Габдулла Тукай әнисенең улына булган мәхәббәт җылысы да салынган. Чөнки әнисе ул сүзләрне, көйли-көйли, улына җырлаган.

Туган телдә шулай ук шагыйрь әбисенең оныгына карата мәхәббәте дә сакланган. Әбисе аны, экиятләр сөйли-сөйли, сәнгать әсәрләре белән таныштырган бит.

Нинди матур шигырь юллары! Туган телдә һәркайсыбызның әнисе, әбисе калдырган мәхәббәт җылысы яши, ди Габдулла Тукай.

Биремнәр

1. Өченче, дүртенче строфаларны да, шул рәвешле ятлап, баштагылары белән кушып, алдагы дәрестә сөйләрсез.
2. Туган тел Тукайга ничек ярдәм иткән? Авыр сорау. Бу сорауга җавапны башта үзегез эзләгез. Безнең җавапны соңрак укырсыз.

Җавап. Габдулла Тукай кечкенәдән шигырь язган. Бар кайгысын, шатлыгын шигырьләре белән сөйләп биргән. Димәк, Габдулла Тукайны шагыйрь иткән дә туган тел икән. Менә ни өчен яраткан ул туган телне!

Нәтиҗә ясыйк: строфаларның һәркайсында шагыйрь туган телне ни өчен яратуы турында яза. Башкача әйтсәк, строфа саен шатлык хисенең сәбәбен күрәбез. Сәбәпләр кабатланган саен, хис дәрәҗәсе артканнан-арта бара. Димәк, шигырь Тукайның туган телгә булган чиксез мәхәббәте турында.

Ләкин сәнгать әсәренең сере дә шунда: шагыйрь үз хисе турында яза, ә без, «мине дә әнием шулай көйләп тирбәткән, әбием экиятләр сөйләп үстерде, мин дә әтигә-әнигә яхшылык кына телим» дип, әсәрне үз хисебез белән баетабыз.

Габдулла Тукайның язмышы безгә яхшы таныш. Иҗат итү аның өчен бердәнбер юаныч булган. Шуңа күрә менә шундый шигырь яза алган япь-яшь шагыйрьнең чиксез талантына сокланабыз. Язмышын күз алдына китереп, аны кызганабыз. Туган телне яратырга өйрәтүе өчен рәхмәтебезне белдерәбез. Рәхмәт сиңа, шагыйрь, бездә шундый матур хисләр уяткан өчен!

Хәсән Туфан

Туган тел

(Өзек)

Бу дөньяның төсен, ямен, зәүкын[1]
Кем аркылы, ничек белдем мин?
Бишектә үк мине өйрәтүчем,
Туган телем — бәгърем, син ул, син!

Рәхмәт сиңа, рәхмәт, тәрбиячем,
Һәрнәрсәнең асыл мәгънәсен
Син аңлаттың миңа, туган телем,
Син өйрәттең миңа һәммәсен.

Бирем

Туган телне шагыйрь ни өчен ярата? Мәхәббәт хисенең ике сәбәбен табыгыз.

ПРЕДМЕТ. СЫЙФАТ. ВАКЫЙГА

Үткән сыйныфларда өйрәнгәннәрне искә төшерик.

Бәйләнешкә керә торган якларның иң гадие — **предмет.** Аның үз эчендә дә бәйләнешләр күп, һәм ул башка бер предмет белән дә бәйләнешкә керә ала.

Галимнәр, уйларга җиңел булсын өчен, күзгә күренә торган барлык нәрсәне **предмет** дип бер генә исем белән йөртәләр.

Балта, агач, машина, орчык, сарык, йорт, китап, балык — болар барысы да предметлар. Күрдегезме нинди киң күңелле ул предмет! Кеп-кечкенә бөҗәкне, бернигә ярамаган чүпне, айны, хайваннарны, хәтта җирне дә үз эченә сыйдыра. Болар бар да минем патшалыкта яшиләр, бар да предметлар, ди.

Предметларның төсен, катылыгын, кыяфәтен, зурлыгын һәм башка теләсә кайсы ягын аның **сыйфатлары** диләр. Әбиебез бәйләгән бияләй сыйфатларын

[1] Зәүкын — матурлыкны тоя белү.

санап чыгыйк. Ул — йон, эрләнгән йон, бәйләнгән, җылы, йомшак, бармакчасы бар. Бияләй әнә шул сыйфатлардан гыйбарәт. Предметның сыйфатлары күп, шул сыйфатлар, билгеле бер бәйләнешкә кергәч, предметка әйләнәләр.

Нәтиҗә ясыйк: бер сыйфат — предметның өлеше, күп сыйфат һәм алар арасындагы бәйләнеш предмет үзе була.

Сыйфатсыз бәйләнеш тә була алмый.

Бер предметның сыйфатлары икенче бер предмет сыйфатлары белән охшаш булса, бу предметлар арасында охшашлык бәйләнеше бар, диләр.

Предметларны гомумиләштерү өчен, аларның ничә сыйфаты охшарга тиеш?

Күп сыйфатлары арасыннан иң әһәмиятлеләре охшаса, аларны гомумиләштерү дөрес була.

Габдулла Тукай

Кечкенә генә бер көйле хикәя

(Өзек)

Бар иде бездә Сафи атлы кеше,
Бик юаш, бичара, беркатлы кеше.

Тире сатып, җон сатып чыккан теше,—
Бар эше шул, юк кеше берлән эше.

Тиргәше юк, сугышы юк, төртеше;
Рәнҗеми, таякласа да бер кеше.

Дине таза, бик каты тәкъва[1] кеше,
Дикъкате бар, диндә бик әкъва[2] кеше.

Бик матур корылмыш иде тормышы,
Яхшы иде, бик чибәр көн күрмеше.

---

[1] Тәкъва — изге.
[2] Әкъва — өстен, көчле.

Бирем

Шигырьне укыгыз. Сафи атлы кешенең барлык сыйфатларын үз сүзләрегез белән әйтегез. Габдулла Тукай аларны гомумиләштергән. Ничек гомумиләштергән?

Предметларның хәрәкәте вакыйга була.

Сез мәктәпкә киттегез, ди. Юлда туктап күгәрчен ашатсагыз, вакыйга тәмамланмаган була, чөнки максатыгыз күгәрчен ашату түгел иде. Сыйныф бүлмәсенә кереп парта артына утырсагыз, максатыгызга ирештегез дигән сүз. Димәк, хәрәкәт тәмамланды.

Карлыгач белән Чыпчык

(Төрек халык әкияте)

Карлыгач белән Чыпчык ояларын бер үк йорт кыегына ясаганнар. Чыпчык түбә калае астындагы бер ярыкка урнашкан. Анда алдан да, арттан да җил искән. Ул шунда йомыркалар салган. Ләкин бер елны да балалар үстерә алмаган. Әле шук малайлар оясыннан йомыркаларын алганнар, әле Чыпчык балаларын песи ташып юк иткән.

Күршедәге Карлыгач балалары исә ел да, исән-сау үсеп, очар кош булганнар. Аналары аларны ашаткан, очарга, сайрарга өйрәткән.

Чыпчык, Карлыгачның тату гаиләсен күреп: «Нинди бәхетле гаилә!» — дип көнләшкән.

— Көнләшмә. Үзең гаепле,— дип җавап биргән аңа Карлыгач.— Ояңны минеке кебек нык итеп ясасаң, бәләкәчләреңә малайлар да, песиләр дә тимәсләр иде.

— Син бит оя ясауның серен беләсең. Мине дә үзеңнеке кебек ышанычлы оя ясарга өйрәт әле,— дип үтенгән Чыпчык.

— Ояны акыл белән ясарга кирәк. Хәер бер дә кыен эш түгел ул оя ясау. Әйдә оч минем арттан, күрсәтәм,— дигән Карлыгач.

Икесе дә күлгә таба очып киткәннәр.

— Мин ни эшләгәнне күзәт. Син дә томшыгыңа балчык кап,— дигән Карлыгач.

— Чык-чырык! Чыннан да бер кыенлыгы да юк икән ич монын,— дигән Чыпчык.

Карлыгач дәшмәгән. Өй кыегына очып кергән дә балчыгын ябыштырып куйган.

— Син дә шулай ит,— дип киңәш биргән Карлыгач.

— Күрәм, күрәм. Бик җиңел эш икән бит ул ышанычлы оя ясау. Мин тагын синең ояңда акыл җитмәслек сер бар дип торам. Болай итеп теләсә кем ябыштыра ала бит. Кыстама, мин мондый юк-бар эш эшләмим,— дигән Чыпчык.

Карлыгач күлдән балчык ташыган да ташыган, аннары салам артыннан очкан. Оясын ул салам белән балчык кушып ябыштырган.

— Син дә шулай эшлә,— дип өйрәткән Карлыгач Чыпчыкны.— Башта стенага балчык ябыштыр, балчык өстенә салам урнаштыр. Тагын балчык ябыштыр, өстенә тагын бер кат салам урнаштыр. Чыдамлы, нык, матур оя килеп чыксын.

— Беләм, беләм, бер хәйләсе дә юк икән,— дигән Чыпчык.

— Белүен беләсең. Ләкин белем белән генә оя корып булмый шул. Аның өчен эшләргә дә кирәк. Минем кебек эшләргә күнекмәсәң, нәни чыпчыкларыңны мәңге үстерә алмассың,— дигән Карлыгач.

Биремнәр

1. Әкияттә Карлыгач һәм Чыпчык белән бәйле ике вакыйга бар. Шул вакыйгаларны сөйләгез.
2. Карлыгач сыйфатларын барлыйк. Карлыгач эшнең рәтен белә: оясын нык, җылы итеп кора, песиләрдән, юньсез малайлардан яшерә. Ул тырыш. Армый-талмый эшли. Игелекле, Чыпчыкны кызгана. Аңа ярдәм итә.
Карлыгач сыйфатларын гомумиләштерүче сүзне табыгыз. Өлешнең исеме шул булыр.
Чыпчык сыйфатларын әйтегез. Аның да барлык сыйфатларын җыеп торучы сүзне уйлап табыгыз.
3. Әкият тәмамланмаган. Тәмамлагыз.

Бәхет

(Әкият)

Бер карт үләр алдыннан өч улын чакырган да:

— Мин сезгә васыять итеп бәхет биреп калдырам. Мин үлгәч, ул үзе килеп керер. Сынатмагыз,— дигән.

Чыннан да, әтиләре үлгәннән соң, ишектән бәхет килеп кергән.

Картның өлкән улы сәүдәгәр икән. Бәхет керү белән, аның эше гел уңайга гына китеп торган. Сәүдәгәр ерак-ерак илләргә барып, яңадан-яңа товарлар алып кайткан. Аларны, үз якларында һәм башка илләргә илтеп, кыйммәт бәягә саткан. Тиз арада картның өлкән улы илнең иң бай кешесенә әйләнеп киткән.

Картның уртанчы улы төзүче булып эшли икән. Бәхет кергәннән соң, аңардан бер-бер артлы берничә кыйммәтле сарай салдырганнар. Күп тә үтмәгән, ул төзегән йортлар бөтен илдә мактала йөри башлаган.

Аңардан хәтта чит ил патшалары да зиннәтле сарайлар салдырганнар. Картның уртанчы улы илнең иң шөһрәтле кешесенә әйләнгән.

Картның кече улы чебен үтерергә яраткан. Мич башыннан төшми генә көннәр буена чебен үтереп ята икән. Бәхет кергәннән соң, аның да эшләре алга киткән. Элек ул бер сугуда бер-ике чебен генә үтерә торган булса, хәзер унарны, унбишәрне үтерә башлаган, ди.

Биремнәр

1. Әкият өч вакыйгадан тора. Бу вакыйгалар аның өч өлеше була. Әкиятне ике генә өлешкә калдырыгыз.
2. Ике вакыйганы кушып бөтенлек итү өчен, түбәндәге мәкальләрнең кайсылары туры килә?

* Тәвәккәл таш яра, таяк баш яра.
* Холкы начардан дуслары качар.
* Ни чәчсәң, шуны урырсың.
* Әдәм көеге булганчы, урман киеге бул.
* Аты олы, кабыргасы коры.

Хикмәтле бүрек

(Әкият)

Бер картның бөтен байлыгы бер сыер булган. Көннәрдән бер көнне бабай шул сыерын сатар өчен базарга киткән. Авыл башында аңа бер кеше очрый да:

— Нәрсә, әллә син бу сарыгыңны сатарга илтәсеңме? — дип сорый.

— Нигә сарык булсын ул, күзең күрмиме әллә синең, сыер ич ул! — ди карт.

— Син үзең сыер белән сарыкны аермыйсың,— ди дә бу кеше үз юлына китә.

Карт юлын дәвам итә. Бара-бара тагын бер авыл башына барып җитә. Бу авылда аңа тагын берәү очрый да:

— Нәрсә, әллә бу сарыгыңны сатасыңмы? — дип сорый.

— Нишләп сарык булсын ул, сыер бит,— ди карт.

— Үзең олы гына кеше, үзең сыер белән сарыкны да аермыйсың,— ди дә китә теге кеше.

Базарга җитәр алдыннан картка тагын бер кеше очрый.

— Син, агай, бу сарыгыңны сатарга илтәсеңме әллә, күпме сорыйсың? — ди.

— Акылдан яздыңмы әллә, сыер ич бу! — ди карт.

— Син, абзый, миңа юкны сөйләмә, сарык тек сарык инде бу,— ди теге кеше.

«Әллә чыннан да минем сыер дигәнем сарык инде?..» — дип уйлана башлый карт. Бар да бер сүз сөйләгәнгә шикләнә. Ә тегеләр өчесе дә караклар икән. Картны алдарга сөйләшеп куйганнар болар.

Карт уйлап-уйлап тора да, базарга кермичә үк, сыерын сарык бәясенә шушы кешегә сатып, өенә кайтып китә.

— Их, карчык,— ди карт карчыгына,— без үзебезнең малны юкка гына сыер дип йөргәнбез икән, ул сарык булган икән бит.

— Сине алдаганнар болай булгач,— ди карчыгы.

Карт бик нык хурлана. Берничә көн уткәч, сыерын саткан акчаны ала да әлеге базарлы шәһәргә китә. Монда ул өч чәйханәгә кереп, яхшылап сөйләшеп чыга:

— Өч кунак алып килермен, шуларны туйганчы ашатып-эчертерсез,— ди.

Ашаган-эчкән өчен акчасын алдан ук түләп чыгып китә. Базарда теге өч кешене очратып әйтә тегеләргә:

— Сарыгымны яхшы бәягә алдыгыз, әйдәгез, чәйханәгә кереп, бергә-бергә чәй эчеп тә чыгыйк инде,— ди.

Карт боларны алып кереп ашата-эчертә дә акча түләү урынына башындагы бүреген салып, өстәлгә шап итеп бер суга.

Чәйханәдән чыгып базарда беркадәр йөргәннән соң, карт боларны башка чәйханәгә алып керә. Монда да ашап-эчкәннән соң, карт бүреген өстәлгә шап итеп бәрә дә «расчет» дип чыгып китә.

Тегеләр гаҗәпләнәләр. Акча түләмичә генә, кунак сыйлап йөри бу, диләр.

Бераз йөргәннән соң, карт боларны өченче чәйханәгә алып керә. Монда ашата-эчертә. Акча-фәлән түләү юк, әлеге бүрекне монда да шап итеп суга. Аннары «расчет» дип, саубуллашып чыгып китә.

Каракларның берсе түзми, карттан сорый:

— Кара әле, бабай, син акча түкми генә сыйланып йөрисең, әллә моның берәр хикмәте бармы? — ди.

— Бар шул. Бүрек бик хикмәтле бит минем. Шап итеп суккан җирдә акча килеп чыга бит,— ди карт.

— Сат син ул бүрегеңне,— диләр караклар.

Карт бик кыйммәт сорый бүреккә. Тегеләр, барлык акчаларын биреп, бүрекне кыйммәт бәягә сатып алалар. Картны тагын бер мәртәбә алдадык дип, шатлана-шатлана, тизрәк бу җирдән шылу ягын карыйлар.

Мөстәкыйль эш

Бу әкияттә әллә ничә вакыйга бар. Шуларны ике өлешкә генә калдырып җыярга кирәк. Ике өлеш каршылык бәйләнешендә булырга тиеш. Анализ тәртибен укып искә төшерик тә әкияткә бергәләп анализ ясыйк.

1. Әсәрне, «Ни турында? Тагын ни турында?» сораулары биреп, өлешләргә бүләбез.
2. Өлешләрне берәм-берәм өйрәнәбез.
3. Охшаш өлешләрне кушабыз, гомумиләштерәбез. Әсәр ике генә өлешкә кала. Ике өлеш арасындагы бәйләнешне табабыз һәм бер генә җөмлә белән әйтәбез.
4. Барысына да исем биреп чыгабыз.

Әкияттәге беренче вакыйганы бик кыска итеп сөйләп карыйк. Беренче вакыйгада авыл башында бер кеше агайның сыерын сарык дип бәхәсләшә. Бу вакыйга нәрсә турында? Сарык белән сыер турындамы? Карт белән карак турындамы? Уйлап карасак, бу вакыйгаларның һәммәсе эчтәлек ачарга ярдәм итүчеләр генә бит. Вакыйганың үзәгендә нәрсә ята соң? Үзәктә сыерны, күрә торып, сарык дип ышандыру ята. Менә шул гамәлне бер сүз белән әйтеп буламы? Була, әлбәттә, «ялган» дип тә, «алдашу» дип тә әйтә алабыз. Димәк, бу вакыйга алдашу турында.

Бирем

Калган вакыйгаларны шул рәвешле кыскартып сөйләгез. Нәтиҗәдә, барлык вакыйганың да алдашу турында булуын белерсез. Ләкин алар ике капма-каршы якка бүленәләр. Бүлегез.

МӘГЪНӘ

Мәгънә — әйбернең безгә кирәк ягы, дип өйрәндек.

Таякның мәгънәсе чыбыркы сабы да, орчык, чаңгы таяклары да булуын яхшы хәтерлисез. Әдәби әсәрләрдә катнашучы кош-кортның мәгънәләре дә кеше булуын беләсез. Берничә әсәр белән танышыйк.

Феликс Кривин

Моржа

(Мәсәл)

Моржа карашынча, бу өйдә яшәүчеләрнең эш-гамәлләрендә бер мәгънә дә юк. Су краны иртәдән кичкә кадәр бер үк чиләкләргә су тутыра да су тутыра. Газ плитәсе бер үк кәстрүлләрне, чәйнекләрне, табаларны җылыта. Балта утын яра да утын яра. Моржа гына кухнядагы юк-бар эшләрдән өстен: ул төтен белән бөтен Галәмне тәэмин итеп тора.

Бирем

Хикәягә автор салган мәгънәне табыгыз.

Муса Җәлил

Имән

Юл чатында ялгыз гына
Үсеп утыра бер карт имән.
Тирә-ягы яшел чирәм,
Ботаклары җиргә тигән.

Таң җилләре җилфер-җилфер
Җилфердәтә яфракларын.
Имән җырлый, искә төшереп
Шаулап үткән яшь чакларын.

Мең ел элек кемдер монда
Җир казыган, тир тамызган
Һәм беренче кат имәннең
Яшәү иртәсен кабызган.

Кем дә белми ул кешене,
Игенчеме, бакчачымы,
Яшеллек һәм хәят сөйгән
Батыр хезмәт патшасымы?

Кем булса да, туфрагында
Җир саклаган аның тирен,
Һәм карт имән гомре белән
Бүләкләгән бу эш ирен.

Һәр көн юлдан дистәләгән
Юлчы уза, тузан туза.
Һәм һәр юлчы, моңлы җырчы,
Имән җырын тыңлап уза.

Җилле көнне юлчыларны
Имән саклый җил-яңгырдан.
Җылы биреп җил-су үтмәс
Яшел чуклы юрганыннан.

Күләгәсе ял иттерә
Кырда эшләп арганнарны,
Кавыштыра айлы кичтә
Яшерен утта янганнарны.

Юл күрсәтә адашканга
Имән кышкы бураннарда.
Җәен татлы дымын эчерә
Кырда урак урганнарга.

Бәхетле син, ерак илдәш,
Хезмәтеңә мин баш иям.
Һәйкәл булып яшьлегеңә
Үскән монда бу карт имән.

Җирдә кеше торса торсын,
Эзе калсын тирән булып,
Үзе үлсә, эше калсын,
Мең яшәрлек имән булып.

10 декабрь, 1943

Биремнәр

1. Шигырьне ике вакыйгага бүлегез.
2. Авторның имән образына салган мәгънәсен әйтегез.
3. Вакыйгаларның бәйләнешен табыгыз.

Инша языйк

Авылыгыздагы бик оста мичченең, исемен-атын үзгәртмичә, матур эшләре, холкы турында инша языгыз. Журналистлар андый иншага **очерк жанры** диләр. Алар

миччегә бәяне (ягъни мактауны) салган мичнең нинди дә булса сыйфатыннан чыгып бирергә яраталар. Күп сыйфатлар арасыннан бәя бирердәен сайлап алалар. (Муса Җәлилнең «Имән» шигырендә дә шулай. Имәннең мең ел яшәү сыйфаты игелекнең беркайчан да онытылмавы турында сөйли.)

Оста куллы кеше чыгарган мич сыйфатларын дәфтәрләрегезгә языгыз.

Әйтик, журналист мичнең аз утын ягып күп җылы бирүенә тукталды, ди. Ул, миччегә бәя бирү өчен, «җылылык» яки «җылы» сүзләренә останы мактарлык мәгънә сала. Очеркын шул бәя белән тәмамлый. Гадәттә автор башта әсәренең ахырын уйлап таба. Аннары эшен ахырдагы нинди дә булса мәгънәле сүз, күренеш яки вакыйганы кабатлап башлый. Сез дә шулай эшләгез. Иншагызны журналист булып язарга тырышыгыз. Авыл мичен күрмәгән укучылар мич турында өлкәннәрдән сорап белә алалар. Иншагызны «җылы» сүзенә мәгънә биреп тәмамларга тырышыгыз. Шуңа күрә эшегезне болай башлый аласыз:

Мичебезнең рәте китте. Җылытмый башлады, төтен чыгара, җитмәсә, бик зур. Күп урын алып тора. Әти оста мичче Галимулла бабайны алып кайтты һ. б.

Дәвам итегез. Галимулла карт ничек эшләде? Эшләгәндә сезгә ниләр әйтте? «Җылы» сүзен тагын, тагын кабатларга тырышыгыз. Аңа башка мәгънәләр бирегез.

Мөстәкыйль эшләр

* Иләктә су тормый,
Юлләрдә сүз тормый.

* Арбаны — кышын,
Чананы җәен әзерлиләр.

Бирем

Мәкальләрнең һәркайсы берботен әсәр булуын исбат итегез. Моның өчен аларны, бер гади җөмләгә генә калдырып, үз сүзегез белән әйтергә кирәк.

Тубылгы ла агач зур булмас,
Арасыннан үтәр юл булмас.
Кайда ла барсаң, дустың булсын,
Дус-иш барда ирләр хур булмас.

Мәк чәчәкләре коела,
Былбыл кагынган саен;
Мәк чәчәкләренә карыйм,
Сине сагынган саен.

Беренче мисалдагы табигать күренешен ачыклыйк. Сүз тубылгы агачы турында бара. Нинди агач соң ул тубылгы? Исле матур чәчәк ата торган, көчле җилдавылларга бирешмәүчән, сыгылмалы-бөгелмәле, кайрысы куе кызыл төстәге болын куагы ул — тубылгы. Өстәвенә әле, аның куаклары хәтта араларыннан юл да үтмәслек дәрәҗәдә куе була. Әнә күпме матур сыйфатларга ия икән тәбәнәк кенә куак.

Җырның икенче өлешендә сүз дуслык турында бара. Тубылгы агачы сыйфатларын җырчы лирик геройның дустына күчерә, шуңа күрә тубылгы турындагы өлешнең эчтәлеге әһәмиятен югалта. Җыр эчтәлеге берәү генә — лирик геройның дустына мәхәббәт хисе. Тубылгы һәм кеше турындагы өлешләр бөтенлек булалар. Дуслык хисе эчтәлеккә байый.

Биремнәр

1. Тубылгының «Арасыннан үтәр юл булмас» сыйфаты төп өлешкә нинди эчтәлек өсти?
2. Мәк чәчәге турындагы дүртьюллыкта чәчәк белән былбыл лирик герой язмышын ачыклыйлар. Ничек ачыклыйлар?

Әнгам Атнабаев

Җиз кыңгырау моңнары

Урап-урап карлар күмә
Кышның озын юлларын,
Чың-чың итә, җил тузгыта
Җиз кыңгырау моңнарын.

Җиз кыңгырау моңнарында
Үткәннең тавышлары,
Очрашулар, кавышулар,
Аерылу сагышлары,
Үткәннең тавышлары.

Бирем

Автор «Карлар күмә кышның озын юлларын» һәм «Җил тузгыта җиз кыңгырау моңнарын» дип яза. Бу сүзләренә ул нинди мәгънә салган?

Марсель Галиев

Җиңәсем килде

Соңгы дәрес башланыр алдыннан һәркем әз генә булса да хәрәкәтләнеп, сөйләшеп калырга тели. Бу тавыш җыелмасын төсләргә әйләндерсәң, сыйныф бүлмәсе эчендә салават күпере уйнап торыр иде. Илгиз Зөлфиянең елкылдап торган толымыннан тартып куйды. Әмма кыз борылып та карамады. Дәресен ятлый иде бугай. Чәченә беркетелгән ак банты төнбоек чәчәге кебек балкып тора. Бөтен авазларны күмеп, Сәләхи көлә. Әйтерсең зур авызыннан тешләренә бәрелә-бәрелә яңгырап чыга аның тавышы. Шундый иләмсез көлү буламыни инде? Ә Илгиз үзе ничек көлә икән?

Шулвакыт ишек янында сакта торучы кычкырып җибәрде:

— Килә!!

Авазлар кинәт тынып калды. Ишек ачылуга, гүя ниндидер кнопкага бастылар. Бөтен сыйныф дәррәү урыныннан купты. Сыйныф җитәкчесе Сания апаның йомшак тавышы, җылы нур булып, рәтләр арасыннан үтте.

— Исәнмесез, укучылар!

— И-сән-ме-сез.

Сания апа кулында зур төргәк. Күзләрендә гадәттән тыш ягымлылык.

— Укучылар,— дип башлады ул,— бүген без Мәскәүдән посылка алдык. Шахмат мәсьәләләре чишү буенча үсмерләр арасында үткәрелгән конкурста беренче урынны яуладык. Мортазин Илгизгә приз җибәргәннәр.

Бөтен сыйныф кинәт ду килде. Көнләшү катыш соклану белән, җиңүчегә төбәлделәр. Илгизнең колакларына кадәр кызарып чыкты.

— Кем дөресен әйтер икән, нинди бүләк дип уйлыйсыз, йә?!

— Курчак,— дип куйды Зөлфия һәм, кинәт кычкырып җибәрүеннән үзе үк оялып, битен каплады.

— Җуләр, торт диген!

Бөтенесе Сәләхигә борылдылар. Төргәк эчендә торт булуга шиге булмагандай, ул голт итеп төкереген йотып куйды.

— Укучылар, 5 «А» сыйныфы чемпионы, районыбыз конкурсында җиңеп чыккан Мортазин Илгизгә грамота һәм шахмат тапшырыла.

Укытучы төргәкне чишеп җибәрде.

— О-о!

— Кара әле, фигуралары гел пыяла сыман...

Бәллүр шахматлар төрле төсләргә кереп балкыйлар. Илгиз сизелер-сизелмәс кенә калтыранган кулына бүләкне алды. Йөрәге кош булып талпына. «Менә, әнигә күрсәтим әле. Төннәр буе, шул шахматыңда казынып, кухняда утырасың дип зарлана иде. Ә Зөлфия ниләр уйлый икән?» Илгиз беркемгә дә күтәрелеп карый алмады. Аның күзләрен бәхет каплаган иде. «Зөлфия хәзер бик чәпчемәс инде. Миңенә дә бармак белән кагылдырыр»,— дип уйлый ул. Кызның муенында өлгергән карлыган шикелле миңе бар. Бервакыт география картасыннан, бергәләшеп, ниндидер утрауны эзләгәндә, Илгизнең аңа күзе төшкән иде. Янып торган миң кайнардыр кебек тоелды аңа. Онытылып китеп, бармагы белән кагылмасынмы! Ә Зөлфия... чалт тегенең яңагына. Бигрәк һавалы бу кызлар! Аңламыйлар малайларны!

Дәрестән соң Илгиз Зөлфия белән кайтырга чыкты. Алар бер йортта яшиләр. Парк капкасы янында басып торучы озын буйлы егеткә тыныч кына карап үтә алмады Илгиз. Киерелеп куйды. Җилкәләрен турайтты.

Сузылып бер-ике сантиметрга үсеп куйгандай булды. Аһ, шуның кебек биек булсаң икән.

— Син ничек уйлыйсың, Зөлфия, берәр дару эчеп, тиз генә үсеп китеп була микән?

— Белмим. Ә минем үсәсем килми. Матур күлмәкләрем әрәм булыр дип куркам...

— Әйдә, аптекадан сорап чыгабыз.

— Әйдә. Тик минем бер дә үсәсем килми бит. Гел шулай кечкенә булып калсаң ие икән ул...

Витрина артында торучы апалар Илгиз соравыннан елмаештылар.

— Үсәргә тели бу. Ә акчаң бармы соң?

Илгиз кызарып куйды. Кесәсендә биш тиен генә калган икән. Бүген буфетта кекс алган иде шул. Пәрәмәч кенә ашаса ни булган. Әнә Сәләхи өеннән алып килгән ипине бөкли дә куя.

Сатучы, серле елмаеп, аңа таблетка сузды.

Алар паркка керделәр... Беседкалар янында кешеләр өелешкән. Анда һәвәскәрләр шахмат уйныйлар. Илгиз кайберләрен танып та белә. Бер читтәрәк култыгына шахмат тактасы кыстырган таза гәүдәле абый тора. Илгиз батырлыгын җыеп аңа таба китте.

— Абый, әйдәгез, икәү уйныйбызмы? Минем бәллүр шахматларым бар, менә бүген генә Мәскәүдән бүләк итеп җибәрделәр.

Таныш түгел абый аңа таба кулын сузды:

— Син бик бәләкәй түгелме соң?

— Булса ни, мин үзебезнең сыйныфта бөтенесенә дә мат куям.

Сәләхи кебекләр белән ферзесез генә уйныйм, дип тә җибәрмәкче иде, тыелып калды Илгиз.

— Мин үземнекенә күнеккәнмен, бу да ярар,— диде таныш түгел абый. Шулчак Илгиз аның күзләренә карап тетрәнеп китте. Аның күзләре тирән тарлавык эчендә кибеп баручы күлгә охшаган иде. Илгиз аларда көн нурын күрмәде. Димәк, ул сукыр... Сукыр кеше ягымлы итеп елмайды. Әйтерсең күзендәге бөтен нуры

аның йөзенә күчкән. Аның шахмат тактасы гадәти түгел, һәр шакмагы тишекле. Фигуралар шул тишеккә кадап куела. Ул бармаклары белән капшап уйный икән.

Күрмичә уйный торган бу абыйга Илгизнең бер дә җиңеләсе килмәде. Ләкин торган саен уен катлаулана бара. Ул бик төгәл уйный, әйтерсең бармаклары белән күрә. Илгиз үҗәтләнеп иреннәрен кысты. «Мин — җиңәргә тиеш. Җиңәргә!» Һәм ул, үзе дә сизмәстән, партнерның почмакта торган ладьясын алып учына йомды. Сукыр шахматчы бераздан нәкъ шул ладья торган төшкә үрелде. Ләкин аның кулы бушлыкта асылынып калды. Кул, бераз хәрәкәтсез торганнан соң, икенче фигурага күчте... Ладья Илгизнең учын пешерә башлады. Фигураны кире урынына утырту соң иде инде. Уен ахырына якынлашкан саен, Илгизнең башы яка эченә тирәнрәк чума барды. Җиңелүе көн кебек ачык.

— Йә-йә, күңелеңне төшермә, бүген җиңелсәң дә, иртәгә, һичшиксез, җиңәчәксең,— дип, соңгы йөрештән соң абый кеше аның җилкәсенә кулын салды.— Чемпион булырга җыенасыңдыр әле. Мин дә синең кебек чакта шулай хыяллана идем. Каһәр суккан сугыш булмаса!.. — Шулчак кырыйга килеп баскан Зөлфия:

— Ә сез элек күрә идегезме? — дип сорап куйды.

— Әйе, кызым. Танк эчендә яндым. Күзләрем дә...

Илгизнең күңеле тулды. Оялудан ул комачтай булган иде.

— Абый, сез мине гафу... гафу итегез инде. Мин хәйләләдем, теге фигураны алып... Минем бик тә җиңәсем... җиңәсем килде...

Абый кеше елмаеп куйды.

— Хәйлә белән түгел, бары акыл белән җиңеп була. Ә мин синең гафу үтенәсеңне белгән идем. Син шуны онытма, улым. Беркайчан да хәйлә белән җиңеп булмый. Ә шахматка килсәк, ул гади уен гына түгел, ә көрәш мәйданы,— диде.

Бераздан алар чын дуслар булып аерылыштылар.

Илгиз, кырыенда Зөлфия барын күрмәгәндәй, сүзсез бара. Илгиз күңелендә әлеге хәйләсе өчен оялумы әллә җиңелү ачысымы? Кайчан соң ул бер дә җиңелми башлар икән. Теге абый белән ул тагын уйнаячак. Җиңгәнгә кадәр!

Урамның як-ягында ябалдашлары кыркылган агачлар. Алар әкияттәге кебек, озын бармакларын күккә сузып, катып калган шүрәлеләр сыман.

— Зөлфия, беләсеңме, пешка соңгы шакмакка җитсә ферзь була.

— Булса соң?

— Булса соң, имеш. Шахмат кырында ул иң көчле зат, белдеңме! Тик һәр пешка да ферзь була алмый. Без менә хәзер пешка кебек кечкенәләр әле...

— Әнә Сәләхи зур бит. Ул ферзьме?

— Ул да пешка. Син дә пешка.

— Ничек инде ул мин пешка булыйм?..

— Хәзергә пешка. Ә ферзь булсаң нишләр идең?

— Балерина булам.

Илгизнең аны син ферзь була алмыйсың дип үртисе килде. Ләкин кызга читтән карап сокланып куйды. Зөлфия киң итәкле пальто кигән. Күпереп торган ак башлыктан — нәкъ менә нәфис шахмат фигурасы — нәкъ ферзь төсле.

— Ә син ферзь булсаң?..

— Минме, минме?..

Илгиз үзен шахмат таҗы кигән король итеп күз алдына китерде. Ләкин уйларын әйтергә кыймады. Бары Зөлфиянең кулын каты итеп кысты.

Алар зәңгәр күләгәләр сеңгән кар өстеннән кояшка таба йөгерделәр.

Биремнәр

1. Хикәяне үзегез аңлаганча, кыскартып сөйләгез.
2. Хикәянең төп катнашучыларын дәфтәрләрегезгә языгыз. Төп геройны табыгыз. Ни өчен төп герой булуын аңлатыгыз.
3. Төп геройга автор бәясен әйтегез.

Галимнәр сыйфатлары охшаган предметларны кушып гомумиләштерәләр һәм барысына бер гомуми исем бирәләр. Исем аларны җыеп, бөтенлеген күрсәтеп тора. Гомумиләштерү — фикерләүнең бик мөһим бер алымы.

Сыйфатлар да бер-берсенә охшыйлар. Без үзебез дә галимнәр кебек үк фикер йөртә алабыз: бу укучы тырыш, мактанмый, эшчән, шәфкатьле, миһербанлы, тәүфыйклы дип, төрле сыйфатлар тезеп чыгабыз да шушы сыйфатларның һәммәсенә, «яхшы бала» дип, уртак бер исем бирәбез. Бүтәнчә әйтсәк, **гомумиләштерәбез.**

Ованес Туманян

Ялганчы

(Әкият)

Булгандырмы, юктырмы, яшәгән, ди, бер патша. Һәм ул иленә шундый белдерү ясаган:

— Кем дә кем дөньяда булмаганны уйлап таба һәм мин аңа: «Бу ялган»,— дип әйтсәм, шул кешегә ярты патшалыгымны бирәм,— дигән.

Моңа бер көтүче килә.

— Патшага озын гомер телим! Минем әтиемнең гаҗәп бер күсәге бар иде. Ул аның белән, күккә кадәр сузылып, йолдызларны болгата иде,— ди.

— Искитәрлек нәрсә сөйләмәдең, минем бабамның трубкасы бар иде, ул аның бер башын авызына кабып, икенче башы белән кояштан ут кабызып ала торган иде,— ди патша. Көтүче, патшаның бу ялганына ни дияргә дә белмичә, башын кашый-кашый, өенә кайтып китә.

Икенче көнне патша янына тегүче килә.

— Патша хәзрәтләре, син мине гафу ит инде, иртәрәк килермен дигән идем дә, бераз соңгарак калынды. Кичә бик каты яңгыр яуды, күк күкрәде, һәм яшен күкне тишкән. Шуны ямап йөрдем,— ди.

— Яхшы эш башкаргансың,— ди патша.— Ләкин начар ямагансың, бүген иртән тагын яңгыр сибәләде.

Тегүче дә оттырган.

Култык астына үлчәү кыстырып, ярлы игенче килеп кергән.

— Нәрсә кирәк? — дип сорый патша.

— Синең миңа бер үлчәү алтын бирәсең бар иде. Бүген шуны алырга килдем,— ди игенче.

— Бер үлчәү алтын? Ялган бу! Минем сиңа бернинди алтын бирәчәгем юк! — ди патша.

— Мин әйткән ялган булса үтә: ярты патшалыгың минеке! — ди көтүче.

— Юк, юк. Син дөрес сөйлисең,— дип котылмакчы була патша.

— Әгәр дөрес сөйлим икән, ул чагында тутыр бер үлчәү алтыныңны! — ди игенче.

Бирем

Әсәргә анализ ясау өченниләр эшләргә кирәк? Исегезгә төшерегез. Анализ ясагыз.

Тезмә әсәрләргә **лирик шигырьләр, бәетләр, поэмалар, балладалар** керә. Мондый әсәрләр лирик геройның эчке кичерешләрен сурәтлиләр. Бу сыйфат аларның барысына да хас.

Әдипләр, хисләрен ачар өчен, табигать күренешләреннән файдаланырга яраталар. Шунлыктан шигырьдә төрле күренешләр, образлар сурәтләнә. Әсәрдә алар, бер-берсе белән бәйләнешкә кереп, бар да лирик герой хисе булып, бер ноктага җыелалар. Шигырьнең бу үзенчәлегенә **эчке бөтенлек** диләр.

Хисне күрсәтеп була. Моңа ышану өчен, дәфтәрегезгә нинди дә булса хис ясарга тырышыгыз. Мәсәлән, кеше авызын әле өскә, әле аска таба борып, елмаю, елау хисен күрсәтегез. (Бәлки, икеләнү, соклану, аптырау, көнләшү, ачу кебек хисләрне дә ясый алырсыз. Ясап карагыз.) Ә аннары шул ук хисләр турында сөйләгез. Хисне ничек кенә сурәтләргә тырышсагыз да, барыбер кешенең йә авызыннан, кашларыннан, йә кулларыннан файдаланачаксыз. Ә алар үзләре берсе дә хис саклаучы әгъзалар түгел. Хисне үзеннән читтәге башка нәрсәләр аша гына тасвирлап була. Шагыйрьләр дә, хисләрен белдерү өчен, табигать күренешләреннән, кешенең төрле әгъзаларыннан, күз күрә, колак ишетә торган башка әйберләрдән файдаланалар. Шунлыктан шигырьдә төрле күренешләр, образлар чәчелеп ята да.

Халык җырларына күз салыйк.

Гөлчирә

(Халык җыры)

Түр тәрәзә яннарында
Энҗе сайлый Гөлчирә.
Озын керфекләре аша
Күзләреннән нур сибә.

Кушымта:

Ай-һай матур Гөлчирә,
Энҗе мәрҗәннәрне тезеп,
Гөлчирә калфак чигә.

Кара толымнарын үреп
Салган ике иңенә.
Билләрен буган тасмасы
Килешә нәзкәй биленә.

Кушымта.

Һушларымны алырсың күк,
Күзем баксам йөзеңә,
Зөһрә йолдызыдай балкып
Күренәсең күземә.

Кушымта.

Җырның өлешләре арасындагы бәйләнешләр күзгә ташланып торалар. Алар бар да кызның матурлыгы турында. Кызның матурлыгы сәбәп булса, лирик геройның аңа карап соклануы — нәтиҗә. Автор соклануын матурлык дәрәҗәсен арттыру юлы белән күрсәтә. Шуңа күрә беренче строфаны болай әйтеп була: тәрәзә янында энҗе тезеп утыручы кыз искиткеч чибәр.

Биремнәр

1. Калган строфаларның эчтәлеген дә шул рәвешле үз сүзләрегез белән дәфтәрләрегезгә языгыз.
2. Лирик герой хисенең дәрәҗәсе тасвирланган урыннарны табыгыз.

Кыр казы

(Халык җыры)

Кыр казлары очты, күрдегезме
Һаваларга менеп киткәнен?
Беләсеңме, дустым, сизәсеңме
Аерылулар килеп җиткәнен?

Балалы ла казлар су эчендә,
Баласызлар суның читендә:
Аерылабыз, дустым, сизәсеңме?
Сагынырсыңмы мине чит илдә?

Беренче строфаның баштагы ике юлы кыр казларының очып китүе, ә соңгы ике юлы лирик геройның аерыласын белеп борчылуы турында. Ике өлеш арасында бернинди дә бәйләнеш юк кебек. Егет, казлар кебек, җылы якларга очмый бит. Кыр казларының да җирдәге лирик геройда эше юк. Ләкин ни өчен җырда алар янәшә торалар соң?

Җыр сүзләрен җентекләбрәк укыйк әле.

Баштагы өлештә казларның бер генә сыйфаты әйтелә: алар очып китәләр. Ләкин без кыр казларының яңадан әйләнеп кайтачагын беләбез.

Менә ни табарга кушкан икән безгә автор. Ул безгә бу ике өлешне бөтенлек итеп күрергә кушкан. Киткән казлар кайталар, шулай булгач, икенче өлештәге ана да баласы белән кавышачак! Читкә киткән баласы, һичшиксез, туган-үскән җиренә әйләнеп кайтачак дип шатланабыз.

Дәвам итик: кыр казлары, туган якларына кайтып, үзләренә оя коралар. Балалар үстерәләр. Казларның бәхетле язмышы да лирик герой язмышына киная түгелмени? Бу строфа өмет турында дип нәтиҗә ясыйбыз.

Бирем

Җырның соңгы строфасын да шул рәвешле өйрәнегез.

Мөстәкыйль эш

Түбәндәге дүртьюллыкларның эчтәлеген табыгыз.

Арыслан ла киек, ай, алдырмас[1],
Каршысында биек тау булса.
Егет тә генә кеше һич кайгырмас,
Газиз башы аның сау булса.

[1] Алдырмас — үтә алмас, җиңеп чыга алмас.

Кара да гынай урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк үтәргә;
Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк гомер итәргә.

Дәрдемәнд

Кыш көннәре

Картайды җиһан...
Гөлләр дә бетте!
Кичмәктә заман —
Кышлар да җитте!
Иелде ботаклар,
Карлар асылды:
Таулар, елгалар —
Бар да басылды!

Күк бозлар катып,
Оешып ятып,
Чишмәкәй шымды —
Бар җиһан тынды!
Җил генә яман
Сызгыра, өрәдер,
Һәм күктә йөрәдер
Бәс белән томан.

Бирем

Шигырьгә анализ ясагыз.

Һади Такташ

Әй, җырлыйсы килә шушы җырны

Әй, җырлыйсы килә шушы җырны,
Бу җыр шундый якын күңелгә,
Җырланган җыр кебек яшьлек таңы
Шаулап үтте,
Шаулап үтте инде гомергә!

— Пи-би-би-бип... —
Ди дә каз бәбкәсе,
Яхшатланып килгән, сөйләнә...
Каз бәбкәсе, белмим телеңне,
Шуңа бүлешә алмыйм сереңне...
Белсәм иде, мин дә тыңлап сине,
Аунап ятар идем чирәмдә.
Син дә, ашый-ашый, теләгәнчә
Сайрап йөрер идең тирәмдә...

Каз бәбкәсе, җаным, телең белмим,
Кем өйрәтте болай сөйләргә?
Гаҗәп матур сөйли беләсең...
Анаң уңган каздыр, күрәсең...

Казлар көтеп үткән малай чагым
Күмелеп калды шушы урында...
Алдадылар мине шәһәр халкы:
Эштән аерып алып киттеләр,
Анда баргач, шагыйрь иттеләр...
Их!
Авыл кырын тутырып бодай үсә,
Дулкынлатып аны җил исә,
Ташлап шагыйрьлеген җил иркенә
Калыйм мәллә монда югыйсә...

Гайшә кызы килә казлар куып,
Артта кала аксак бәбкәсе,
Бөгелеп алган чакта бәбкәсен ул,
Шалтырап китә талир тәңкәсе...
Миңлениса чыккан, утын кисә,
Толымнарын селкеп җил исә,
Ташлап шагыйрьлеген җил иркенә
Калыйм мәллә монда югыйсә?
Инде монда мине хәзер
Тик бер генә нәрсә шатландыра,
Ул да:
Киләчәктә шушы кырларга
Тракторлар килер җырларга...
Тик бер генә нәрсә шатландыра:
Киләчәктә шушы урында
Нәни коммунарлар ат көткәндә
Җырлар җырлар минем турында...

Лирик геройны иң элек әсәр башында бирелгән эпиграфта очратабыз. Эпиграф — сәнгатьнең бер алымы. Аның белән якыннанрак танышыйк.

Эпиграф әсәр башында уң якта урнаша. Эпиграф итеп, гадәттә, укучыларга таныш әсәрдән өзек алына. Эпиграф, башка өлешләр белән бәйләнешкә кереп, әсәр эчтәлеген табарга ярдәм итә. Авторны без, беренче чиратта, эпиграфта күрәбез.

Эпиграфны тагын бер кат укып чыгыгыз. «Ул ни турында?» соравына сез: «Эпиграфта шагыйрь үткән яшьлеген сагынуы турында яза»,— дип җавап бирәчәксез. Бик дөрес җавап. Ә ни өчен яшьлек түгел, «яшьлек таңы» ди автор?

Әйдәгез, лирик геройны авторга алыштырыйк. Бу шигырен ул туган авылы Сыркыды турында, шунда кайткач язган бит.

Сез белгән дөрес җавап мондый: таң көннең яңа туган чагы бит. «Яшьлек таңы» дип, Һади Такташ, сезнең кебек, мәктәптә укып йөргән чагын күз алдында тота.

Һади Такташ эпиграфында җыр образының мәгънәсен дә алдан ук әйтеп куя: җырланган җыр ул — үткән балачак хатирәсе, ди.

Шигырь лирик геройның хисе турында. Шуны исбат итәр өчен, әсәргә анализ ясарга кирәк. Гадәттәгечә, үзебезгә үзебез «Ни турында? Тагын ни турында?» сораулары бирик.

1. Лирик герой турында, каз бәбкәсе турында, авыл басуындагы иген турында, авыл кызлары турында дияр идек, лирик шигырьләрнең төп герое — лирик герой, ә шигырьнең эчтәлеге лирик герой хисләре булуы безгә яхшы таныш. Димәк, каз бәбкәсе, иген, авыл кызлары лирик герой хисенең сәбәпләре булырга тиеш. Шуны исбат итегез.

Шигырьнең башка өлешләрен күздән кичерсәк, аларның барысы да лирик геройның бала чагын сагынуы турында диячәксез.

Нәтиҗә ясыйк: шигырьдәге барлык өлешләр дә эпиграфта әйтелгән сагыну хисен вакыйгалар эченә кертеп кабатлады. Кабатлаган саен хиснең дәрәҗәсен арттырды. «Әсәр ни турында?» соравына хәзер шикләнмичә җавап бирә алабыз. Әсәр Һади Такташның авылда үткән бала чагын сагынуы турында. Ләкин шигырьдәге эпиграф «эшсез» калды түгелме? Ул бит төп өлешне ачыклап килергә тиеш иде? Әһә, шигырь азагында җыр образы тагын кабатлана икән.

Биремнәр

1. Әсәр ахырында кабатланган җырның мәгънәсе үзгәрде. Ничек үзгәрде?
2. Эпиграфның баштагы ике юлына күз салыгыз. Авторның ни өчен шушы җырны ярсып җырлыйсы килә?

Мөстәкыйль эшләр

Роберт Әхмәтҗанов

Кайтып барыш

Як-ягымда яшел арыш
Килә әйлән-бәйлән!
Туган йортка кайтып барыш,—
Җир, син тизрәк әйлән!

Бирем

Шигырьне үз сүзләрегез белән сөйләгез. Яшел арышның әйлән-бәйлән килүен, җирне тизрәк әйләндерү турындагы юлны аңлатыгыз.

Илдар Юзеев

Өзелмә

Мин — бер яфрак, яралганмын
Әнкәй дигән каеннан,
Язмышым тик изгелектән,
Ал нурлардан каелган[1].

Хәзер үзем — каен.
Әнкәй, яфрагым бул, өзелмә,
Саклармын зәһәр җилләрдән
Кышларын да, көзен дә...

Бирем

Шигырьгә анализ ясагыз.

---

[1] Каелган — чигелгән.

ТЕЗМӘ ӘСӘР ӨЛЕШЛӘРЕН БӘЙЛӘҮЧЕ ЧАРАЛАР

Сүзләрдәге авазлар охшашлыгы. Рифма

Аеруча еш кабатланучы бәйләнешләрнең берсе — охшашлык.

«Әйт әле, Күбәләк, / Сөйләшик бергәләп»,— дип язган Габдулла Тукай. «Күбәләк» шигырендәге беренче юлын «күбәләк» сүзе белән, ә икенчесен аңа охшаган «бергәләп» сүзе белән тәмамлаган. Бу сүзләрнең уртак эчтәлекләре юк. Нибары «әләк» авазлары һәм, төрле урында утырсалар да, «б» авазлары гына кабатланган. Шулай да аларның яңгырашлары охшаш.

Шигырь юлы ахырында килүче охшаш авазлы сүзләргә **рифма** диләр.

Халык авыз иҗатында рифма

Үсә каен, үсә каен
Яфраклары әрәтсез;
Бу дөньяда кошлар гына
Кайгысыз, хәсрәтсез.

Биремнәр

1. Дүртьюллыктан рифма табыгыз. Дәфтәрләрегезгә язып куегыз (мәсәлән: *карга — арба*).
2. Строфаның каен турындагы өлешендә «яфраклары әрәтсез», ягъни күп, ди автор. Соңгы ике юл белән кушылгач, ул нинди мәгънә бирә?

Каз канаты ап-ак була,
Ир канаты ат була;
Чит илләрдә йөргән чакта
Бик сагынган чак була.

* Аланда үскән балан әче була.

* Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар.

Бирем

Дүртьюллыкның һәм мәкальләрнең рифмадаш сүзләре нинди өлешләрне берләштерүен әйтегез.

Әдәби әсәрләрдә рифма

XIX йөзнең беренче яртысында иҗат иткән талантлы шагыйребез Габделҗәббар Кандалый менә нинди матур хикмәт язып калдырган:

Якутлар табыладыр вакыт берлән,
Вакытлар табылмыйдыр якут берлән.

Биремнәр

1. Шигырь өлешләре арасында каршылык бәйләнеше барлыгын исбат итегез.
2. Шигырьдәге өлешләр каршылыгын бөтенлек итүче чараларны әйтегез.

Шәүкәт Галиев

Бел

Исәннәрнең кадерен бел,
Үлгәннәрнең каберен бел.

Бирем

Шәүкәт Галиев шигыренең кечкенә генә бу өзеге үзе мөстәкыйль шигырь булырлык эчтәлеккә ия. Аның ике өлеше арасындагы каршылыгы күренеп тора. Өзек исәннәр һәм үлгәннәр турында. Ләкин анда ике якны бөтен итеп җыючы сәбәп — нәтиҗә бәйләнеше дә, рифма да бар. Исбат итегез.

Мөстәкыйль эш

Түбәндәге мәкальләрдә төшеп калган сүзләрне үзегез табып куегыз. Алар рифмалашкан булырга тиешләр.

* Сәләтсез сәнәк сындырыр, көчсез ... сындырыр.
* Бүре баласын ... салсаң да, урманга карый.
* Эшләгән туңмас, эшләмәгән ... .
* Искегә тисәң, ... китәр.
* Бер кичкә кер ... .
* Эт өрер, бүре ... .
* Кунак килсә, ит пешә, ит пешмәсә, ... пешә.

Кабатланулар тәртибе.
Ритм

Теләсә нинди кисәкнең билгеле бер тәртипкә буйсынып кабатлануына **ритм** диләр.

Сөйләм кисәкләре вак-вак өлешләргә бүленә. Аларны **иҗек** диләр. Иҗек нигезен сузык аваз тәшкил итә. Гадәттә сузык аваз янәшәсендәге тартык авазларны да үзе белән бергә ияртеп йөри.

Гадел Кутуй

Туган ил

И туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта.
Калсаң да бездән еракта,
Күңелдә син һәрчакта.

Суың тәмле, кырың ямьле,
Шифалы һаваларың,
Сугышларда дан казанды
Синең батыр улларың.

Искә төшә җәйге таңнар...
Рәхәт иде ул чаклар,
Бүген дәле янадыр күк
Без кабызган учаклар.

Искә төшә бәйрәмнәрең,
Табыннарың, казларың,
Бер карауда гашыйк иткән
Зифа буйлы кызларың...

Безне озаткан сукмакларны
Капламасын үләннәр,
Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Сез көтегез, сөйгәннәр!

1944 ел

Биремнәр

1. Шигырь юлын иҗекләргә бүлик:

И-ту-ган-ил, -и-ма-тур-ил, ...

2. Беренче дүртьюллыкның башка юлларын да, иҗекләргә бүлеп, дәфтәрләрегезгә языгыз. Һәр юлның иҗек санын дәфтәрләрегезгә язып куйсагыз, иҗек саны кабатланган юллар табарсыз. Дүрт юлның кайсыларында иҗекләр саны кабатлана?

3. «Суың тәмле...» дип башланган икенче дүртьюллыкны да шул рәвешле иҗекләргә таркатыгыз.

4. Баштагы ике дүртьюллыктагы иҗек саннарын чагыштырыгыз. Кайсы юлда ничә иҗек бар?

Шигырь юлларындагы буыннарның һәм иҗекләрнең бер тәртиптә кабатлануы нәтиҗәсендә көй барлыкка килә, ә көй хис тудыра. Шуңа күрә рифма да, ритм да шигырьләрдә хис тудыру вазифасын үти дип әйтә алабыз. Алар шигырьне бер хискә буйсындырып, җыеп торалар, юлны юлга, строфаны строфага охшаталар. Иҗек һәм ритм, төрле строфаларны бербөтенгә әйләндереп, шигырь тудырырга ярдәм итәләр.

5. Шигырь, лирик герой хисенең эчтәлеге, дәрәҗәсе һәм юануы дип, өч өлешкә бүленә. Исбат итегез.

Шигырьдә авазлар, иҗекләр, басымнар, сүзләр, җөмләләр, строфалар да кабатлана. Шигырь, үзенең ниндидер кисәкләрен кабатлый-кабатлый, чәчелеп яткан төрле сыйфатларны, предметларны, күренешләрне, вакыйгаларны бербөтен итеп җыя. Үзара бәйли. Шулай итеп, яңа эчтәлек тудыра. Бу эчтәлек вакыйганың үзендә дә (ягъни сюжетта да), автор һәм персонажлар сүзләрендә дә булмый. Аны без, укучылар, әсәргә анализ ясап табабыз.

6. **Шигырьне дәрестә ятлагыз.**

Равил Фәйзуллин

Туган ягым

Беләм: кояш астында бар
шундый шифалы яклар:
кадасаң чыбык җиренә —
яшьнәп чыга яфраклар!

Минем дә бар үзем өчен
шундый як — Туган ягым!
Дога иңгән һәр төшеннән
чишмәләр чыга аның!

Анда кайтсам — күз алышына,
күрмим фәкыйрьлеген дә...
Кара уйга урын юк шул,
нур тулгач күңеленә!

Тычкан утын учак саныйм,
картны яшь итеп күрәм.
Һәрбер сайраган кош — былбыл,
гөл — һәрбер үскән үлән!

...Өсте генә көл үткәннең,
терелә ут — өр генә!
Һәр сулышың бер җыр монда,
Вакыт тап, кайт, йөр генә!

Биремнәр

1. Анализ алымнарының тәртибен искә төшерегез. Шул тәртипне саклап, әсәргә анализ ясагыз.

2. Башта — беренче строфадагы ике юлның иҗекләрен, аннары өченче һәм дүртенче юл иҗекләрен санагыз. Аерма булуын күрерсез. Икенче, өченче һәм калган строфадагы юлларны да санап карагыз, барысының да иҗек саны беренче строфаныкы кебек булыр. Аерма да кабатланыр. Шуны исбат итегез.

СТРОФА

Әдипләр шигырьне ритм кабатланган өлешләргә бүләләр һәм ул өлешләргә **строфа** диләр. Строфа шигырьне эрерәк өлешләргә бүлә. Алар берберсеннән киңрәк ара белән аерылалар.

Шигырь строфаларга ничек бүленә?

Безгә таныш Гадел Кутуй шигыренә әйләнеп кайтыйк. Бу шигырь биш строфага бүленгән. Аларның һәрберсе беренче строфаның төзелешен кабатлый: беренче юл белән өченче юлдагы һәм икенче белән дүртенче юлдагы иҗек саннары кабатлана. Рифмалы сүзләр барлык строфаларда да бер үк урында, икенче һәм өченче юллар ахырында урнашкан.

Бирем

Шуны исбат итегез.

Нәтиҗә ясыйк: строфалар чыннан да беренче дүртьюллык төзелешен кабатлыйлар икән. Строфалар ике һәм биш-алты юлдан торырга мөмкин. Ничә генә юлдан торсалар да, алардагы кабатланулар билгеле бер тәртипкә буйсынырга тиешләр.

Муса Җәлил

Тик булса иде ирек

Карлыгач булса идем,
Канат кагынса идем,
Җидегән йолдыз батканда,
Чулпан йолдыз калыкканда,
Туган илем, якты өем,
Очып сиңа кайтыр идем,
Сызылып таңнар атканда.

Йә булсам алтын балык,
Ак дулкыннарны кагып,
Ярсып дәрья акканда,
Ташып ярдан ашканда,
Таң сөмбелем, нечкә билем,
Йөзеп сиңа кайтыр идем,
Күлне томан япканда.

Булсам җитез аргамак,
Көмеш ялымны тарап,
Таң җилләре искәндә,
Үләнгә чык төшкәндә,
Чулпан кызым, таң йолдызым,
Чабып сиңа кайтыр идем,
Гөлләр хуш ис сипкәндә.

Юк, барсыннан да элек
Тик булса иде ирек,
Кылчым булса кынымда,
Карабиным кулымда,
Сине саклап туган җирем,
Мин ирләрчә үләр идем
Данлы сугыш кырында.

1942 ел

Биремнәр

1. Шигырьдәге строфа үзенчәлеген әйтегез.
2. Әсәргә анализ ясагыз.

Габдулла Тукай

Ай һәм Кояш

Һималая тау өстендә алтын бишек,
Кояш йоклый һәр кич саен шунда төшеп;
Җил төн буе йоклаганын саклап тора,
Тирбәтә һәм өстен-башын каплап тора.

Йокысыннан Кояш ничек уяндисә[1],
Җил шулвакыт җилбер-җилбер итеп исә;
Исә-исә бөтен дөнья буе китә:
— Торыгыз! — ди,— уянырга вакыт җитә!

Торып чыккач шул бишектән Кояш агай,
Анда кереп йоклый инде энесе Ай;
Йоклый шунда йолдызлар да өелешеп,
Оядагы йоклап яткан кошчыклардай.

---

[1] Уяндисә — уянды исә.

Каты йоклап Ай бишектә мәгърибкәчә[1]
Торып чыга, көлеп җиргә нурын чәчә;
Кояш һәм Ай — ике туган агай-эне —
Менә шулай дустлык берлән нәүбәтләшә[2].

Бирем

Шигырьдәге строфа үзенчәлеген табыгыз.

Мөстәкыйль эшләр

Чишмә

(Миф)

Күлнең тау битендә яшәвен күргәннән соң, Җил аңа мәсьәлә чишәргә куша. Мәсьәләне чишә алмыйча, гарьлегеннән елавын күргәч, Җил Күлдән:

— Үзем чишеп биримме? — дип сорый. Күл: «Чишмә!» — дип җавап бирә. Җилнең моңа хәтере кала, һәм ул Күлгә Чишмә кушаматы тага. Күлгә бу кушамат бер дә ошамый. Шуңа күрә ул таудан түбән таба чаба. Ләкин кушаматыннан шушы көнгә кадәр аерыла алмый.

Бирем

Мифның кыска матур, ритмны саклап әйтелгән җөмләләрен юри авырайттык. Паузаларны, ритмны төшереп калдырдык. Текстны кыска җөмләләр белән җиңел укырлык итеп яңадан языгыз.

* Белгән **укыр**, белмәгән ... .
* **Кыскалыкта** — ... .
* **Сабыр** төбе — ... алтын.
* Кеше холкын **күзәт**, үзеңнекен ... .

---

[1] Мәгърибкәчә — кояш баткангача.
[2] Нәүбәтләшә — чиратлаша.

Биремнәр

1. Мәкальләрне тәмамлагыз. Сез табасы сүзләр калын хәрефләр белән бирелгән сүзләргә рифмадаш. Мәкальләрне үзегез тапкан җаваплары белән дәфтәрләрегезгә язып куегыз.
2. Беренче мәкальне үзебезчә болай әйтеп була: укымышлы бала мин беләм дип мактанып йөрми. Күбрәк укыган саен, үзен аз белүче дип саный. Шуңа күрә күп сөйләми, укый да укый. Ә белемсез бала берни белмәсә дә сөйли дә сөйли. Башкаларга акыл сата.
3. Калган дүрт мәкальне үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.

Шәүкәт Галиев

Файдалы җиләк

Әнкәй әйтә:
— Җәй көне,— ди,—
Җиләк ашарга кирәк.
Елмаеп кына торырсың —
Бик файдалы ул җиләк!

Бер стакан җиләк алды
Бүген баргач базардан.
Файдалырак булыр иде,
Нигә инде аз алган...

Трамвайда ашап кайтам,
Бөтен кеше кызыга.
Мөлдерәп утыра әнә
Бер апаның кызы да.

Беләм инде, күрәм инде,
Авыз сулары килгән.
Ымсынып калмасын диеп,
Аңа да бераз бирәм.

Кыстаттырып торган булды,
Үзе барыбер алды.
Җиләкне кабу белән үк
Шундый матур елмайды!

«Тәмле! Тәмле!» — дия-дия,
Бик тиз чүпләп бетердек.
Стакан төбе күренгәч,
Бергәләшеп, бер көлдек.

Әнкәй бигрәк дөрес әйткән,
Җиләк ашарга кирәк —
Бөтен кешене елмайтты,
Файдалы икән җиләк!

Биремнәр

1. Шигырь строфаларының үзенчәлеген әйтегез.
2. Шигырьгә анализ ясагыз.

Йомгак ясыйк: тезмә әсәр бөтенлеге темасын өйрәнүне тәмамлыйбыз. Бу теманы өйрәнгәндә, без ниләр белдек? Шуларны гомумиләштерик.

Өйрәнгән лирик шигырьләрнең барысының да эчтәлеге хис булуын белдек. Шигырьләрдә вакыйгалар да, төп геройның холкы да күренмәде. Лирик шигырь өлешләренең үзара бәйләнешкә исләре китми. Алар, көнбагыш чәчәкләре кояштан күзләрен алмаган кебек, бар да бер үзәккә карап торалар. Аларның күз нурлары лирик герой хисенә килеп тоташа. Шул ноктада төрле-төрле өлешләрнең мәгънәләре ачыла.

Тезмә төр әсәрләрнең үзенчәлеге шунда: аның эчтәлегендә хис ята, һәм хис тудыручы өлешләрне җыеп торучы рифма, ритм, кабатлану кебек чаралар да бар.

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Чәчмә әсәрләр турында сөйләгәндә, алар сөйләм теле белән язылган, диләр. Аларда рифма да, строфалар, иҗек тәртипләре дә юк. Чәчмә әсәрләрдә дә, лирик герой кебек, үзе турында һәм күргән-белгәннәре турында сөйләүче персонаж бар. Ләкин хәзер без аны **хикәяләүче** диячәкбез.

Әдәбиятның бу төркеме дә жанрларга бүленә. **Хикәя** жанрына бер генә вакыйгалы әсәрләр керә. Ике-өч вакыйганы эченә алган чәчмә әсәрләргә — **повесть,** ә күп вакыйгалы, күп персонажлы мөһим темага багышланган әсәрләргә **роман** диләр. Бу төргә шулай ук **истәлекләр** һәм **юлъязмалар** да керә.

Вакыйга чәчмә әсәрләрнең бик мөһим берәмлегеннән санала.

Әсәрләрдәге вакыйга — кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, хисләр хәрәкәте ул. Мөнәсәбәтләр, кискенләшеп, хиснең дәрәҗәсен арттыралар. Киеренкелек, артаарта, каршылыкка әйләнә. Каршылык кискенләшкән саен, персонажлар хисенең дәрәҗәсе үсә бара. Киеренкелек иң югары дәрәҗәсенә җиткәч, мәсьәлә йә уңай якка, йә кире якка чишелә.

Вакыйгалар хәрәкәтенең исемнәре дә бар: киеренкелек туа гына башлаган өлешкә сюжетның **үстерелеше** диләр, киеренкелек конфликт дәрәҗәсенә җитсә, ул — **кульминацион нокта**, ә чишелсә, аны **чишелеш** дип атыйлар.

Хикәя, повесть, романнардагы менә шундый вакыйгалар җыелмасы **сюжет** була.

ӘКИЯТ СЮЖЕТЫ

Чәчмә әсәрләр дип, беренче чиратта, әкиятләрне атыйбыз. Әкият сюжетының үзенчәлеген карап үтик.

Акыллы Каюм бабай

(Әкият)

Берзаман бер бай Каюм бабай янына килә дә акыл сорый:

— Каюм бабай, киңәш бирсәң иде, тиз генә баю өчен нәрсәдән күбрәк табыш алырга мөмкин? — Бабай әйтә:

— Һәй, бик җиңел эш ул,— ди.— Көз көне бик күп итеп каз сатып ал. Барысын да какла. Язын базарга чыгарып кыйбат бәягә сатарсың,— ди.

Бай бабайның киңәшен тыңлый. Күп итеп каз сатып ала да каклап элеп куя. Аннары аларны, яз җиткәч, чыгарып сата. Казларыннан бик яхшы табыш ала.

Баеп алгач, байның борыны тагын да югарырак күтәрелә. Бабай янына тагын килә бу.

— Әй, Каюм дивана, тагын нәрсә белән табыш алыйм, өйрәт,— ди.

— Һәй, ул бик җиңел эш. Көзен күп итеп суган белән кишер сатып ал. Икесен бергә катнаштырып базга сал. Яз башында кишер дә, суган да кыйбат була. Базарга чыгарып сатарсың. Табышың күп булыр,— ди.

Бай шулай эшли. Суган белән кишер сатып ала. Катнаштырып, базына сала. Яз башында базын ачса, ни күрсен: суганы да, кишере дә черел беткән.

Байның бик каты ачуы килә. Ул тагын бабай янына бара.

— Бабай, мин синнән акыл сорадым,— ди.— Башта әйбәт акыл бирдең, икенчесендә тиле акыл бирдең. Шуның аркасында бөлдем. Бөтен малым китте,— ди.

— Бабай кеше яхшы акыл бирә, дивана кеше дивана акыл бирә, үзеңә үпкәлә,— дип җавап бирә бабай.

Биремнәр

1. Вакыйганың тәмамланган хәрәкәт булуын искә төшерик. Байның Каюм бабай киңәше белән табыш алуы — шундый дәвамлы хәрәкәт. Бай киңәш сорый — Каюм бабай киңәш бирә — бай, аның киңәшен тотып, мул уңыш ала. Хәрәкәт тәмамланды.

2. Әкият сюжетын вакыйгаларга бүлик. Ике вакыйга арасындагы бәйләнешнең каршылык булуы күренеп тора. Ләкин алар икесе ике вакыйга түгел, бербөтен сюжет. Ни өчен шулай? Исбат итегез.

Шомбай

(Әкият)

Бер бай күрше авылга хезмәтче эзләргә чыга. Капкага сөялеп торган бер егетне күрә.

— Иптәш, ди, сезнең авылда хезмәткә керүче булмас микән? — ди.

— Булыр, без үзебез өч агай-эне, хакын бирсәң, мин үзем үк керермен. Хакы ничек булыр соң? — ди егет.

Бай әйтә:

— Эшнең хакы шулай булыр: минем өй артымда шомырт агачы бар, шул шомыртка сандугач килеп сайраганда, ике йөз тәңкә, ди. Тик, ди, бер дә рәнҗештән булмасын, рәнҗесәң, ике йөз тәңкә үзең түләргә,— ди.

Ярар, килешәләр дә кайтып китәләр болар. Төн куналар да иртә белән чыгалар борчак сугарга. Борчакны ике җәем сугалар да бай хатыны көндезгегә аш әзерләргә керә. Бераздан чыгып кычкыра:

— Ашау җитте! — ди. Өйгә керсәләр, өстәл тулы нигъмәт. «И, болай булгач, эшләр бик шәп»,— ди егет. Бүлмәнең теге ягында бер сабый бала елый башлый.

— Син, егет, ди, кулың да юмаган бугай әле, минем малайны өйалдына алып чыгып, тәпиен генә тотып кер әле,— ди бай.

Ярар, тәпиен тота торгач, бик озак утырды бу малай. Бетереп керсә, өстәл өстендә бертөрле дә ризык калмаган. Бу, сөмсерләре коелып, өстәлгә таба карап утыра. Бай моңа әйтә:

— Нигә сөмсерләрең бик коелды, миңа рәнҗедең мәллә? — ди.

— Бәй, рәнҗемәскә, ди, мин сезнең белән бергә эшләдем бит,— ди. Бай әйтә:

— Алай рәнҗесәң, бир ике йөз тәңкәңне, кайт өеңә,— ди.

Бу кайтып китә инде. Болар өч агай-эне иде бит.

— Нишләп бик тиз кайттың? — диләр.

— Үзегез барып карагыз әле,— ди. Уртанчы малай да барып, шулай алданып кайта. Хәзер кече уллары Шомбай бармакчы була.

Килә теге бай:

— Сезнең авылда хезмәткә керүче булыр микән? — ди.

— Хакны яхшы бирсәң, үзем үк керермен,— ди Шомбай.

— Хакы, туганкай, ди, сандугач сайраудан. Сайраган саен ике йөз тәңкә алырсың. Бәхетле булсаң, бер көннән ук сайрар, иң бәхетсез кеше булсаң да, бер айдан калмый,— ди.

Бу егет әйтә:

— Ике йөз тәңкә айга бик күп бит ул, барам,— ди.

Китәләр болар. Борчакның ике җәемен сугалар. Өченче җәемдә бай әйтә:

— Син көндезге ашка ризык әзерлә,— дип, хатынын өйгә кертә.

Ярар, керә, бик яхшы итеп әзерли ашарга, эндәшә боларны. Эндәшкәч керәләр, керсәләр, өстәл өсте ризык белән тулган. «И, ди, абыйлар шундый рәхәттә тора белмәгәннәр бит»,— ди егет.

Ярар, кулын юып керим дисә, теге бала тагы елый. Бай әйтә:

— Туганкай, ди, синең кулың юмаган бугай, син шуның тәпиен генә тотып керсәнә,— ди.

Тәпиен тотарга чыга. Малай бик озак утыра.

— Юк, малай,— ди егет,— абыйларны да шулай җәфалагансың син,— ди. Малайны ишегалдында калдыра да керә. Малай елый башлый. Байлар ирлехатынлы икесе дә йөгереп чыгалар. Чыгалар да хәйран калып тик торалар.

— Нигә шаккаттыгыз? — ди.

— Бәй, ди, балабызны кыйнагансың бит! — ди.

— Әллә рәнҗисезме? — ди.

— Бәй, рәнҗемәскә... — ди бай.

— Рәнҗесәң, ике йөз тәңкәне бир әле монда,— ди.

Ярар. Хәзер болар киңәш итәләр:

— Бу егетне нишләтик микән? — диеп. Хатыны әйтә:

— Ике ат белән чирәм ертырга җибәрик, ди, атын ташлар да кайтып китәр авылына,— ди. Бай әйтә:

— Егет, ди, җитен чәчәсе җирне сукалап ташлыйк микән әллә? — ди.

— Ярар,— ди егет.

Бик усал ике ат җигәләр дә китәләр болар яңа җир ертырга. Җирне ун сажин иңенә, алтмыш сажин буена итеп ерып ала да бай әйтә:

— Шушыны кичкә хәтле сукалап бетереп кайт,— ди.

Ярар. Теге бай ике атны моңа куеп кайтып киткәч тә, Шомбай ике атны да суеп, тиреләрен тәртәгә кип-терергә элә. Үзе ял итеп карап ята.

Бай җиренә килеп җитсә, ике тирене күреп хәйран кала.

— Егет, синең нишләвең бу? — ди.

— Менә шулай эшләвем, ди, әллә рәнҗисеңме? — ди.

— Рәнҗеми нишлим? — ди.

— Кая, бир әле ике йөз тәңкәне,— ди.

— Карчык, нишлибез? Бөлдерә бит бу безне,— ди бай.

Хатыны талый торган айгырга башак бирдерергә куша. Бай әйтә:

— Улым, әнә анда безнең бер айгыр бар, аңар бер чиләк су бир, тәмле генә итеп башак болгат,— ди.

Ярар. Шомбай ике чиләк су алып кайта да келәт-тәге бөтен онны утарга сибеп бетерә. Утарда булган атларны, сарыкларны ачып чыгара, барысы бергә ашарга тотыналар. «Инде бу беткәндер»,— дип чык-салар, атлар, сыерлар, сарыклар — бар да камыр ашый-лар. Шомбай үзе кырыйдан карап тора. Ярар. Теге, хәйран-вәйран булып, амбарга кереп караса, бер чеметем он да калмаган, барын сибеп бетергән. Бу егет әйтә:

— Ник болай бик хәйран булып торасың? — ди.

— Балам, соң иртәгә нәрсә ашарбыз, бер тамчы да он калдырмагансың бит? — ди бай.

— Рәнҗисеңме әллә син, бай? — ди.

— Рәнҗемәскә, дөнья көтмәгәнлегең әллә каян билгеле бит,— ди.

— Рәнҗесәң, ике йөз тәңкәңне бир әле монда,— ди.

Ярар. Көндезге чәйне эчәргә утыралар. Чәй эчкәндә, шомыртка кунып сандугач сайрый.

— Әнә, улым, шомыртта сандугач сайрый, елың тулды, бәхетле бала икәнсең,— ди.

— Бәй, ул сандугач нинди була икән? — дип барып караса, байның унсигез яшәр кызы, шомыртка менеп, сандугач булып сайрый икән. Бу егет кызны сөйри дә төшерә шомырттан.

— И балам,— ди бай,— баламны харап иттең бит,— ди.

— Әллә, бай, рәнҗисеңме син, ди. Рәнҗесәң, ике йөз тәңкәңне бир әле монда, мин кайтам инде,— ди. Әллә нихәтле акча алып кайтып китә өенә.

Биремнәр

Түбәндәге анализ нәтиҗәсен исбат итегез.

1. «Шомбай» әкиятендә дә, «Акыллы Каюм бабай» әкиятендәге кебек, ике вакыйга бар. Алар бер-берсенә ялганганнар һәм шул ук вакытта капма-каршылар. Сюжет әнә шул каршылыкта торган бөтенлектән гыйбарәт.

2. Әкиятләрнең икесендә дә яманлык җәзасын ала (сәбәп — нәтиҗә бәйләнеше).

ӘДӘБИ ӘСӘР СЮЖЕТЫ

Әсәрдәге вакыйгаларның, бер-берсенә ялганып, эзлекле агышына **сюжет** диләр. Ләкин вакыйганың агышында үзенчәлек бар. Башта ул салмак кына кузгала, аннары хәрәкәтен тизләтә, бик тиз хәрәкәтләнә дә кинәт туктап кала. Сюжет хәрәкәтен ачыклап кына әсәрнең эчтәлеген белеп булмый. Ләкин автор табышы анда да була ала.

Шул үзенчәлекне хикәяләрдә күзәтик.

Татар халкының бөек шагыйре Һади Такташ пьесалар да, хикәяләр дә иҗат иткән. «Хикәя нинди булырга тиеш?» дигән сорауга ул зур мәкалә белән җавап биргән. Мәкаләсендә хикәя жанрының үзенчәлеген болай аңлаткан.

Һади Такташ

Хикәяне ничек язарга?

(Өзек)

Хикәянең эчке төзелеше нәрсәләрдән тора? Беренче — хикәянең герое, аның характеры, геройның тормышка карашы. Икенче — хикәянең сюжеты. Өченче — төп теләге. Дүртенче — буявы.

Бу саналган нәрсәләрне хикәянең төп материаллары итеп алырга мөмкин.

Инде хикәяне ничек язуга, шушы материалларны ничек файдалануга килик. Әйтик, хикәя язарга теләүченең алдында бер герой, гади тел белән әйткәндә, язарга дип күздә тоткан кешесе бар. Ул кешенең үткән тормышы аңарда куркаклык психологиясе ясаган. Менә шул психологияне язучы ачып салырга тиеш. Ләкин ничек? Бездә «Батыр сугышта беленә» дигән мәкаль бар. Монда да шулай. Берәү, әйтик, авылда яши. Сука сукалый. Иген игә. Йортын карый. Вакытында ашый, вакытында эчә... Менә мондый гади тыныч аккан тормышта без бер геройның характерын тиз генә ача алмыйбыз. Без аның сука сукалаганда яки чәй эчеп утырган вакытына карап, аның батыр табигатьле, куркак табигатьле икәнен белә алмыйбыз. Шуның өчен батырның батырлыгын, куркак табигатьле кешенең куркаклыгын без бары шул табигатьләрен күрсәтерлек бер вакыйгага эченә куйсак кына күрә алабыз.

Геройларның эчке тормышларын ачу өчен бирелгән вакыйгага сюжет дип атала. Хикәя язуда сюжет зур роль уйный. Геройның сюжетка кадәр булган тыныч, гади тормышы, гадәттә, хикәянең эченә төп материал

булып керми. Ул тормышы аның ярдәмче материал гына була ала.

Хикәяләр тормышта булган вакыйгадан алынып языла. Ләкин язучы үзенең теләгенә, осталыгына карата эшли. Әйтик, бер вакыйга тормышта бертөрле була. Ул вакыйга тормышта булганынча язылса, матурлык аз була. Ләкин язучы аны шомарта. Икенче шуңа охшашлы булган вакыйгаларның аерым кисәкләреннән бербөтен сюжет төзи.

Үзеннән кайбер якларны арттыра, матурлый... Бу — хикәянең буявы дип атала.

Бирем

Һади Такташ мәкаләсен кыска итеп дәфтәрләрегезгә языгыз.

Нәбирә Гыйматдинова

Төнбоек

(Хикәя)

Җәйнең иң матур көне иде. Без чират көтүенә чыктык. «Без» дигәнем — ике малай, өч кыз. Бишебезгә дә унике-унөч яшьләр чамасы. Арада бер генә олы кеше дә юк. Шуңа күрәдер өйдәгеләр: «Карагыз аны, уен белән мавыкмагыз, көтүне дүрт яктан да ныгытып саклагыз»,— дип, колакка киртләп озатты.

Сарыклар утлыйсы болын авылдан ерак түгел, әмма без таптала-таптала үләне сирәкләнгән җирне өнәмәдек, көтүне куып, өч чакрымдагы урыс авылы ягына таба китеп бардык. Ирек тәмен сизгән күңелләр монда гына сыймый, әллә кайларга ашкына шул. Берберебез белән узыша-ярыша йөгереп кенә барыр идек тә бит, сарык-кәҗә токымын «чабуга ябыштырганнар». Сарыгы ярый әле аның, ә менә кәҗәсе... Бер карыйсың — бар ул, икенче карыйсың — юк! «Иярегез» дип нинди телдә аңлатадыр, артыннан сарыкларны да тезеп алып китә. Көтүнең бу «дошмани өлеше»н саклау малайларга йөкләтелде. Үлән чемченгәндә

башларын күтәреп тирә-якка күз тәгәрәткән хәйләкәр сакалбайларга «һайт» дип кенә кычкыра алар, тегеләр шунда ук сарыклар арасына яшеренә.

Көтү белән сәяхәт итә-итә, без бер күл янына килеп җиттек. Ул, кемнеңдер күзеннән яшеренгән сыман, бөдрә талларга уралган, тып-тын су өстендә балыклар сикерешеп уйный иде. Яр читендә иске көймә тора. Күптән урыныннан кузгалмаган бугай, төбе ләмгә баткан. Малайлар су коенабыз дип әтәчләнгән иде, ярдан ике адым атлауга кикрикләре шиңде: күл тирән иде. «Төпсез»,— диеште алар. Йөзә белүләре дә чамалы иде, күрәсең.

Сарык-кәҗәләрне куа-куа, бәлки, юлыбызны тагын дәвам итәр идек, мин күлнең нәкъ уртасында ялгыз төнбоек күрдем. Балыклар сикереп уйнаганда, койрык очы белән су чәчрәтте микән, чәчәкнең таҗларында көмеш тамчылар җемелди.

— Алып бирегез! — дидем мин, аңа бармагым белән төртеп.

Күлнең тирәнлеге дә, малайларның йөзү-йөзмәүләре дә «нипачум» миңа. Алып бирегез, бетте-китте! Арадан бер малай минем теләкне үтәргә теләде, көймәне урыныннан кузгатып, суга этеп төшерде.

— Нишлисең, аның төбе тишек! — дип кычкырдылар аңа. Чынлап та, көймә тишек, аны, мөгаен, шуңа ташлап та калдырганнар иде. Ә үзсүзле малай гүя тавышларны ишетмәде, көймә эченә сикерде.

— Тукта дип әйт, кермә дип әйт, бата бит хәзер, бата! — диде кызлар, мине күлгә таба эткәләп.

— Юк, алып бирсен төнбоекны! — дидем мин, аяк тибеп.

Сарык-кәҗә онытылды, энеләрнең кисәтүе җилгә очты, без яр буена җыелып тамаша кыла башладык. Малай кулы белән ишә-ишә эчкә кергән саен, көймә тишегеннән саркып су тула иде. Их, борыл диясе иде дә... Шулай дип эчемнән генә кычкырам да инде: «боры-ыл!» Эчемнән генә шул, тыштан сиздермим:

көлемсерәп басып торам. Күлнең уртасына җиткәндә, көймә яртылаш су «эчкән» иде инде, көтүдәшләрем миңа кырын-кырын карап куялар, янәсе, таш бәгырь икән син.

Малай, ниһаять, үрелеп төнбоекны өзде. Аңа ярдагылар:

— Тизрәк кыймылда, батасың! — дип акыралар. Көймәне, чынлап та, күл төпкә суыра. Кемдер шатыр-шотыр тал чыбыгы сындырырга кереште, кемдер бау кисәкләре табып килде. Алай-болай була калса, тал-чыбыкларны ыргытып, бау сузып батырны коткарырга уйлыйлар.

Шунда гына минем йөрәккә курку оялады. Төнбоек өчен кеше батып үлсә, бөтен авыл сиңа нәфрәт белән караса... Без бит инде яхшы белән яманны аерыр яшьтә.

Батыр малай бата-чума барыбер күлдән чыкты. Аның йөзендә курку юк иде, тыйнак кына елмаеп төнбоекны миңа сузганда, безнең карашлар очрашты да, ул кызарып күзләрен түбән иде...

Ә кәҗә-сарык, яр буендагы ыгы-зыгыдан файдаланып, авылга элдергән. Шаккаткан халык: әле моңарчы кояш чәчрәп торган көн үзәгендә көтү кайтканы булмаган.

Биремнәр

1. Хикәядәге сюжет үсешен сөйләгез.
2. Төп герой чәчәк өзүче малаймы? Хикәяләүче кызмы, аларның иптәшләреме?

Андрей Платонов

Аллы-гөлле күбәләк

(Хикәя)

Бирем

Хикәядәге вакыйгаларның сюжет булып бәйләнүенә игътибар итегез.

Кара диңгездән ерак түгел, Кавказ таулары ярдан күккә кадәр күтәрелә торган урында Аниса исемле карчык яшәгән. Аның таштан салынган өе чәчәкле

болын уртасында урнашкан булган. Болынның аргы башында Ульян исемле умартачы карт яшәгән. Ул кешеләргә: «Мин монда килеп урнашканда, Аниса әби карчык иде инде»,— дип сөйли торган булган. Ул чакта ук әбинең ничә яшькә җитүен берәү дә белмәгән. Аниса карчык әйтмәгән, чөнки үзе дә белмәгән.

Ульян бабай Аниса карчык янына елга бер булса да килеп киткәләгән. Бал бүләк иткән, тузган аяк киемнәрен, йорт түбәсен төзәткән.

Алар, ташка утырып, әңгәмә корырга яратканнар. Бер-берсенең хәл-әхвәлләрен сорашып, күңелләрен бушатканнар.

Соңгы килүендә Ульян бабай әбинең күзлеген тимерчыбык белән ныгыткан.

Китәр алдыннан Аниса карчыкка:

— Безгә дигән гомернең чәнти бармак хәтлесе дә калмады. Әйдә булмаса, китик инде,— дигән.

— Юк, яшим әле. Эшем бар минем бу дөньяда. Улымны көтәм. Аны күрмичә үләргә ярамый миңа,— дип җавап биргән Аниса карчык.

— Алайса, яши бир,— дип риза булган Ульян карт.— Минем үземә вакыт җитте инде.

Шулай дигән дә кайтып киткән. Бераздан үлгән. Аниса карчык улын көтеп яшәвен дәвам иткән.

Укылган өзектәге вакыйга карт ананың баласын күрәсе килүе турында. Ул — сюжетның **башы, төенләну** өлеше.

Аның Тимур исемле улы, Аниса карчык яшь чакта ук, өйдән китеп югалган. Ул көн дә тауга менеп уйный торган булган. Ташлар белән сөйләшкән, ташлар ул әйткәнне игътибар белән тыңлап торганнар. Төрле төстәге матур күбәләкләр тотарга яраткан.

Көн төшкә авышкач, Аниса тауга карап, улын ашарга чакыра торган булган.

Улы тоткан күбәләкләрен әнисенә күрсәткән. «Нигә очмыйлар? Очмагач үләләрмени?» — дип сораган.

— Күбәләкләр очсалар гына яши алалар. Син бит тотып аларның канатларына зыян китергәнсең. Тотма күбәләкләрне. Яшәсеннәр, очсыннар,— дигән әнисе.

Тимур көн дә бер үк сукмактан китә торган булган. Аниса карчык ул сукмакның зур тауга, зур таудан болытлар оеша торган биек тауга күтәрелүен, ә биек таудан иң биек таулардан да биегрәк яман тауга менүен чамалаган. Ул шулай ук бу сукмакны юньсез кеше салуын да яхшы белгән.

Бермәлне Тимур таудан кояш баегач кына кайтырга чыккан. Тау итәгендә үскән чәчәкләр йокыга талганнар. Сукмак читендәге ялгыз ак чәчәк өстендә Тимур төрле-төрле төскә буялган бик зур күбәләк кунганын күреп алган. Күбәләк, канатларын җилпи-җилпи, чәчәктәге чык тамчысын эчәргә тотынган. Тимурның исе-акылы киткән. Канатындагы төсләрнең матурлыгы турында әйткән дә юк. Бу кадәр зур күбәләкне аның бервакытта да күргәне булмаган. Күбәләкнең озын канатлары дерелдәвеннән тирә-якка нурлар сибелгән, тавышы Тимурны үзе янына чакырган.

Тимур аңа таба кулын сузган. Ләкин күбәләк очып киткән.

Башта ташка кунган, аннары сукмак буйлап югарыга очып киткән. Ичмасам, матурлыгына карап калыйм дип, Тимур аның артыннан чапкан.

Төн җиткән. Ә Тимур күбәләк артыннан чапкан да чапкан. Күбәләк әле читкә, әле артка, әле кабат сукмак өстеннән очкан. Ләкин малай барыбер артыннан ияреп йөргән.

Кинәт ул әнисенең:

— Улым, бүген тагын соңга калдың. Әниеңне тәмам оныттың,— дип ялварган тавышын ишеткән.

— Хәзер кайтам, әни, иң-иң яхшы күбәләкне тоту белән кайтырга чыгам,— дип җавап биргән Тимур.

Тимур сукмагыннан тайпылмаган, югарыга менүен дәвам иткән. Менә ул зур таудан үтеп киткән, биегенә дә

үрмәләгән. Ниһаять, башы күккә терәлгән иң биегенә дә менеп җиткән.

Моннан күктәге барлык йолдызлар да күренә икән. Ә берсе менә монда гына, кул сузсаң, тотып алырлык кына якында җемелдәгән.

«Миңа күбәләк кирәкми, йолдыз күбәләктән дә матуррак»,— дип уйлаган Тимур.

Ул җирне тәмам онытканы. Йолдызга таба үрелгән һәм... чоңгылга егылып төшкәнен сизми дә калган.

Укылган икенче өзектәге вакыйга Тимурның китеп югалуы һәм ананың күп еллар буе улының кайтуын көтүе турында сөйли. Аниса карчыкның борчылуы артканнан-арта, ә улының анасына булган мәхәббәте, киресенчә, кими-кими юкка чыга.

Өзектә ана хисенең дәрәҗәсе артканнан-арта бара, шуның өчен бу вакыйга — сюжетның **үстерелеш** өлеше. Үстерелеш өлеше укылган ике өзектә тәмамланды.

Таң аткач, як-ягына караган: тар гына елга, елга ярында куак, ә тирә-якта таш стена урап алуын күргән. Таш стена күккә кадәр күтәрелгән. Аның өстенә күбәләк булсаң гына менәрлек икән.

Кая карама — таш та таш. Аста эссе, күңелсез. Әрле-бирле эре күбәләкләр оча икән. Ләкин малай аларга әйләнеп тә карамаган.

— Әни! — дип кычкырган да елап җибәргән. Аннары стена төбенә утырган да ташны тырнаклары белән кыра башлаган. Шулай тишек чокып, әнисе янына кайтырга теләгән.

* * *

Чоңгылга егылып төшкәннән соң, күп еллар үткән. Малай үскән, егет булган. Югарыдан тәгәрәп төшкән бер каты ташны бүтән каты ташларга ышкып үткенләгән. Шул таш белән стенаны чокырга керешкән. Ләкин таш стена да каты икән.

Ә гомер узган да узган. Эшнең очы-кырые күренмәгән.

Таш стенаны күбрәк уткән саен, әнисенең тавышын ешрак ишеткән. «Мине оныттың, улым. Нигә китеп югалдың?» — дип кабатлаган әнисе.

Тимур әнисе тавышын ишеткән саен елаган. Аның саен ашыгыбрак чүкегән.

Улым җирдән чапкан булса, әллә кайчан кайтып җиткән булыр иде инде, дип уйлаган карчык. Ләкин улы кайтмаган. Шулай булгач, ул йолдызлар арасына киткән. Күкне әйләнеп чыкмый торып, өйгә әйләнеп кайтмаячак дип, үзен юаткан карчык улына:

— Кайтырга вакыт, улым. Нигә кирәк сиңа күбәләк, тау, күк нигә кирәк? Бар да булсын, күбәләкләр дә очып йөрсен, тау да, күктә йолдызлар да янсын, ләкин син минем янда бул. Югыйсә күбәләк тотасың, ул үлә, йолдызга кагыласың, ул тоныклана. Барсы да яшәсә, син дә яшәрсең,— дигән.

Бу вакытта улы, бөртек-бөртек чукып, тау җимерүен дәвам иткән. Тау вак-вак кисәкләргә генә кителгән. Ул артык биек булган. Шуңа күрә Тимурның гомере таш ватып узган, ул тәмам картайган.

Укылган кисәктә ана хәсрәте дә, улы хәсрәте дә арта-арта иң югары дәрәҗәгә җитте. Сюжет **кульминацион ноктасына** күтәрелде.

* * *

Ә беркөнне, ниһаять, аръякта чиләк чылтыраган тавыш ишеткән. Таныш чылтыраудан әнисенең суга килүен белгән. Ишетелсен өчен, җан көченә кычкырган.

Суга килгән кеше чыннан да әнисе булган. Әнисе тавышны ишеткән, ләкин улы тавышын танымаган.

— Син кем? — дип сораган карчык.

— Әни, мин үземнең кем булуымны оныттым,— дип җавап биргән Тимур.

Улы, тауның соңгы ташын җимереп, яктыга, әнисе янына чыккан. Ләкин әнисен күрә алмаган, чөнки тау чоңгылында аның күзләре күрмәс булган.

Аниса карчык йөзен сакал баскан карт янына менгән. Улын кочаклаган да:

— Мин сине тудырдым. Ә син чыгып киттең. Мин бит сине иркәләргә дә, тәрбияләргә дә өлгермәдем,— дигән.

Тимур кечкенә хәлсез әнисенең кочагына кергән. Йөрәгенең тибүен ишеткән.

— Моннан соң гел яныңда булырмын, әни! — дигән.

— Картайдым шул инде, улым. Мин сине гасыр ярым көттем. Тиздән үләчәкмен. Ичмасам, сине күреп тә туя алмый калам,— дигән.

Әнисе улын күкрәгенә кысып кочаклаган. Гомеремнең бөтен сулышы улыма күчсен, аңа булган мәхәббәтем улыма көч бирсен, гомер бирсен, дигән.

Теләген әйтеп бетерүе белән, улы җиңеләйгәннән-җиңеләя барган. Кечерәйгән. Күбәләк эзләп киткән малайга әйләнгән. Әнисе аны элеккечә кулына алып иркәләгән.

Карт ана соңгы бәхетле сулышын алган. Улын ялгыз калдырып, теге дөньяга киткән.

Хикәядә ана белән ул күрештеләр. Киеренкелек бетте. Күрешү вакыйгасы сюжетның чишелеш өлеше булды.

Биремнәр

1. Малайның холкына бәя бирегез.
2. Аниса карчык сыйфатларын әйтегез.
3. Автор хикәясендә ана мәхәббәтенең көче турында яза. Мәхәббәт дәрәҗәсен сурәтләү өчен, дөньяда булмый торган вакыйгалар уйлап таба. Һади Такташ әйткән әнә шул «буяу»-ларны табыгыз.

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ЭЧТӘЛЕГЕНДӘ ХИС

Әкият эчтәлегендәге хис

Коштай

(Әкият)

Күптән, бик күптән бер бабай белән бер әби яшәгән. Икесе дә миһербанлы, яхшы күңелле кешеләр булганнар.

Кышның салкын бер кичендә бабай урманга утынга киткән.

Утынын турап бәйләгән. Җилкәсенә салган. Таудан төшә генә башлаган икән, кызганыч тавыш ишеткән. Тавыш килгән якка киткән. Бераз баргач, капкынга кысылган торна күргән. Торна, канатларын җилпи-җилпи, ыңгыраша-ыңгыраша, ярдәм сорый икән.

— И-һи-һи, мескенкәй, харап була язгансың бит. Хәзер коткарам, бераз гына түз,— дигән бабай һәм торна аякларын капкыннан ычкындырган. Торна тозактан котылгач, канатларын кагынган да очып киткән. Үзе оча, үзе, шатлана-шатлана, нидер каңгылдый, ди.

Биремнәр

1. Укып чыккан өзекне үз сүзләрегез белән сөйләгез. Аннан соң кыскартып сөйләгез. Исем уйлап табыгыз.

Бабай өенә кайткан. Әби белән бергәләп, чәй эчәргә утырганнар. Шулчак кемдер ишек шакыган.

— Төн уртасында кем булырга мөмкин бу? — дип сукранган бабай. Ишеген ачып җибәрсә, каршында апак карга күмелгән бик матур кыз басып торганын күргән.

— Адаштым. Бик куәтле буран. Юл күренми,— дигән кыз.

— Кер, кызым, кер,— дип чакырган әби.— Без кунакларны яратабыз.

— Урамда бик салкын, туңгансыңдыр. Кер, әйдә, мич каршына утыр. Җылынырсың,— дип өстәгән бабай.

Кунак кыз өйгә кергән, мич каршына утырган.

— Исемең ничек, кызым? — дип сораган әби.

— Минем исемем Коштай, әби.

— Бигрәк матур исем икән — Коштай,— дип мактаган әби.

Ягымлы кыз хуҗаларга ошаган.

Икенче көнне, китәргә җыенгач, әби белән бабай:

— Безнең балабыз юк. Ялгыз яшибез. Монда бөтенләйгә калмассыңмы, кызым? — дип ялынганнар.

2. Бу өзеккә дә бер яисә ике генә сүзле исем уйлап табыгыз.

Кыз да ятим бала икән. Әби белән бабай янында калырга бик шатланып риза булган.

— Яхшылыгыгыз өчен үзегезгә матур келәм тукып бирермен. Тик бер генә шартым бар: келәм тукыганда, ул бүлмәгә керә күрмәгез,— дигән.

Кунак кыз бүлмәсенә бикләнеп тукый башлаган. Өч көн тукыганнан соң, әби белән бабайга төрелгән тукыма чыгарып биргән.

— Минем мондый матурлыкны гомеремдә дә күргәнем юк! — дип шатланган әби.

Бабай кызга карап алган да борчылган.

— Бик йончыган кебек күренәсең, кызым,— дигән.

Ул арада келәмнәр сатып алучы кеше — Ким килеп кергән. Әби кулындагы йомшак гүзәл тукыманы күргәч, аның күзе дүрт булган.

— Ай-яй кызыгыз оста икән! — дигән. Әбигә берничә алтын тәңкә биргән. Әби белән бабайның алтын акчаны күргәннәре дә булмаган. Алтын тәңкәләр кояш кебек ялтырыйлар, тимердән дә авырлар икән. Әби белән бабай кунак кызга рәхмәт әйтеп туя алмаганнар.

— Бик зур рәхмәт сиңа, кызым Коштай. Мондый акчалар белән кешечә яши башлаячакбыз хәзер,— дигәннәр.

3. Әкиятнең алдагы өзекләрен дә кушып сөйләгез. Соңгысына исем куегыз.

Яз җиткән. Карлар эрегән. Кояш җылыта башлаган. Коштай авыл балалары белән дуслашып өлгергән. Балаларга Коштай белән уйнау кызык, күңелле булган. Алар бергәләп уйнаганнар, көлгәннәр. Ләкин беркөнне келәмнәр сатып алучы Ким тагын килеп чыккан. Ул бу юлы да шундый ук келәм сораган.

— Сорама да, кызыбыз келәм тукып бик арый,— дигән бабай. Ләкин Ким аның учына алтын тәңкәләрне көчләп салган.

— Акча тагын да күбрәк бирермен. Ләкин хәзер сатмасаң, бүтән берне дә алмаячакмын,— дип куркыткан.

— Башка зур хәсрәт килде. Инде ни эшләрбез? — дип хафаланган әби белән бабай. Ләкин аларны Коштай тыңлап торган икән.

— Борчылмагыз. Тагын берне тукып бирермен! Тик монысы соңгысы булыр. Үтенеп сорыйм, зинһар өчен, мин эшләгәндә бүлмәгә керә күрмәгез,— дип, тагын бер тапкыр кисәткән.

Коштай бүлмә ишеген япкан да икенче келәмен тукырга керешкән. Туку машинасы көн эшләгән, төн эшләгән. Өч көн үткәч, Ким тагын кергән.

— Йә, миңа дигән келәм өлгердеме? Күрсәтегез! Кая ул?

Ким тавышына әби белән бабай сискәнеп киткәннәр.

— Күрсәтергә ярамый! Бүлмәсенә кермәскә кушты! — дигәннәр.

— Кушмаса кушмас! — Ким бүлмә ишеген көч белән ачып җибәргән. Бүлмәгә караган да хәйран калган: анда кыз урынында торна утырганын күргән.— Торна, тор-рна! — дип кычкырып җибәргән Ким.

Чыннан да, туку машинасы янында торна утырган була. Торна, канатларын җәеп, борыны белән канат астындагы йомшак каурыйларын, мамыкларын йолкып, шул каурый-йоннардан келәм тукый икән.

Икенче көнне әби белән бабай әлеге бүлмәне ачып карасалар, бүлмә тып-тын. Анда беркем дә юк. Туку

станогында күзнең явын алырлык keлəм ята. Тирəюньдə торна мамыклары чəчелгəн...

Кичкə таба урамда балалар əби белəн бабайга:

— Әби, бабай, чыгыгыз тизрәк, монда килегез! — дип кычкырганнар.

Әби белән бабай чыгып күккә карасалар — торна! Бабай коткарган торна! Каңгылдый, өй өстендә әйләнеп оча. Каурыйсыз канатларын җилпеп көч-хәл белән оча...

— Коштай, безнең Коштай! — дип елап җибәргән әби.

Әби белән бабай торнаның кунак кыз Коштайга әйләнүен хәзер генә аңлаганнар. Үзләрендә калдыра алмаулары өчен үкенеп бетә алмаганнар.

— Коштай, торна! Китмә, китмә!

Ләкин торна соңгы тапкыр кычкырган да кояш баткан якка очып югалган.

4. Өченче өлешкә дә исем уйлап табыгыз.

5. Бабай белән әби ни өчен хәсрәтләнәләр?

Хикәяләр эчтәлегендәге хис

Марсель Галиев

Чатыр тау җиле

Исәнме, мәгърур тау!

Туган як тәхете Чатыр тау, исәнме!..

Менә тагын сиңа килдем. Сагынып килдем дә сокланып карап торам.

Янәшәдәге дулкын-дулкын тауларга басып меник әле синең иреңә.

И бу җиһанның гадел минутлары...

И бу җанның убылыр упкыннары...

Чатыр тау җиле үзе янына кешеләр менгәнне нинди ярата, зарыгып көткән була: уйнаклап килеп кочаклап ала да шатлыгыннанмы — әле елый, әле көлә. Аннары үлән өстендә мәтәлчек ата... аягыңа сөт тешле көчек

булып сарыла, куенына кереп, суык борынлы песи булып мырылдый, сабый булып чәчеңне тузгыта, йолыккалый. Юк, мондый җил, мондый да саф җил бүтән беркайда да исми. Рәхмәт сиңа, Чатыр тау җиле, күңелдәге юшкынны тараткан өчен мең рәхмәт сиңа!..

Шушы тауның текә маңгаеннан торып, күпме шагыйрьләребез Стәрле, Ык буе тугай-кырларын тамаша кылдылар. Андагы хозурлыклар!.. Балыклары сикереп чыгып арба тәгәрмәченә урала торган күлләреме, еракларга китәсе килмичә, борылып кайта-кайта, тау куеныннан иркәләнеп-иркәләнеп аккан елгаларымы, билгә каеш итеп урарлык йөгерек юлларымы, аяк тавышын ишетүгә, үлән арасына поса белгән мут-кызыл җиләкле аланнарымы, мөгезләре белән муенын кашый-кашый, ыспай гына атлап су эчәргә төшкән пошиларымы, саллы имәннәр кырыенда чытлыкланып бөтерелгән көяз каеннарымы — бу ганимәтләр шагыйрь каләме кытыклавын көтеп тын калганнар...

Саубуллашыр алдыннан күңел доганны укы да, иелеп, тау маңгаен сыйпап ал. Күпне күргән олпат таулар да юатуга мохтаҗ...

Ераклашкач, Чатыр тауга соңгы тапкыр борылып кара син. Тик бер генә тапкыр борылып күз сал. Олы юлга фатиха алып чыкканда капка төбендә озатып калган әниеңә дә шулай бер генә тапкыр борылып, кул болгый идең бит. Күз яшеңне күрсәтмәс өчен...

Йә, хуш, Чатыр тау!..

Бәхетем дә, ләхетем дә синдә булсын, туган җир...

Ә син, эчкерсез тау җиле, яшеннәр оясын туздырып уйна шулай, без кешеләр уенына кызыга күрмә, илаһи биеклектә кал!

Ярабби...

Искәрмә. Чәчмә әсәр итеп иҗат ителгән бу шигырьнең авторы танылган язучы Марсель Галиев Чатыр тау итәгендәге Азнакай районы Балтач авылында туган. Чатыр тау — Татарстанның иң биек тавы. Шуңа күрә Марсель Галиев өчен бу мәһабәт тау — дөньядагы иң матур тау, чөнки туган иле тавы.

Чатыр тау, астан торып караганда, күз явын алырлык матур. Ләкин ул искиткеч тыйнак та. Үренә менүчеләрне җиле белән иркәләп каршы ала да үз тирәсендәге матурлыкны күрсәтә башлый. Болытларга күз төшерегез әле: алар монда сезнең баш очыннан гына йөзәләр. Мондагыдай гүзәл болытлар башка бер җирдә дә юк. Туган як болытлары алар. (Ә хәзер җирдәге матурлыкка күз салыгыз, диләр.)

Марсель Галиев шул турыда яза. Туган илгә булган мәхәббәтен туган җирнең бер генә кисәге аша ача. Аның әсәрендә Чатыр тау мәхәббәткә төрелгән туган илгә әйләнә. Автор бер генә урында да хисенең сәбәбен һәм дәрәҗәсен әйтми. Үзегез табыгыз, ди. Әйдәгез, әсәрне өлешләп өйрәник.

Әсәрдә вакыйгалар да, катнашучыларның холыклары да юк. Була да алмый, чөнки «Чатыр тау җиле» лирик жанрга керә. Рифмасыз шигырь. Рифмасыз шигырьләрнең дә үз атамасы бар. Аларны **нәсер** диләр. Димәк, нәсерне лирик шигырь итеп өйрәнәбез.

Беренче өлешне өйрәник

1. Беренче өлешне табыйк. Ул тауга менәр алдыннан тау матурлыгын күреп соклану турында. «Сагындым», «сокланам» сүзләре хис турында сөйлиләр. Ләкин сөйлиләр генә. Аларның үз эчләрендә хис юк әле. Чөнки алар төшенчәләр генә. Ә төшенчәләр нәрсәнедер атаудан һәм гомумиләштерүдән уза алмыйлар.

Менә автор безне, укучыларын, үзе белән бергә тауга менәргә чакыра.

Ияреп китәбез. Бермәлне автор туктый да як-ягына карап: «И бу җиһанның гадел минутлары... И бу җанның убылыр упкыннары»,— ди. Ул шатланамы, моңланамы, нәрсәнедер исенә төшерәме, әлегә белеп булмый. Автор сүзләре, югарырак менгән саен, җанланганнан-җанлана бара. Алар хискә төренәләр, хис дәрәҗәсен арттыру өчен, бер-берсенә кушылып, барысы өчен уртак көй тудыралар.

Биремнәр һәм сорау

1. Укыган өлештә лирик герой хисенең дәрәҗәсе ничек тасвирлана?

Икенче өлешне өйрәник

Автор безгә тау җилен ничек яратуын тасвирлады. Ул сүзләрнең һәрберсе, һәр җөмлә авторның хисе турында сөйли.

2. Әсәрнең икенче өлешендә лирик герой хисенең сәбәбен әйтегез.

Өченче өлешне өйрәник

«Болытлар астындагы» иркә җил белән таныштык. Җил кочагыннан чыгарга да өлгермәдек, автор безнең игътибарны түбәнгә юнәлтте. Туган җиребезнең хозурлыгын автор күзе белән күреп исебез-акылыбыз китте. Марсель Галиев андагы матурлыкка хисләрен учлап-учлап сибә диярсең. Безнең дә елгалар, юллар күргән бар. Күлләрдә балыклар да тотып караган бар. Ләкин беребезнең дә тотыгыз безне дип тәгәрмәчкә урала торган балыкларны, кире әйләнеп кайта торган елганы, билгә каеш итеп урарлык юлларны күргәнебез булмады. Әнә нинди була икән ул туган ил — күрә, тоя белгән кешегә!

3. Лирик геройның теләген әйтегез.

Тау башындагы җил исә торды. Үзен яраттырды. Хәзер аңарга җирдәге матурлык тудырган хис өстәлде. Автор өстәлгән хисен ничек сурәтләгән?

Соңгы өлешне өйрәник

Нәсернең соңгы өлешендә автор безне түбәнгә — җиргә төшерде. Чатыр тау белән хушлашканда, аның күңеле тулды. Матурлык күреп төштек бит, ни өчен күңеле тулды икән?

Бергәләп уйлыйк. Автор Чатыр тауны аналар белән янәшә куйды. Туган ил дип атады. Иң соңыннан безгә әйтәсе төп теләген җил образы аша җиткерде.

Безнең туган илебез шундый ямьле, күңелебезгә шундый якын. Ул безне эчкерсез ярату белән ярата. Без дә аңа шундый ук мәхәббәт белән җавап бирсәк, таулардан төшкәндә, беребезнең дә күзебездән яшь таммас иде. Без дә бу тормышта, үкенерлек булып, түбәнгә төшмәсәк иде. Автор безгә шундый матур теләк теле.

Бирем

Нәсерне «Саубуллашыр алдыннан...» сүзләре белән башланган абзацка кадәр ятлагыз.

Әмирхан Еники

Җиз кыңгырау

(Хикәя-истәлек)

Биремнәр

1. Өзекне төп герой психологиясенә (ягъни кичерешләренә) игътибар итеп укыгыз.
2. Укыганда шулай ук каһарман кичерешләрен тасвирлау өчен автор кулланган «буяу»ны табыгыз.

Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез генә җиз кыңгырау тора. Кайчандыр, моннан бик күп еллар элек, туйга яки кунакка барган чагында, ул кара дугага тагылган килеш ат башында йөри иде. Хәзер кара дуга да юк, кара дуга белән җигелгән ат та юк, хәтта дилбегә тотып утырган хуҗа үзе дә юк, ә менә җиз кыңгырау ничектер торып, сакланып калган... Әллә нигә бер мин аны кулыма алып, әкрен генә селкеп карыйм. Җиз кыңгырау шунда ук, телгә килгәндәй, дәртле тавышын чыгара: «Зың-зиң, зың-зиң!..» Нәкъ менә кара дугада чактагы шикелле чыңлап, яңгырап китә. Гаҗәп, вакыт дигәнең дә көчсез икән бу җиз кыңгырау алдында, вакыт аны әз генә дә, ичмасам, үзгәртә алмаган. Ул элеккечә яшь, дәртле, моңлы һәм ниндидер бер могҗиза белән мине күз ачып йомганчы кырык ел артка, яшүсмер чагыма күчерә дә куя.

3. Хикәянең автор үзе катнашкан кереш өлеше җиз кыңгырау турында. Автор хикәясенә дә шул ук исемне биргән. Шуны белгәннән соң, сез нинди нәтиҗәгә киләсез?

Әйе, яхшы хәтерлим, егерме дүртенче елның җәе иде бу. Нигъмәтулла абзыкайларның яшел чирәмле иркен ихатасына килеп керсәм, ишек төбенә тарттырып куйган җигүле ат тора. Озын яллы сары ат җиз

кыңгыраулы кара дуга һәм эшлеяле[1] камыт белән читән тарантаска җигелгән.

Каяндыр болыты белән вак чебен иярде, һәм сары ат, башын селкә-селкә, ялкау гына бара башлады. Нигъмәтулла абзыкай тарантас артына киерелеп ята төште дә, тургайлар сайравына кушылгандай, «ихи-хи-хи!» дип, бер сузып куйды.

Без Сынны юлы белән барабыз. Көн бик тын, бик эссе. Ике якта да яшь игеннәр йокымсырап, оеп утыра. Иген арасыннан күзгә күренмәс чикерткәләрнең иренеп кенә чырылдавы ишетелә. Юл буендагы эт эчәгесенең кыңгырау чәчәкләре тирәсендә ак, сары, чуар күбәләкләр талпына. Ара-тирә иген арасыннан берәр кошчык пырылдап күтәрелә яки кәкре томшыклы карчыга, тычкан эзләп, түбәннән генә канат какмыйча, йөзеп кенә үтеп китә...

4. Әхтәм күргән иген, чикерткә һәм башка катнашучыларның сыйфатларында уртак як бар. Шул уртак сыйфатны табыгыз.

Үр менәбез... Сары ат йомшак юл тузанына тып-тып басып кына атлый. Абзыкай башта, ниндидер бер көйне исенә төшерергә теләгәндәй, әкрен генә сызгырырга тотынды. Аннары күзләрен яртылаш йомып, тавышын калтырата төшеп, башта авыз эченнән генә сузып, тик соңгы сүзләрен генә ачык әйтеп җырлый башлады:

И-и-и... яланнары сарылай кәрешкә-ә-ә-у[2],
Тырышлыклар кирәк лә һәр эшкә-ә-ә-у.

Мин ул чагында бик нечкә күңелле идем, бик тиз тәэсирләнә идем, шуңа ачуым да бик килә иде, ләкин нихәл итим? Менә абзыкайның сузып җибәрүе белән үк, минем күземә мөлдерәп яшьләрем дә килде. Әллә

---

[1] Эшлея — атның күкрәген әйләндереп алып ыңгырчак бавына тоташтырылган каешлардан гыйбарәт ат сбруе.

[1] Кәрешкә — чәчәк исеме. Виканың бер төре.

нинди шунда эчтәге бөтен нәрсәне бик төптән кузгата торган, бер үк вакытта бөтен җан иясен — адәмнәрне, кошларны, чәчәкләрне, бөҗәкләрне әрнеп кызганырга һәм өзелеп сөяргә мәҗбүр итә торган көй иде шул бу дәдәм көе! Һәм ул аны киң сулыш белән гаҗәп иркен, тирән, моңлы итеп җырлый белә иде. Җырлап бетергәч, тургайларны да үзенә кушылырга чакыргандай, тавышын тибрәтә-тибрәтә дәртләнеп, бер «үлү... лү... лүү» дип сузып җибәрә иде, һәм тургайлар, чынлап та аңа кушылгандай, тын, якты кырлар өстендә тагы да талпыныбрак, исеребрәк сайрарга тотыналар иде кебек.

Менә хәзер дә ул җырын әнә шулай әллә кайларгача җәелеп китәрлек итеп сузып бетерде дә, үзе дә, шуңардан әсәрләнеп булса кирәк, кәефләнеп бер көлеп куйды.

5. Бу өзек Нигъмәтулла абзый җыры турында. Җырның эчтәлеге җырчының хисе була дип өйрәндек. Ләкин җыр Әхтәм күңелен биләп ала. Нигъмәтулла абзый хисе, Әхтәм күңеленә кереп, әрнүгә әйләнә.
Әхтәмнең бик матур бер сыйфаты ачылды. Нинди сыйфаты ачылды?

Укуны дәвам итик.

Күп авыллар үткәч, ниһаять, туй үтәсе авылга «дәртле кыңгырау тавышы белән» килеп керәләр. Хуҗалар кунакларны шатланып каршы алалар.

Билгеле, шунда ук миңа да игътибар итеп өлгерделәр. Кучердан җиргә төшүемә, кода бабай:

— Бәрәкалла, бик кадерле кунак алып килгәнсез икән, рәхмәт төшсен! Әйдүк, шәкерт, әйдүк! — диде кода бабай, миңа ике кулын сузып.

Бу хәтле зурлап дәшүне ишеткәч, мин шактый каушап калдым, кызарып киттем. Бигрәк тә яшь кодачаларның, күзләрен елтыратып, миңа кызыксынып карауларын күргәч, бик уңайсызландым, әллә ничек үземне котсыз, килбәтсез, ә өс-башымны ярлы, начар

итеп тойгандай булдым... Алар мине «каладан килгән кунак» дип карыйлар инде... Ә минем кай җирем генә каланыкына охшаган соң?! Талчыбыктай нечкә, озын бер малай гына ич мин... Шулай кызарып, уңайсызланып кына мин кода бабай, кодагый әби, Хөбәйбулла кода белән күрештем, әмма кодачаларга кул сузарга көчем җитмәде.

6. Укылган өзектә Әхтәмнең тагын нинди сыйфаты ачылды?

Укуны дәвам итик.

Тамак туйдыргач, Әхтәм арт капкадан болынга, Түреш елгасы буена чыгып китә.

Башта, уйланып барудан ахрысы, ничектер тирәягыма күтәрелеп карарга да оныткнмын. Күпмедер җир киткәч, үземне бил тиңке куе үлән эчендә күреп, гаҗәпләнгәндәй тукталып калдым. Алдымда шау чәчәктән торган тип-тигез болын җәйрәп ята... Шушымыни инде ул Түреш буе?.. Хәйран калмаслык та түгел икән шул!

Мин үзем дә Дим буенда үскән малай, болыннарны күп таптаганым бар, әмма моның кебек тоташ чупчуар чәчәкле, ерып йөри алмаслык куе үләнле, тынякты болынны беренче күрүемдер. Күңелгә кинәт нур тулды, күзгә хәтта сөенеч яшьләре килде, һәм шул чакта табигатьнең кешегә газиз ана кочагыдай никадәр якын-кадерле булуын, кешенең аңа мең төрле җепләр белән бәйләнгән булуын, алай гына да түгел, кешенең бөтен хыялы-өмете, эше-гамәле шушы җылы, якты, тере сулышлы табигатьтән яралган булуын ихтыярсыз аңладым, тойдым, белдем шикелле... Болар берсе дә яңа нәрсә түгел кебек, әмма кеше йөрәгенең табигать белән мондый гомерлек тирән якынлыгын кинәт бик ачык хис итүе дә, минемчә, еш булмый торгандыр.

...Барам, туктыйм, колак салып торам. Тагын кузгалып китәм, тагын туктыйм. Үлән арасында мәш кил-

гән хисапсыз кортларга, бөҗәкләргә озак кына карап торам. Аннары күтәрелеп, ерактагы күксел киңлекләргә бер гаҗәпләнеп карыйм. Йа дөнья, нинди киң, нинди иркен син! Әмма шушы чиксез, нурлы иркенлектә, шушы иркә, назлы, йомшак табигать кочагында мин үземне нигәдер бик ялгыз тоям. Күңелемне ниндидер сәбәпсез сызлану, моңаю гел биләп тора кебек... Бөтен җанымда әллә нинди бер тирән кичереш бара... Нигә соң ул алай?!

Минем үндүрт яшьлек чагым. Мин күп уйланам, бик аз беләм. Тормыш нәрсә, бәхет нәрсә, мәхәббәт нәрсә ул?! Әйе, бу минем үндүрт яшьлек чагым. Мин гел нидер көтеп яшим. Хыялым бары киләчәктә генә... Киләчәк мине дәшә, чакыра, әллә ниләр вәгъдә итә, ләкин мин беләм: бу әле якты, томанлы рәшә[1] генә, аңа әле барып җитәсе бар...

Нәрсә ачылыр ул томан артында — миңа билгесез, мин күрмим әле аны. Менә шушы билгесезлек мине гел борчып, үртәп, җанымны ничектер ләззәтле сыкратып тора да шикелле... Күңелдә әледән-әле өмет белән өметсезлек чиратлашып туа, вакыт-вакыт үземне, кешеләрне, җирдәге бөтен җан иясен өзелеп кызгана башлыйм, берәүгә дә афәт килә күрмәсен иде, берәү дә бу якты дөньядан мәхрүм булмасын иде, дип телиялвара башлыйм. Ләкин шуның артыннан ук миндә искиткеч бер көч, дәрт, өмет кабына ки, мин бөтен дөньяны ал да гөл итеп, бөтен кешеләрне тигез, шат, бәхетле итеп, үземне исә бәхетнең җиде кат күгендә итеп күрә башлыйм. Өмет, өмет, өмет!.. Мин аңа ышанам, мин аңа табынам, мин аның өчен диңгезләр кичәргә, таулар аша сикерергә әзер торам... Менә нинди тиле, хыялый «бала» чагым бу минем!..

Шулай агым суга ияреп, йөреп шактый вакыт уздырып, ниһаять, авылга таба борылдым...

---

[1] Рәшә — эссе көндә җирдән күтәрелгән җылы пар.

Ә авылда туй. Әхтәмне кунаклар янына чакыралар. Хәзрәт никах укый. Сәдакалар өләшәләр. Өстәлгә аш-су килә. Кунаклар Нигъмәтулла абзыйны җырларга кыстыйлар. Нигъмәтулла абзый җырлый. Җырның тәэсирен Әмирхан Еники, шигырь язгандай, үзе дә хискә бирелеп яза.

Аңардан җыр көтәләр,— ул моны белә, тик җаен гына көтә... Һәм менә турая биреп, тамак кыргалап алды да, пинжәк чабуын кайтара төшеп, әз генә калтыравык нечкә тавышы белән сузып җырлап та җибәрде:

Утырдым ла көймәнең, ай, түренә,
Карадым да суларның төбенә.
Су төпкәйләрендә һич кара юк,
Хак язганны күрми чара юк.

Мәҗлес шундук тынып калды. Җыр һәркемнең йөрәген учлап алды. Кеше, мәрткә киткәндәй, сагышка, хыялга чумды. Кемгәдер яшьлеге кайтты, кемнеңдер заяга узган гомере күз алдыннан кичте, кемнеңдер күптән онытылган ярасы ачылды, әмма барысын да ниндидер бер искиткеч ләззәт-шашыну биләп алды.

Җыр бетүгә табын, аз гына өнсез торганнан соң, дәррәү хәрәкәткә килде. Әллә шатлыктан, әллә исәрләнүдән тыела алмыйча яман шауларга, көләргә тотындылар; кемдер, сүз таба алмыйча: «Әх-х, Нигъмәтулла!» — дип өзгәләнеп кычкырып куйды...

7. Әхтәмнең тагын бер матур сыйфаты ачылды: ул үзенә үзе дөрес бәя бирә алучы малай икән. Үзенә үзе шундый бәяне нинди малай бирә ала?

Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез генә җиз кыңгырау тора. Ул шул Абзан туена, Нигъмәтулла абзыкайның сары ат башында, кара дугага тагылып барган кыңгырау икән, аны миңа күп еллардан соң Мәдинә җиңгәчәй биргән иде.

Әйе, дөньяда бөтен нәрсә искерә, туза, үзгәрә, тик менә җиз кыңгырау, ни хикмәттер, һич кенә дә үзгәрми. Чак кына кагылдың исә, нәкъ теге вакыттагы

шикелле, көмештәй саф, нечкә, дәртле тавышы белән бүлмәне яңгыратып җибәрә һәм, күз ачып йомганчы, мине ундүрт яшьлек чагыма — үземә урын таба алмыйча гел борчылып йөргән, нидер сизенеп көткән иртә яшьлегемә кайтара да куя. Барысын-барысын да үтә бер ачыклык белән терелтә ул минем хыялымда... Яңгырап җибәрүенә, Нигъмәтулла абзыкайның җырын ишеткәндәй булам: «Утырдым ла көймәнең, ай, түренә...» Юк, кирәкми, искә төшермик. Иясенә калсын ул...

Хәзер инде бик күп яңа җырлар туды. Яңа гадәтләр, яңа йолалар туды. Туйларга да хәзер кыңгыраулы пар атларда түгел, ә күбрәк «Волга», «Москвич»ларга гына утырып баралар. Әмма мәңге үзгәрми торган бернәрсә калды: бу — кешенең яшьлеге, мәхәббәте! Һәркемгә килә ул, һәркем кичерә аны... Менә ни өчен җиз кыңгырау бик кадерле миңа — аның дәртле, көмеш тавышында гүя яшьлек һәм мәхәббәт саклана.

Нәтиҗә ясыйк: Әмирхан Еники төп героеның эчке кичерешләре турында яза. Ә аның эчке кичерешләре — үтә катлаулы, каршылыклы үзенә бер дөнья. Бу дөньяның үзәгендә әхлак һәм хыял ята. Нәкъ менә шул ике үзәк, Әхтәмнең барлык сыйфатларын җыеп, аны бербөтен шәхес итә. Ул — тыйнак, башкалар язмышы өчен борчыла, үзенә үзе тәнкыйть күзе белән карый торган, нечкә күңелле егет.

Әсәр Әмирхан Еникинең эчке дөньясы турында, чөнки Әхтәмнең кичерешләре ул — авторның хәтерендә сакланган егет чагындагы кичерешләре.

Ә җиз кыңгырау — әсәрнең үзәге — фокусы. Ул — үткәнне бүгенге белән ялгап торучы тылсымлы тавыш иясе.

8. Әхтәм кичерешләрен үз кичерешләрегез белән чагыштырыгыз. Сез дә алдагы көннәрдә ниндидер билгесез максатка омтыласыз бит. Сезнең дә, барысыннан да өстен булып, бик күп кешегә ярдәм итәсегез килә. Сез дә, өметегез тормышка ашсын өчен, диңгезләр кичәргә әзер.

Шул хакта ашыкмыйча гына уйланыгыз. Берәүгә дә әйтмичә, үзегезне Әхтәм белән чагыштырыгыз. Сез аңардан кайсы яктан калышасыз?

Мөстәкыйль эш

Габделхәй Сабитов

Тәүге[1] соклану

(Хикәя)

Без — биш-алты яшьләрдәге бер төркем малай — тегермән артында үрдәк оясы белән балык сөзәбез. Инеш текә кызыл ярлар арасыннан боргаланып ага. Яр астыннан саркып кына чишмә бәреп чыга. Чишмә чыккан урында суга туенган соры ком шома ефәк тарттырып куйган кебек тип-тигез. Кулың белән казып, чокыр ясасаң, аңа шунда ук сап-салкын су мөлдерәп тула. Тоткан балыкларыбызны шунда сала барабыз. Табыш чираттан. Бер салганда эләккәне миңа булса, аннары Заһрига, Таһирга, аннары башкага. Үрдәк оясы кем кулына керә — өлешеңә тигән көмешең.

Инешнең кайбер җире тубыктан, кай урыны тездән. Әмма тегермән тарта башласа, билгә үк җитә, агым көчәя. Ул чакта каядыр китеп югала ташбашлар. Без, үрдәк ояларын бер читкә ташлап, лычма су булган күлмәк-ыштаннарыбызны сыгабыз, коры урын сайлап, кояшта кызынырга ятабыз. Тирәбездә әбиләр кулы кебек бүртмәч[2] тамырлы үги ана яфрагы үсә, дымлы ярларны ука чуклы алтын сары чәчәкләр сарып алган. Давыл чәчәкләре. Өзмә — давыл чыгарасың!

Тегермән тартудан туктап, инеш агымы тынычланса, тагын үз шөгылебезгә керешәбез.

Бу юлы чират минеке.

---

[1] Тәүге — беренче тапкыр.

[2] Бүртмәч — *(диал.)* бүртеп-кабарып бүлтәйгән.

Тирәнрәк урынга тез тиңентен керәм дә үрдәк оясын, агымга каршы куеп, суга батырам. Малайлар, унбиш-егерме адым түбәнрәк китеп, шапыр-шопыр балык куа.

Йөрәгем дөп-дөп тибә.

Ни көтәм?

Дәү балык, алтын балык көтәм, һәм хәйран-тамаша!

Теләгем кабул булды. Өлешемә көмеш түгел, алтын чыкты. Әнә ул үрдәк оясы төбендә ду килеп сикерә, бәргәләнә. Саргылт тәңкәләре кояш нурында балкып-балкып китә.

Ярга чыктым. Малайларның күзе шар булды, телләре тотлыкты.

— Ә-әпләй! Бар икән бәхетең! — диләр.

Шулай булмый ни! Моңа кадәр бу инештә булганы да юк иде мондый дәү балыкның. Кайтырмын өйгә, ушын алырмын әнинең.

Мин артык дулкынланудан калтыранган кулларым белән балыкны үрдәк оясыннан тотып алдым. Тыпырдый, боргалана, ычкынып качмак була. Юк инде, бер килеп капкач!

Мин аны, үги ана яфрагына төреп, кепкама салдым да башыма киеп куйдым.

— Тукта, тагын бер генә күрсәт инде! — ди Хәниф. Күрсәттем. Озак та үтмәде, тагын килеп җиткән.

— Кая, һаман тереме әле?

— Тере булмаска, ул сиңа маерык ташбаш түгел лә,— дим. Кепкамны батырыбрак киям дә башкалар белән бергә балык куарга китәм. Тез тиңентен инешкә керүем булды, артымнан килеп, кемдер кепкамны күтәрде:

— Кая, әллә кайчан үлгәндер инде.

Шуны гына көткән икән дәү балыгым, алтын балыгым. Суга чапылдап төште дә, вәссәлам! Койрыгын да болгамады.

Хәниф, авызын иләмсез кыйшайтып, мыскыллы елмайды да һичбер сүз әйтмичә китеп барды. Мин дә

әйтер сүз таба алмыйча катып калдым. Белми идем шул әле ул чакта дөньяда хөсетлек[1] дигән нәрсәнең барлыгын. Кеше бәхетеннән көнләшүче, кеше шатлыгыннан кара көюче әчкерле бәндәләр барлыгын соңрак кына төшендем.

Ә ул чакта... Сөмсерем коелып, малайлар төркеменнән читкә китеп бардым. Берьялгызым кызыл яр итәгенә барып утырдым. Нишләгәнемне үзем дә абайламыйча, давыл чәчәге өзеп алдым. Давыл чыкмады, никтер күңелем давылланды. Башымны күтәрдем, күккә карадым, һәм кинәт шунда бөтен кайгы-хәсрәтләрем юып алгандай юкка чыкты. Күктә — биектә, зәп-зәңгәр төпсез тирәнлектә — ике генә өем ак болыт йөзә иде. Күземне томалаган мөлдерәмә томан аша нindидер сихри тамаша булып күренделәр миңа алар, ак болытлар. Моңа кадәр бер дә күргәнем булмаганмы шуларны? Бәбкә чирәмендә аунап-аунап уйнаган чакларда искәргәнем булмаганмы?

Юктыр, ахрысы, беренче күрүем шушы булгандыр. Күрдем дә күңелемне әсир иттеләр.

Ак болытлар, ак болытлар! Шул көннән соң гомерем буена юлдаш булды алар миңа. Урманнарда йөрсәм, яфракларны аралап, зәңгәр күктән эзләдем. Су коенсам, дулкыннарга чалкан ятып, һаман күккә бактым. Җырласам, җырларыма керде шул өем болытлар, ятсам — төшләремә.

...Озын иде гомер юллары. Күп дөньялар гизелде. Идел-елгада йөздем, көмеш күлләргә кармак салдым. Кара диңгез, Балтыйк дулкыннарында тирбәлгәнем булды. Хакасия далаларын, Чулым буйларын таптадым. Кайсы гына суга кармак салсам да, күңелемнең кайсыдыр төшендә яшерен өмет пыскыды: әлеге алтын балыгым килеп кабар кебек тоелды.

Капса әгәр, ни сорар идем икән аннан?

---

[1] Хөсетлек — көнчелек.

Юк, ташпулатлар, алтын таулары таптырмас идем.

— Әй алтын балык! — дияр идем мин аңа.— Берни дә кирәкми. Тик кайтар мине бала чагыма. Сөтле кычыткан шулпасына да риза булырмын, кайтар. Күрим бер шул инеш буйларын, күрим ялан тәпием эзләрен...

Инша язарга өйрәник

Хикәя белән таныштык. Хикәя эчтәлеген табарга өйрәнеп киләбез. Хәзер Габделхәй Сабитовның «Тәүге соклану» әсәрендә хис» дигән темага инша языйк.

Инша темасын белү белән, ашыгып эшкә керешмибез. Башта инша төзелешен искә төшерәбез. Инша өч өлештән: кереш, төп өлеш һәм соңгы өлешләрдән тора. Өчесе дә хис турында булырга тиеш. Шул өч өлешкә исем бирик. Бу исемнәр эшнең планы булыр. Иншаның эчтәлеге төп өлешендә ачыла. Шуңа күрә иң элек төп өлеш турында уйлыйк.

Тема хикәя эчтәлегендәге хисне табарга куша. Димәк, безнең игътибар үзәгендә хис булырга тиеш.

Без кем хисе турында язарга тиеш? Әлбәттә, төп герой хисе турында диярсез. Ләкин без бит уйларга кирәк дип сүз куештык. Уйны дәвам итик.

Кем соң ул төп герой? Габделхәй исемле малаймы, өлкән яшьтәге автормы?

Кылт итеп, Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәре искә төшә. Анда да өлкән яшьтәге Габдулла Тукай үзенең кечкенә Габдулла чагындагы хисләрен яңартып язган иде.

Габдулла Тукай әсәрендәге кебек, Габделхәй Сабитов әсәрендә дә төп геройлар икәү — малай Габделхәй һәм өлкән яшьтәге язучы Габделхәй Сабитов. Без менә шул ике кеше хисен табарга тиеш.

Эш җиңеләйде, башта — малай турында, аннары автор турында язарга кирәк дигән нәтиҗәгә киләбез. Мин ике катлы хис турында язарга тиеш икән дип, шыпырт кына нәтиҗә ясап куябыз һәм шатланабыз. Нигә шатланмаска, шактый катлаулы мәсьәлә чишә алдык бит без.

Башта малай хисен табабыз. Ә без хиснең эчтәлеге сәбәбендә булуын күптән беләбез. Сәбәпләр эзлибез.

Бергәләп балык тоту кызык бит — малай шатлана. Балык тоткач, шатлыгы эченә сыймый (хис дәрәҗәсе күтәрелде). Иптәше, көнләшеп, балыгын суга җибәргәч, Габделхәй рәнҗи, киткән балыгы өчен дә, иптәшенең хыянәте өчен дә гарьләнә, җаны әрни, ачуы килә. Хис кичерешләре, бер-берсенә өелеп, иң югары ноктага җитә (кульминация ноктасы булуын беләбез). Кечкенә Габделхәй шулхәтле хис ташкынына түзә алмыйча, Хәнифкә әллә ниләр әйтеп ташларга, ачуыннан сугышырга да күп алмас иде.

Хикәя сюжетының иң мөһим урынына җиттек. Габделхәйнең үзен тыеп калырга ихтыяр көче җитә. Давыл күңелендә генә кузгалып кала. Үче тышка бәреп чыкмый. Ак болытлар күрү белән, бу ямьсез вакыйганы гомумән оныта һәм аның күңелен яңадан шатлык баса. Аның хыялы, кара уйлы Хәнифне ташлап, биеккә күтәрелә, сабыр гына каядыр еракка юлга чыккан болытларга иярә. Һәм ак болытлар өлкән яшьтәге автор хисләрен бала чагындагы хисләренә алып китәләр.

Автор хикәясен балык тоту вакыйгасы белән башлаган иде, балык тоту вакыйгасы белән тәмамлый һәм хикәядәге ике вакыйганы алтын балык тоту теләге белән ялгап куя. Бала чакта малай алтын балык эләксә иде дип теләк тели, өлкән яшьтә дә ул шул теләктә кала. Ләкин хәзер алтын балык аңа иң зур теләген тормышка ашыру — бала чагына кайтару өчен кирәк. Өлкән яшьтәге автор бала чагын сагына. Кешенең иң бәхетле чоры — аның бала чагы, ди.

Хикәянең төп өлешен таптык. Хәзер шул эчтәлекне кыскартып, үз сүзегез белән язасыгыз гына калды.

Төп өлеш табылгач, иншаның кереш өлеше җиңел языла. Ул, гадәттә, инша темасына кыска гына итеп ачыклык кертүдән гыйбарәт. Инша темасында «хис» атамасы, әсәр исеме һәм автор бар. Иншаның кереш өлеше шуларның берсен ачыклау була ала. Хис турында язсак, хиснең эчтәлеген ничек табу турында язабыз.

Давыл чәчәге әсәргә табигать матурлыгын күрсәтер өчен генә кертелмәгән. Тагын ни өчен кертелергә мөмкин? Иншагызны сез дә, автор кебек, давыл чәчәген өзүдән башлап, давыл чәчәгендәге мәгънә белән тәмамлый аласыз.

Хикәянең исемен ачыкласак, авторның беренче шатлыгын табабыз. Ул — үзен үзе җиңүе. Ләкин икенчесен автор безгә табарга куша. Табабыз. Авторның икенче шатлыгы — ара-тирә балачактагы матур өметләр, хыяллар дөньясында яшәп алу.

Мин хикәянең авторын — Габделхәй Сабитовны яхшы беләм. Ул минем дустым иде. Шуңа күрә автор турында иншаның кереш өлешен менә болай язар идем:

* * *

«Габделхәй Сабитов искиткеч матур, гадел шәхес иде. Аның озынча, сипкелле битендә кем дә булса хәсрәт, ямансулык галәмәтен күрде микән? Аның иреннәре читләрендә һәрвакыт, теләктәшлек билгесе булып, елмаю эленеп торды. Хәсрәтле, борчулы көннәре күп булды аның. Уйчан булды, ләкин зарлана белмәде. Күп сөйләшмәде, ләкин үткен фикерне бик тиз аңлап ала иде дә шундый бер ихласлык белән рәхәтләнеп көлә иде, аңа ияреп көлмәскә мөмкин түгел иде.

Габделхәй Сабитов хикәяләрен укысагыз, аның урманга, су буена гашыйк булуын белерсез. Урман турында язса, каен яфракларының һәрберсендә аның серле елмаюын күрерсез, ул язган урман шавын үз колакларыгыз белән ишетерсез, урман иясе басып тора, дип язса, автор сүзенә, һичшиксез, ышанырсыз. Ул язган урман иясенең дөньяда булмавын беләсез, урман иясе дип, автор табигатькә мәхәббәтне атый. Моның өчен безгә, авторның үзе кебек, аз гына хыялга бирелү дә җитә.

Габделхәй Сабитовның табигатькә мәхәббәте әнә шулай түгелми-чәчелми әсәрләренә күчкән. Табигать матурлыгы аның җөмләләрендә, сүзләр бәйләнешендә кабатланган. Авторның һәр җөмләсе үзе кебек теләктәшле елмая, эчтән генә хәсрәтләнә, давылга әйләнә».

Минем язмада, күрдегез, авторның туган елы да, туган урыны да, хәтта язган әсәрләренең исемлеге дә юк. Мин авторның шәхесен һәм әдип буларак осталыгын күрсәтергә тырыштым. Иң мөһиме — бер генә сүзне дә кайдандыр күчереп язмадым. Габделхәй Сабитовка үз мөнәсәбәтемне, аны сагынуымны һәм әдип буларак осталыгына соклануымны гына күрсәттем.

Истә калдырыйк: иншаның кереш өлешендә безнең авторга бәябез булырга тиеш.

Ә ахырын ничек тәмамларга?

> Иҗади эшеңне ахырын белми торып башлама. Гадәттә, иҗади эш ни белән башланса, шуның белән тәмамлана.

Иншамның ахыры мондый булды:

«Күп еллар үтте. Елга буена барган саен, Габделхәй Сабитовның сүзләре искә төшә: «Бер көн балык тоту гомереңне ун көнгә озайта».

Их, нигә тагын, тагын балык тотарга дәшмәдем микән мин аны? Эшеннән аерып, көчләп булса да алып китәсе иде Идел уртасындагы утрауга. Утырасы иде сөйләшеп, төннәр буена учак ягып... Дәреслекләргә кирәрлек тагын әллә никадәр берсеннән-берсе матуррак хикәяләр язарга өлгергән булыр иде бит, дип уфтанам».

Ә иншабызның исеме нинди була ала?

Хикәянең төп темасы баланың сабырлыгын җыеп, үзен үзе җиңүе турында, дидек. Автор хисенең сәбәбе дә шул. Шуңа күрә мин инша исемен «Җиңү» дип куяр идем.

«Давыл чәчәге» исеме дә матур гына. Карагыз әле, без аңа мәгънә бирә алабыз бит. «Давыл чәчәге» — чәчәк кенә. Ә без андагы ике сүзнең эчтәлеген үзгәртә алабыз. Мәсәлән, «давылның чәчәге» дип. Болай итсәк, давыл — малай күңелендә уянган үч, ачу, рәнҗү бураннары, ә аның чәчәге, ягъни нәтиҗәсе — малайның кинәт дөньяга олылар күзе белән карый башлавы булачак.

ХИКӘЯ ГЕРОЙЛАРЫНЫҢ ХОЛКЫ

Шамил Усманов

Ачылган йозак

(Хикәя)

Безнең мастерскойга әллә ниткән төрле заказлар китерә торганнар иде. Барысыннан күбрәк йозак эше була; ишек, сандыкка йозак куярга, яисә ачкычы югалган йозакларны ачарга, яисә икенче ачкычлар ясарга китерәләр. Боларның барысын да мин яратып эшли торган идем. Катлаулы, чуалчык механизмлы йозак кулыма эләксә, мин, аны сүтеп, ничек корылганын белергә тырыша идем.

...Мин йозак эшенә аерым ихлас куйдым: китаплардан карап, иң чуалчык йозакларның механизмнарын өйрәндем. Нинди генә катлаулы йозак китермәсеннәр, бер-ике минут эчендә аны ачып ташлый торган булдым.

Берничә ел вакыт үтте. Тормыш дулкыннары мине үз шәһәребездән ерак булган Антроповка фабрикасына китереп ташлады. Мин фабриканың мастерскоенда ремонтлаучы слесарь булып эшли башладым.

Мастерскойның башлыгы — механик — мине, ни өчендер, бер карауда ук дошман күрде. Миңа иң түбән хезмәт хакы куеп, иң кара, иң авыр эшләргә билгели башлады. Минем йозакчылык һөнәрем файдаланмыйча ята иде.

Беркөнне мастер, карт слесарь Аникин янына килеп, аны кайдадыр бер эшкә җибәрде. Аникин бер егерме минуттан бик гарьләнгән кыяфәт белән кайтып килде дә, тимерчыбык кисәкләренең очларын бөгеп, отмычкалар ясый башлады.

— Василий Петрович, кайда идең? — дип сорадым.

— Конторада, директорның өстәл тартмасы ачкычы югалган. Шуны ачарга кирәк. Каһәр төшкән йозак, һичбер отмычкага бирешми,— дип, инструментларын

ящигына тутырып, ашыгып китте. Бераздан мастер, карт слесарь Беляев янына килеп:

— Михаил Васильевич, йәле, барып кара. Аникин булдыра алмый, ахрысы,— дип, картны җибәрде. Беляев мастерскойда иң тәҗрибәле, оста слесарьлардан санала, башкалар булдыра алмаган эшләрне булдыра торган иде. Әмма бу юлы ул да эшне башкара алмаган, күрәсең; ярты сәгать маташкач, ул да кайтып, ашыгып-пошыгып, отмычкалар ясый башлады.

— Әллә йозак бирешмиме? — дип сорадым мин аңардан.

— Ачып булмый шул, каһәр сукканны. Бик нык ясалган.

Җан түзмәде, шыпырт кына мастерскойдан чыгып, конторага киттем.

Контораның өске катында директор кабинетына илтә торган ишекләр шар ачык...

Директор хозурына доклад белән керергә вакыт җиткән. Ә монда эшләр начар; бай кабинетында механик, мастер, Аникин, Беляев, тагын берничә кеше өстәл янында тирләп-пешеп маташалар. Бай үзе бүлмә почмагындагы тәрәзәдән карап тора. Болай караганда, тыныч кыяфәтле күренә. Тик ул сирәк-сирәк иреннәрен генә чәйнәп ала. Ә карт хезмәтчеләр яхшы беләләр: бай иренен чәйнәсә, хәерлегә түгел инде. Берничә кеше штрафлану, берничәсе урынсыз калуны көт тә тор.

Механик ни эшләргә белми. Минем, кабинетка кереп, аның борын төбеннән үтеп, өстәл янына узганны күрмәде дә. Бөгелеп йозакны карадым. Йөрәк шаулап китте: бу миңа таныш схема белән ясалган йозак иде.

Бу вакытта механик минем янга килде.

— Син монда ни эшлисең, сине кем җибәрде? — дип мыгырданды.

— Менә йозакны ачып карарга уйлыйм. Вакытында бу эшкә осталыгым зур иде,— дидем елмаеп.

Механик минем елмаюымны әллә үзеннән көлү дип санады инде, бердән күперенеп, кабарынды да:

— Чакырмаган җиргә тыгылма. Вон моннан! — дип, аяк тибеп кычкырды.

Бер сүз әйтмәстән борылдым да киттем. Верстак янына килеп эшли башладым. Гарьлек тамагыма ачы төен булып тыгылды. Шунда барып тыгылуым өчен, үземне үзем тирги башладым.

— Моннан соң инде үзләре килеп аякка егылып, ялынып, ялварып сорасалар да барасым юк! — дип, күңелемә бик нык беркетеп куйдым. Үзем артык ул турыда уйламаска карар бирдем.

Менә минем янга мастер Москвин килде. Аның кыяфәте, болай, эш юктан йөреп килеп чыккан кешенеке шикелле, игътибарсыз гына. Минем яныма туктады.

— Фәхри, сине йозак ачарга оста диләр, дөресме? — диде.

— Бик артык оста булмасам да, Аллага шөкер, бүгенгәчә кулыма эләккән бер йозакны ачмыйча калган юк әле,— дидем.

— Алай булса, хәзер үк конторага барып, һөнәреңне күрсәтеп кара әле. Анда байның өстәл тартмасын ачарга кирәк.

Бугазыма тәрәлгән гарьлек төене әүвәлгедән дә ачы булып күренде. Шулай булса да, мөмкин кадәр тыныч тавыш белән җавап бирдем:

— Кайда инде ул безгә директор кабинетында өстәл ачулар! Андый эшкә бездән күп карт, күп тәҗрибәле слесарьлар, мастерлар, ахырында механик үзе бар. Алар булдыра алмаганны без булдыра алабызмыни инде?

Мастер, «алай булса, ихтыярың» дигәндәй, борылып янымнан киткән иде, ләкин берничә адым атлагач та, онытылган сүзен әйтергә теләгән кеше шикелле, кире кайтты. Бу юлы аның кыяфәте кискенләшкән, күз карашы гадәттәгечә авырайган иде.

— Йә, инструментларыңны ал да марш конторага, живо! — дип кычкырып куйды.

Минем гарьлек зәһәрле шатлыкка әйләнде. Кәефем килүдән шатланып, көлеп җибәрдем.

— Ә шулаймы? «Марш конторагамыни?» Ә анда барсам, механик «Марш урыныңа!» дип кычкыра... Юк инде, господа. Мин сезгә алай итеп йөрергә хәерче малай түгел. Ул йозакны ача беләм. Ләкин бармыйм. Расчет бирсәгез дә, конторага аяк атламыйм.

Болай нык торгач, мастер аптырап калды. Бер сүз әйтмәстән, мастерскойдан чыгып китте.

Озак та үтмәде, минем янга Василий Петрович Аникин килде.

Ул минем җилкәгә кулын куйды да:

— Йә, Фахрейка, әйдә, көчеңне сынап кара. Безне дә бәладән коткар,— диде.

Механик мине конторадан куып җибәргәч тә, анда шушындый бер сөйләшү булган.

Бай, борылып, өстәл янына килгән дә механиктан:

— Йә, ачтыгызмы? Әгәр егерме минуттан ачмасагыз, аннары үзегезгә үпкәләгез,— дигән.

Механик үз нәүбәтендә мастер белән слесарьларга басым ясаган.

— Алай булганда, әгәр чынлап та ачарга теләсәгез, Фахрейканы чакырырга кирәк, ул — бу эшнең остасы,— дигән Василий Петрович.

Механик белмәмешкә салышкан:

— Кайсы Фахрейканы?

— Әле генә сез куып җибәргән Фахрейканы. Ул — йозак мастеры. Монда ул гына ачса ача алыр.— Механик мыгырданган:

— Аны баштарак әйтәсе калган. Бар, чакырып китер! — дип, мастерга мине чакырырга фәрман биргән. Мастер минем яннан:

— Килми! — дип хәбәр китергәч тә, механик Василий Петровичның үзен җибәргән.

— Отмычкаларыңны ал да, әйдә, һөнәреңне күрсәт,— диде Петрович,— югыйсә бай каршында безнең бөтенебезнең базары төшә. Чынлап та, жалованье-

ларыбызны киметеп кую ихтималы бар. Мин үзем аннан курыкмыйм, расчет алам да башка фабрикага китәм. Ә Беляевның гаиләсе бар. Ул кайда да кузгала алмый.

Мәсьәлә алай куелгач, мин артык сөйләшеп тормадым. Отмычкалар бәйләмемне алдым да конторага юнәлдем.

Мин кергәндә конторада бер таркаулык сизелә, директор кабинеты яныннан аяк очлары белән генә басып үтәләр иде.

Мин туры ук өстәл янына уздым. Бөгелеп, йозакны карадым. Аның механизм төзелеше белән танышу өчен, элек озын борынлы разведчик отмычкасын тыгып, пружиналарын капшадым.

Кинәт йозак теленең шылт итеп төшеп киткәнен сиздем. Аны миннән башка берәү дә ишетмәде.

Маңгай тирләремне сөртеп алдым да, урындыкка утырып, махорка төрә башладым.

Бер читтә мыекларын кабартып карап торган механик яныма килде дә:

— Йә, ничек, буламы? — дип сорады.

Аңа җавап бирмәдем. Тәмәкене кабызып алдым да бер кул белән өстәл тартмасын тартып ачып җибәрдем.

— Менә сезгә!

Василий Петровичның:

— Молодец, Фахрейка! — дигәнен ишеттем. Директор безнең янга килде.

— Ачтыгыз? — дип, механикка карады.

Шатлыклы тавыш белән:

— Мин ачтым! — дидем.

Директор, иреннәрен чәйнәп, механикка, аннан миңа карады да янында торган главбухка:

— Василий Иванович, йозакны ачучы слесарьга егерме сум награда яз! — дип әмер итте.

Ул вакытта минем көндәлек хезмәт хакым илле тиен булганлыктан, бу сумма минем өчен зур шатлык иде.

Хикәянең авторы белән танышыйк

Вакыйгаларны читтән күзәтеп иҗат итүчеләр дә күп. Бетмәс-төкәнмәс ихтыяр көче, елгырлыгы белән Шамил Усманов вакыйгаларның эчендә кайный.

Уналты яше дә тулыр-тулмас ул фабрикада слесарь булып эшли башлый. Гражданнар сугышында Шамил Усманов Оренбургта төзелгән татар батальонының комиссары була, соңрак аны полкның меңләгән сугышчысы үзенең комиссары итеп сайлый. Дутов гаскәрләреннән легендар татар бригадасы төзүче дә Шамил Усманов. Үзе сугышчылар җыя, аларны коралландыра, киендерә, командирларын билгели һәм, комиссар булып, сугышка да китә. Ул күп меңләгән сугышчының комиссары — егерме яшьлек егет — Шамил Усманов була.

Җырларда макталган, батырлыгы белән илебез тарихына кергән Беренче татар бригадасы — әнә шул Шамил Усманов төзегән дивизия инде ул. Өч елдан соң ул генерал дәрәҗәсенә күтәрелә. Сез егерме өч яшьлек генералны күз алдына китерә аласызмы?

Әнә шул генерал — татар халкының танылган язучысы да. Күп санлы хикәяләр, повестьлар, пьесалар авторы.

Бу әдипнең барлык әсәрләре дә диярлек үз башыннан кичкән вакыйгаларга нигезләнеп язылган. Шуңа күрә әсәрләренең күбесендә төп геройның үзенә охшавы бер дә гаҗәп түгел.

Биремнәр

1. Сюжетның төенләнгән урынын, иң югары ноктасын (кульминация ноктасын), чишелешен әйтегез.
2. Төп геройның эчке кичерешләре турында сөйләгез.

Эчке кичерешләр дип күңелдәге хисләр хәрәкәтенә әйтәләр. Хисләр дә, төрле холыклы кешеләр кебек, бер-берсе белән каршылыкка керәләр: намус белән тарткалашалар, фикер белән уртак тел таба алмый интегәләр, теләкләрнең беришен хуплый-

лар, беришенә каршы сугыш ачалар. Кайчак хәтергә әйләнгән хисләр дә «Мин монда!» дип чәчрәп чыгалар да күңелдәге бәхәскә кушылалар. Кинәт яңарган хисләрнең матурлары кешене канатландыра, матур уйларга чумдыра, хәтта яшьлегенә кадәр алып кайта. Яманнары хәсрәткә батыра, әллә кайчан булган ялгышы өчен кайта-кайта үкендерә.

Берөзлексез хәрәкәттәге серле дөнья ул — күңел хисләре.

3. Төп геройның холкы турында сөйләгез.

Холык дип кешедәге даими сыйфатларга әйтәләр.

4. Хикәя исеменең мәгънәсе бармы?

Фәнис Яруллин

Алсу чәчәк

(Хикәя)

Сиринә быел алтынчы яшькә чыкты. Аның сөйкемле коңгырт күзләрендә тормышны, үзен уратып алган тышкы дөньяны тизрәк аңларга тырышу чаткылары көннән-көн күбәя. Әнисен дә, әтисен дә нигә, ничек дигән сораулар белән аптыратып бетерә ул. Әмма әнкәләренең вакыты тар, кызларының күп сорауларына: «Менә тиздән мәктәпкә керерсең, шунда укытучылар бөтенесен дә аңлатырлар»,— дигән җаваплар биреп котылырга тырышалар. Ә кыз моңа гына риза түгел, бөтенесен беләсе, күңелен кытыклаган сорауларга кызыклы җаваплар ишетәсе килә аның.

Соңгы вакытта күршеләрендә яшәүче Рәшит абый белән дуслашып китте Сиринә. Рәшит абыйларында китаплар бик күп. Идәннән түшәмгә кадәр киштәләр тезелгән, ә киштәләрдә нинди генә китаплар юк!

— Ай-яй,— диде Сиринә, беренче тапкыр күрше абыйларына кергәч,— боларның бөтенесенең дә рәсемнәрен карап чыктыңмы, абый?

— Рәсемле китаплар күп түгел миндә,— диде Рәшит абыйсы,— ә боларның мин һәммәсен диярлек укып чыктым.

— Ә сиңа китапларны киштәдән кем алып бирә, абый? Син бит йөри алмыйсың...

Рәшит, уңайсызланып, үзенең хәрәкәтсез аякларына карап торды. Кыз аның йөри алмаганлыгын каян белгән диген. Хәер, күрше-тирәдә бу хакта хәбәрдар булмаган кеше юктыр, мөгаен.

Сиринә, Рәшит абыйсының тын калуын күреп:

— Үзем алып биримме китапларыңны, абый? — диде.

— Ярар, сеңлем, бергәләп укысак, миңа да күңелле булыр.

— И абый, мин укый белмим шул.

— Әкиятләр тыңларга яратасыңмы?

— Ярата-ам.

— Алайса без синең белән әкиятләр укырбыз, яме? Шүрлектән әнә теге яшел төпле китапны алып бир әле.

Шул көннән башлап Рәшит абыйсы Сиринәгә әкиятләр дөньясына юл ачты. Яшел төпле китаптагы «Шомбай», «Үги кыз», «Тапкыр егет» әкиятләре каткат укылды. Кыз аларның һәрберсен чын итеп күз алдына китереп, тәэсирләнеп тыңлады. Ә «Камыр батыр» әкиятен укыганнан соң, хәтта әнисенең гөбәдиягә дип куйган камырын, кечкенә чиләгенә тутырып, Рәшит абыйларына алып керде:

— Рәшит абый, без дә шушыңардан Камыр батыр ясап карыйк әле!

— Ай-яй, әниең ачуланыр бит,— диде Рәшит абыйсы. Бу минутта кызга ни әйтергә белмичә аптырап калган иде ул.

— Ачуланмас, Рәшит абый, минем әни бер дә ачуланмый.

— Ясавын ясарбыз да, ләкин безнең батырыбыз җансыз булыр бит. Аңарга җан кертер өчен, әкият

дөньясына китәргә яки тылсымлы әфсен укый белергә кирәк. Ә китапта андый әфсенне өйрәтмәгәннәр.

Кыз, күңелсезләнеп, камырын өйләренә кертеп куйды. Шулай да аның әфсеннең китапка язылмаганлыгына ышанасы килми иде бугай. Әкиятләр китабын кулына алып әйләндереп-әйләндереп карап утырды.

— Абый,— диде ул аннары,— мине дә укырга өйрәт әле.— Үзе укый белсә, хикмәтле сүзләрне китаптан эзләп табар төсле тоела иде аңар.

— Өйрәтәбез аны,— диде Рәшит абыйсы, шатланып.— Минем китаплар арасында «Әлифба» юк-югын. Ләкин без үзебезчә өйрәнербез. Безнең әкиятләрдә иң күп очраган хәреф «А» бугай. Шуңардан башларбыз.

Рәшит абыйсы «А» хәрефенең олысын да, кечесен дә Сиринәгә күрсәтеп бирде. Кызның күзе хәрефкә күнегә төшкәч:

— Хәзер әнә шул «а»ларны китаптан үзең эзләп кара инде,— диде. Сиринәгә бу уен кызык тоелды. Таныш хәрефләре очраган саен, имән бармагы белән төртеп күрсәтеп:

— Менә тагын бер «а»,— дип шатланып әйтә башлады.

Алар башка көннәрне бүтән хәрефләр өйрәнделәр. Кызның күрү хәтере бик көчле иде, һәр хәрефне күңеленә тиз сеңдерә барды. Әгәр бу эш кызны ялыктырып җибәрсә, Рәшит абыйсы кәгазь-каләмнәрне, китап-дәфтәрләрне алып куя да нинди дә булса кызыклы китапларның эчтәлеген сөйли башлый. Ләкин Сиринәне барыннан да бигрәк әкиятләр мавыктыра. Тик Рәшит абыйсының әкият китабы гына укылып бетте.

— Рәшит абый,— ди Сиринә, балаларча беркатлылык белән,— теге әкиятләрне яңабаштан укыйк, Шомбай тагын кемгә ялланды икән?

Сиринә һәр әкияткә дәвам өстәп укыганны көтә. Әмма Рәшит абыйсы бөтенесенә ничек дәвам уйлап бетерсен. Иң яхшысы — яңаларны үз башыңнан чыгару.

Биремнәр

1. Сиринәнең холкы ачыла башлады. Укылган өзектә сез аның нинди сыйфатларын күрдегез?

Ә беркөнне ул Сиринәгә мондый әкият сөйләде.

«Борын-борын заманда, биек таулы, карурманлы авылда синең кебек кечкенә сеңлесе белән бер абый яшәгән. Абыйсының менә минеке кебек аяклары авырта икән. Шуңа күрә бөтен эшне бәләкәй сеңлесе эшләгән. Салкын чишмәләрдән сулар алып кайтып, тәмле-тәмле чәйләр кайнаткан, болыннардан кызарып пешкән җиләкләр җыеп, абыйсын сыйлаган, һәр көн тәрәзәләрен ачып, өйләрен җилләткән, сап-сары иттереп идәннәрен юган. Абыйсы аңа: «Ярый әле, сеңлем, син бар, югыйсә мин нишләр идем»,— дигән.

— И абый,— дигән кыз,— миңа эшләү берни түгел. Чишмәләргә барган саен, мин кояш нурларыннан салават күперләре сузам, болыннарга чыксам, күбәләкләр белән куышам, урманнарга керсәм, кошлар тавышын тыңлыйм. Шуннан бөтен арыларым басыла. Тагын да күбрәк эшлисем килә башлый. Әгәр кулымнан килсә, сине терелтер идем. Тау башына менәр идең дә күзләрең арганчы кояшка карар идең. Аннан соң мин сине үзем генә белә торган җиләкле аланнарга алып барыр идем. Ничек кенә синең аякларыңны йөри торган итәргә икән, абый?

— Аның бер чарасы бар-барын,— дигән абыйсы.— Хәтереңдәме, безгә бервакыт сихерче карчык килгән иде. Шул миңа сөйләде. Имеш, әнә теге биек тау башында бер алсу чәчәк үсә. Көннең иң озын, төннең иң кыска вакытында шул чәчәкне өзеп алып кайтып, аякларыңны сыйпасаң, авыруны гел булмаган кебек иттерә икән...

— Абый,— дигән кыз, шатланып,— ул тауны беләм ич мин. Барам да алсу чәчкәне өзеп алып кайтам. Көннәр генә озынайсын.

— Юк, сеңлем, ул тауга болай гына менеп булмый. Анда бара торган сукмакны авызы бәрәңге базы хәтле

Аждаһа саклый. Ә ул Аждаһаны һични белән дә җиңмәле түгел, ди. Безнең авылның батырлары, булат кылычлар тагып, менеп-менеп карадылар инде. Әмма кылычларын сындырып, үзләре кара канга батып кайттылар.

— Алайса анда сукмаксыз җирдән менәргә кирәк, абый,— дигән кыз,— мин урманның бөтен чытырманлыкларын, бөтен уравыч юлларын беләм. Җиләк җыйган чакта куяннар сукмагыннан да, аюлар эзеннән дә йөрергә туры килгәләде. Тик бер җирдә Аждаһа очрамады.

— Ул Аждаһа көннәрнең иң озынайган чагында гына сакка чыга, ди, шул. Шуңа күрмәгәнсеңдер. Чөнки шул вакытта гына алсу чәчәк шифалы суларга туеныл җитә. Ә син беләсеңме соң көннәрнең иң озын, төннәрнең иң кыска вакыты кайчан булганын?

— Беләм, абый. Юкәләргә бал төшкән, болыннар гөлгә күмелгән июньдә була.

— Шулай, сеңлем. Гөлләр чәчәкләрен атып өлгерсен, кошлар балаларын тизрәк үстерсен өчен, иң җылы чакта көннәр озыная. Менә тиздән тагын кояшлы җәй килеп җитәр. Болыннарда ак болыттай ак күбәләкләр уйнар, җылы яңгырлар басуларны сугарыр, күктән җиргә бал явар, муллык явар.

— Шулвакыт теге алсу чәчәк тә үсеп чыгар, абый, әйеме?

Кызның күңелен алсу чәчәк шундый дулкынландырган, хәтта ул аны төшләрендә күрә икән. Ә җәй җитеп, җилләр дөньяга хуш исләр таратып, кояш нурлары үләннәрнең йомшак чәчләрен сыйпап йөри башлагач, кыз түзмәгән, көн саен урманга чыккан да күзләре авырткачы тау ягына караган. Эзли торгач, йөри торгач, ул тау башына илтүче туры сукмакны да тапкан. Сукмак уртасында, өй хәтле кара таш астында, подностай олы күзләрен ялтыратып, Аждаһа ята икән. Кыз әллә нинди уравыч юллардан, куе чытырманлыклардан тауга менмәкче булып караган, ләкин барлык

юллар да ахыр чиктә шушы Аждаһа янына китереп чыгарган. Ә Аждаһа яныннан үтеп китүне уйларлык та түгел, ди. Кыз алай да итеп караган, болай да итеп караган, ләкин бер хәйлә дә тапмаган. Әмма аның абыйсын терелтәсе килү теләге шундый көчле икән, шифалы чәчәкне өзми торып, һич кенә дә өенә кайтасы килмәгән. Әйләнгән дә шул сукмакка килеп чыккан ул, әйләнгән дә килеп чыккан. Шулай аптырап йөргәндә, тау итәгендә ялтырап яткан бер нәрсә күреп алган. Ул әйбергә һич кенә дә туры карап булмый, күзне чагылдыра икән. Озаграк карасаң, хәтта күзләрдән яшь ага башлаган.

Читкә борыла-борыла гына, ул ялтыравыклы әйбер янына йөгергән. Барып җитсә, ни күзләре белән күрсен: җем-җем итеп яткан нәрсә гап-гади пыяла икән. Кыз аны ачу белән читкә атмакчы булган, тик шулвакыт башына бер уй килеп атмый калган.

— Кара әле,— дигән ул,— пыяла, минем күзне чагылдыргач, Аждаһаның күзләрен дә чагылдырырга тиеш бит. Кояш нурларын Аждаһага таба җибәрәм дә, күзләре яшьләнгәч кенә үтәм дә китәм.

Сөенеченнән нишләргә белмичә, кабат Аждаһа яткан сукмакка йөгергән ул. Күк йөзендә һичбер болыт әсәре юк икән. Бөтен дөнья күзне камаштырырлык якты, ди. Кояш та, кызга ярдәм итәргә теләгәндәй, нурларын бер дә кызганмыйча урманга, болыннарга сипкән. Кыз каушаудан дерелдәгән куллары белән якты нурларны үзенең пыяласы аша явыз Аждаһага юнәлткән. Аждаһа, бу ни хәл дигән кебек, челт-челт күзләрен йомган. Тора-бара аның күзләре яшьләнеп, ялт-йолт итә башлаган, әйтерсең аларга утлы яшеннәр кереп тулган да менә-менә гөлтләп кабынырга торалар. Аждаһаның күзләре еш йомылган саен, ныграк кыюланган кыз. Ниһаять, Аждаһа яшьле күзләрен йөнтәс койрыгы белән ныклап уарга тотынган. Шулвакыт кыз, яшь болан тизлегендә, аның яныннан үтеп тә киткән. Ә тау шундый биек икән, югарырак күтәрел-

гән саен, сукмагы да тарая барган. Кызның тез буыннары калтыраган, йөрәге атылып чыгарга җитешеп ярсып типкән. Әмма яшь батыр туктамаган, хәтта артына борылып карамаган. Артына борылып караса, теге Аждаһа куа киләдер кебек тоелып котын очырган.

Инде хәлсезләнеп егылам дигәндә генә, тау башына менеп җиткән ул. Һәм андагы иркенлекләрне күреп хәйран калган. Монда мәһабәт кошлар тау башына утырып ял итәләр, тиеннәр, агач башларында тирбәлеп, агачлардан чикләвек коялар. Ә кояш шундый якын: зуррак кыяга басып кулларыңны сузсаң, буең җитәр төсле. Әмма кызга мондагы матурлыклар белән хозурланып йөрергә ярамый шул. Аны авыру абыйсы көтә. Тизрәк шифалы чәчәкне эзләп табарга да абыйсын терелтергә кирәк!

Кыя ташына утырып бераз хәл җыйгач, теге чәчәкне эзләргә дип торып баса ул. Ләкин шулвакыт әллә каян гына котырынган җил чыга. Урман шомлы тавыш белән шауларга тотына. Кошлар, куркышып, ояларыннан качалар. Көн караңгылана. Үләннәр күзгә күренеп бөрешә. Ә барлык чәчәкләр шайтан таягына әверелә. Шунда каяндыр ерактан, агачларга-ташларга бәрелеп, тау хуҗасының ямьсез тавышы ишетелә.

— Ха-ха-ха! Минем сакчымны хәйләләп үттең дә хәзинәмне алып китмәкче булдыңмы? Алмый тор! Мин аны ерак яшердем. Әнә, күрәсеңме, чәнечкеле шайтан таягын? Шуның берсе — алсу чәчәк. Танысаң — ал!

Кыз, тавыш килгән якка карарга да куркып, баскан урыныннан кузгалмый тора. Күзләрен куллары белән каплап кирегә, өйләренә чабасы килә. Тик урыныннан тора алмыйча сызланып ятучы абыйсын уйлап ала да, батырланып, шайтан таякларына таба юнәлә.

— Бөтенесен өзеп кайтсам кайтырмын, әмма чәчәкне тапмый калмам,— ди ул үзсүзләнеп һәм шайтан таякларын йолкып, кочагына җыя башлый. Энәдәй каты чәнечкеләр аның кулларына кадала, бармакларын каната, уч төпләрен җәрәхәтли. Тик ул туктамый.

Шул заман әллә каян гына бер тиен кызның алдына сикереп төшә.

— Исәнме, иске таныш? — ди ул кызга.— Әллә танымыйсың инде?

— Гафу ит, Тиенкәй, танымыйм. Сез барыгыз да бертөсле бит.

— Хәтерендәме, былтыр син мине капкыннан коткарган идең?

— Синең бит, Тиенкәй, арт тәпиең аксап калган иде, ничек төзәлде?

— Шушы таудагы алсу чәчәк белән сыйпадым, шуның шифасы тиде.

— Мин ул чәчәкне таба алмам инде,— ди кыз һәм кайгысын Тиенгә сөйләп елап җибәрә.

— Кайгырма,— ди Тиен,— җаен табарбыз. Әнә тегендә өзелгән кәлтә койрыгы ята. Шуны барып ал әле. Селкенәме?

— Юк, селкенми.

— Селкенмәгәч бигрәк әйбәт. Хәзер шул кәлтә койрыгын тот та шайтан таякларының чәчәкләренә тидереп чык. Кайсысына тигәч кәлтә койрыгы селкенә башласа, шунысы шифалы алсу чәчәк булыр.

Шулай ди дә Тиен китеп бара. Кыз аңарга рәхмәт әйтергә дә өлгерми. Тиен китү белән, ул эшкә керешә: койрыкны әле бер чәчәккә, әле икенче чәчәккә тидереп карый. Инде бөтенесенә диярлек кагылып чыга, әмма койрык селкенми. Бары тик бер читтә ике-өч кәрлә үсенте генә кала. Кызның күңеле суына. Теләр теләмәс кенә теге үсентеләр янына килә. Салмак хәрәкәтләр белән койрыкны чәчәккә сыйпап җибәрүе була, койрыкка җан кереп, уч төбендә тыпырчына башлый. Куанычыннан кулларының авыртуын да онытып, бу чәчәкне өзеп ала ул. Бары тамырлары гына җирдә кала.

Кулга шундый хәзинә төшергәч, аруын да, ачыгуын да оныта. Хәтта Аждаһа ята торган өй хәтле кара ташны да сикереп кенә үтә.

Әйтерсең аңа кемдер канатлар куйган, очып кына кайта. Кайтып кергәндә куанычының иге-чиге булмый.

— Абый,— ди ул,— алсу чәчәкне таптым бит. Моннан соң бервакытта да авырмассың инде.

Шулай сөйләнеп, абыйсы янына килә һәм аякларын ачып, чәчәге белән сыйпап җибәрә. Башта бармаклар әкрен генә селкенә башлый, аннары хәрәкәт тез буыннарына күчә. Күзгә күренеп аяклар җанлана. Ә инде күпмедер вакыт үткә, кызның абыйсы бер дә авырмаган кебек торып баса. Торып баса да сеңлесен һавага чөя. Шуннан соң инде алар дөньядагы иң бәхетле кешеләр булып яшиләр, ди...»

2. Хикәя вакыйгасы эченә әкият вакыйгасы килеп керде. Әкияттәге кызчыкның холкы нинди?

Рәшит абыйсының бу әкияте Сиринәгә барысыннан да ныграк ошады. Әкияттәге кызны үзе, ә кызның абыйсын Рәшит абыйсы итеп күз алдына китерде. Сиринәнең дә, шундый алсу чәчкә табып, күрше абыйсы Рәшитне терелтәсе килде.

Шушы әкият тәэсиренә бирелеп йөргәндә, Сиринәне авылга әбиләренә җибәрделәр. Ә күпмедер вакыт үткәч, Рәшит абыйсына Сиринәдән бер посылка килеп төште. Анда уттай янып торучы берничә шайтан таягы һәм әбисе белән бергәләп язган хат бар иде.

«Рәшит абый,— дип язган иде Сиринә,— безнең әбиләр авылында теге син сөйләгән төсле тау бар икән. Без шул тауга әби белән әллә ничә тапкыр бардык. Иң биек түбәсенә генә менеп җитеп булмый әле, әби арый. Үзем генә менәргә куркам. Әби әйтә, Аждаһасын болыт күтәреп китте инде аның, ди. Менә бу шайтан таякларын шул таудан йолыктык. Алар теге алсу чәчәк түгелме икән? Шулар белән аякларыңны сыйпап кара әле, Рәшит абый. Болар гына төзәтмәсә, тауның иң очына менеп йолкып төшәрмен. Курыкмаска өйрәнеп киләм инде».

Рәшит хатны укыды да чәчәкләрне сулы стаканга утыртып куйды. Ул инде Сиринәне ныклап юксына башлаган иде.

3. Хикәянең төп эчтәлеге — хис. Шуны исбат итегез.

Биремнәр

«Көтүчеләр» хикәясен укыганда, түбәндәге ике сорауга җавап эзләгез:

1. Әсәр эчтәлеген табу өчен, беренче чиратта, аның исеменә игътибар итәргә кирәклеген беләсез. Автор әсәрен ни өчен «Көтүчеләр» дип атаган?
2. Төп геройның даими сыйфатын (холкын) кабатлаучы вакыйгаларны табыгыз.

Галимҗан Ибраһимов

Көтүчеләр

(Хикәя)

I

Мин түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдем.

Атам көтүче иде: озын буйлы, киң маңгайлы карт. Исеме — Әптерәш. Анамны хәтерли алмыйм: гомерем яшь ярымга җитмәстән элек, аны кабер алган...

II

Ул вакыт без тирмәндә яшәдек, бер ягыбыз — ялангач соры ташлары белән күккә күтәрелгән зур тау; икенчесе — көне-төне шаулап утырган караңгы урман. Без табигатьнең шул ике куәте арасында кысылганбыз. Тауның кара көйгән зур ташлары арасыннан, шаулап, куәтле елга төшә. Безнең тирмәнебез шуңа корылган.

Мин монда ялгыз үстем.

Әти көн буе көтү көтә дә, кич кайтып, сүзсез-нисез караңгы почмакка егыла; иртән аның киткәнен мин белми дә калам.

Тирмәнебез авылдан читтәрәк булганга, миңа анда барып йөрергә сирәк туры килә иде. Хәят[1] башта миңа шул тирмән булып күренде. Су чылтырап ага... урман шаулый... тирмән көн әйләнә, төн әйләнә. Мин, гүя аның шул әйләнүенә сихерләнеп, гомернең кая барганын, уйнауның, балалыкның ни икәнен белми яшим.

Төшләрем өнгә охшый. Өнемдә булганнарны төштән аера алмыйм...

Биремнәр

1. «Төшләрем өнгә охшый. Өнемдә булганнарны төштән аера алмыйм...» сүзләрендә Вахитның холкын күреп буламы?

Урак бетеп, иген-тару җыелуга, тирмән халык белән тула. Күп вакыт, аталарына, абзыйларына ияреп, балалар да килә. Алар белән уйныйсың, бөтенләй яңа дөньяга кергән шикелле булып каласың.

Бервакыт, этисенә ияреп, бик матур бер кыз килде. Ул япь-яшь, ләкин гаҗәп тере, уенчак иде...

Сараны беренче күрүем белән, кулымдагы эшемне оныттым да, аларның арбасы янына барып, күзеннән күзләремне ала алмый, аңа сүз куштым; бер-ике минут үтмәде, без инде гомерлек дуслар булып әверелдек.

Мин аны тауларга, урманнарга алып чыктым, вак кына чуар, җылтыр шома ташлар, матур чәчәкләр җыеп бирдем. Киткән чакта ул мине үзе белән бергә авылга барырга чакырды, анда минем курчакларым күп, атым да бар, бергә уйнарбыз, ди. Арбасына утыртып алып барырга атасы да риза булды.

Ләкин мин, шул бер-ике сәгатьлек мөнәсәбәт эчендә, аңа үпкәләп тә өлгергән идем. Бүген монда калам, иртәгә барсам барырмын, дидем.

Шул көннән соң авыл минем күңелемне тарта башлады.

---

[1] Хәят — тормыш.

Һәр көн йокыдан уянгач, шунда бару, матур Сарам белән бергә икәү генә уйнау өмете минем йөрәгемне кузгата торган булды.

Ләкин анда бару белән тагы дәртем сүнә иде. Аның көтү-көтү малайлар белән тәмам үз булып уйнап йөрүе, мине дә шуларның берсе санавы күңелемне кыра иде.

Мин, уеннарына катышмыйча, Сарага кадалып, читтә бераз карап торам-торам да һичкемгә һичбер сүз әйтми кайтып китәм.

Күңелем сына, җаныма никтер авыр була. Шул вакыт никтер әнине сагынам. Аның итәгенә ятып, озак елыйсым, дөньяның мине җәберләве турында йөрәгемдә уянган зардан күз яшем белән бушанасым килә башлый. Ләкин ул кабердә... Башка һичкем мине аның кадәрле сөя алмый... Мин берәүгә дә кирәк түгел, мин үзем дә һичкемне якын күрмим, һичберсен яратмыйм, ярата алмыйм...

Шул минутларда ялгызлыктан җаным әрни. Ходайның каршысына тезләнеп, нинди гөнаһым өчен бу каһәрләргә дучар булуым хакында елап сорыйсым, ялварасым килә.

2. Вахит хәсрәтенең сәбәбен әйтегез.

III

Яшеннән ут чыгып, тирмәнебез янып китте. Мин аптырый калдым: инде, дим, ни булыр, инде безне, дим, кая куярлар. Ләкин әти җиңеләеп, бер сулыш алгандай булды...

Күптәннән үк инде ул:

— Моннан күчәсе иде, күчәсе иде! — дип уйлана, аз гына кәефсезләнгән саен: — Урыс йортында җан бирәм күрәсең инде, Ходаем,— дип, авыр кайгыга төшә иде. Яшен аны коткарды.

Ул кыш көнне урман саклый иде, ахры, бик яхшы күзәтче булгандыр, авылга күчәргә исәп барлыгын әйткәч, урыс:

— Китмәгез, тирмәнне яңадан корам, яхшы итеп салдырам, сезгә тыныч бер бүлмә бирермен, синең кебек туры кешене табып булмый,— дип ялынса да, әткәй тыңламады:

— Булмас инде, бик картайдым, хәзрәттән, мәчеттән ерак яшисем килми,— диде.

Без тирмәнне ташладык.

IV

Садыйк байның ындыры артында кечкенә генә бер өй бар икән. Әти, авылга күчәр идем, дигәч, Садыйк бай ун карт белән старостаны чакыртып киңәшкән дә:

— Барыбер буш тора, шул читән өйне Әптерәш картка бирик,— дигән.

Тегеләр, ахры, риза булганнардыр, без дә, Аллага тапшырып, бер җомга көн шунда күчендек.

Бу — билгеле, бер сажин кадәр читәннән ясалып, эче-тышы кызыл балчык белән сыланган, җир идәннәр, ...карындык тәрәзәле, түбә-кыексыз[1] бер өй иде. Әткәй аны күп үзгәртергә теләмәде: түбәсенә үскән озын әрем, алабуталарны йолкып ташлады, миңа мич башына, үзенә сәке почмагына саламнар түшәп, ятарга урын ясады да без шунда тора башладык. Бу өйгә самовар кергәнен хәтерләмим; лампа яндырылганы да исемдә юк, итле аш буы белән парлангандыр дип тә белмим. Җәй көне тамак ил өстендә туя, монда тик кайтып кунабыз гына. Кышның озын төннәре килсә, әти Садыйк байдан кар көрәү, утын яру кебек эшләр эшләве өчен алып кайткан арыш саламын киң кочагында ашыкмый гына мич буена кертеп сала да, шуны урап, бик акрын гына ягарга тотына.

Әтинең җәй көне туклауда[2] сөт кайната торган, корымга буялып, кап-кара булып беткән бер тимер

---

[1] Түбә-кыексыз — кыеклап эшләнмәгән түбә.
[2] Туклау — малларны су эчертеп ял иттерә торган урын.

чәйнеге бар. Шуңа су салып, утта кайнатабыз да, беребез агач савыт, икенчебез әллә ничә җиреннән сыланып, бәйләнеп беткән кәсә белән чәй эчәбез. Ястүне соң гына укыгач, әти, караңгы почмакка кереп, кыйблага каршы утыра да акрын гына көйли башлый.

Еллар үтте. Мин дә чыбыркы өстерәп сыер артыннан йөгерерлек яшькә җиттем. Шуның белән инде бик нык картаеп барган атама булышлык кылырга, аның белән көтүгә йөри башларга вакыт җитте.

Кулда зур елан шикелле бөтәрләнеп торган озын чыбыркы; көтүдән читкәрәк чыгып барган усал сыерларның арка тиреләрен ярып алырлык бер төшерсәң — үзеңнең булдыклылыгыңа горурланып ук китәсең: шул арада иптәш малайларыңнан берәрсе күренсә — башың тагы күтәрелә.

Ләкин бу озакка бармады. Берничә сәгать үтү белән, минем иртәнге горурлы шатлыгым эштән чыгып аруга, хәлдән таюга алмашынды.

Эсседә мал ашамый икән. Төш якынлый башлагач, көтүне су буена туклауга төшерәләр.

Кулымда чыбыркым, билемдә капчыгым көенчә, яр буена авып, үлемнән каты йокыга чумдым. Көннең мондый эссе чакларында көтүне озак туклаталар, дүрт-биш сәгатьсез көтүне туклаудан чыгармыйлар икән. Ләкин бу биш-алты сәгать миңа күз ачып йому кадәрле дә тоелмады.

VI

Адәм башы ниләр күрми, ниләргә күнекми! Акрынакрын мин дә көтүче малай булып киләм. Инде элеккс кебек ук арытмый да. Гәрәй картның явыз сыерлары да элгәреге кебек чаба алмыйлар. Беркөн шулай, гадәтләренчә, иген ягына карый башлаганнарын күргәч, үзләрен түбән оч көтүчесе Вилдан белән икәүләп таш арасына кысып тоттык та арт аякларындагы нечкә сеңгерләрен кыл белән, өзеп керерлек каты итеп,

урап бәйләдек — шуннан соң ни күрәсең, сыерларыбыз бөтенләй тәүфыйкка утырдылар...

Туклауга төшүгә, әти белән теге югаргы оч көтүчесе Камали карт азрак сөйләшеп утыралар да йоклап китәләр; без, яшьрәкләр, алар йоклагач, зур кәҗәләрне тотып савабыз да утта кыздырган ташлар белән сөт җылытабыз...

3. Вахит Садыйк бай бүләк иткән читән өй начар дип зарлана. Ул өйнең начарлыгына кем гаепле? Садыйк баймы, әтисе белән Вахитмы?
4. Вахит эш авыр дип зарлана. Аның эше авырмы? Ул малларны яратамы?

VII

Әтинең картлыгы җиңә башлады, ахры. Йомшаруның башлануына бер ай дигәндә, картның чыбыркы тотып сыер артыннан йөрерлек чамасы бөтенләй бетте...

Көтү минем үземә калды.

VIII

Безнең әткәй элек бик талымсыз кеше: ни туры килсә, шуны ашый, нәрсә ашаса, шуның белән тук була иде. Ә хәзер алай түгел: каты нәрсә аның тамагыннан үтми, чәйгә сөт кирәк, җылы шулпа да кирәксенә. Ләкин мин боларны кайдан алыйм? Аш пешерергә казаны да, аңа салып пешерергә ите-фәләне дә юк.

Булса да, барыбер мин аны пешерә белмәс идем.

Рәхмәт төшсен, тик ара-тирә Гайни карчык кечкенә кызы артыннан үзенең калган шулпасын җибәрткәли. Шул көннәрдә этинең кәефе бераз төзәлгән кебек булып китә.

Беркөнне әти бик авырайды. Берничә мәртәбә теленнән дә язды. Мин көтүгә чыкмадым. Икенче көн... тагы көтүгә бармадым. Җәй уртасында көтүчесез калу халыкка бер дә ошамаган, ахры.

— Атаң янында башка кеше торыр, син көтүгә бар,— диделәр. Мин усал тел белән җавап кайтардым:

— Бу нинди халык?! Боларның җаннары бармы, юкмы? Атаң ыңгыраешып, телдән калып, үләргә ятсын,— син, имеш, аны ташлап калдыр да Гәрәй байның сыерлары артыннан йөре!

Мал хуҗаларының артык кәефе кырылган да, күп киңәшеп-нитеп тормыйча, безнең исәпкә яллап, икенче берәүне көтүгә чыгарганнар.

Чукынып, кадалып китсеннәр, сыерларының муеннары асларына килсен, берне түгел, меңне яллагыз!.. Мин әткәйне ташлап китәр хәлем юк!..

Халык бик сүгенә башлаган. Бер әле генә түгел, болар һәркайчан миңа кырын карыйлар, мине яратмыйлар.

Бервакыт Кәрим бай үзе ашый алмаган черек йомыркасын миңа биргән иде, мин иснәп карадым да:

— Фу, тынчып беткән икән бу! — дип, эткә ташладым.

Икенче бервакыт Сафи карт ертылып эштән чыккан зур чалма бүреген миңа «бүләк» итмәкче булгач, бу каз оясын ни эшләтим мин, дип, үзе алдында ук бер хәерче картка ыргыткан идем.

Шундый эшләремнән соң авылда минем хакта «ярлы тәкәббер» дигән сүз китте.

Әтинең юашлыгын, сүз тыңлаучанлыгын, каршы тел әйтмәвен мактап сөйли башласалар, шуңа ялгап мине яманлыйлар:

— Яхшыдан яман туган...

— Күзләрендүк әллә нинди бер кирелек бар бу этнең...— диләр иде.

Беркөнне Сафи карт керде дә, ярлы тәкәббер дип, яхшыдан яман туган дип, мине әти алдында әрли башлады.

Ни эшләмәк кирәк, каршы сугышырга көч юк, тырнаша, тешләшә башласаң, этине борчу була. Ләкин тыңлап торуга җан түзми:

— Әтине үтерделәр, инде мине дә тереләй ашамакчылар! — дип, акырып елап җибәрдем, бар көчем белән ишекне шакылдатып ябып чыгып качтым.

Көн буе ялгызым теге, элек үзебез торган тирмәндә, таулар, чокырлар арасында йөреп, кич өйгә кайтсам, анда һичкем юк, һичнәрсә юк, ватык кәсә белән тишек чәйнекләргә чаклы алып киткәннәр.

Мин аптырап елап торганда, Гайни карчык килде дә ишекне ябарга азаплана башлады. Үзе авыз эченнән нидер мыгырдый, сукрана:

— Кадерен белмәдең, бар, хәер сорашып йөре инде!.. Атаңны илгә чиратка салдылар...— ди.

Карчыкның соңгы сүзләрен ишеткәч, аптырап ката калдым. ...Илгә чиратка салдылар, дигәч, йөрәгемдәге кан башыма капланды, хурлануымнан башымны кая куярга җир тапмадым...

Бүген Фәхри байда, иртәгә Вәли картта, аннан соң Гали картта — шулай бер тамагын туйдырыр, бер җылы почмак табар өчен, көн саен бер ишектән икенче ишеккә йөрерме икәнни, бичара?!

...Мине кем тоткандыр, теге тирмән янындагы биек таудан суга сикереп үлүдән ничек котылганмындыр, моны хәзергәчә белә алмадым.

Әткәйне дә күрми, һичкемгә һичбер сүз әйтми, һичкем белән исәнләшми, авылдан чыкканмын да киткәнмен.

IX

Шуның артыннан ниләр булганын ачык хәтерли алмыйм... Ачлыктан бик артык хәлсезләнүем, аптырап, хәлсезләнеп, бер баганага сөялеп торуым...— әле дә төштә кебек кенә исемдә тора.

Ләкин ачык белмим, бу — төш идеме, өн идеме?!

Һушыма килеп, күземне ачып җибәрсәм, үземне апак, ап-якты бер өй эчендә күреп аптырап калдым... Барысы да ак киенгән ирләр, хатыннар мине чолгап алганнар.

Фәрештә төсле күренгән шул ак киемлеләр эченнән көләч йөзле, үтә кара кашлы, гаҗиб[1] мөлаем бер ханым үзенең йомшак куллары белән мине ярым кочаклап утыртты да:

— Курыкма: авыр көннәр үтте инде...— диде.

Күземә яшь килде, шуны марҗага күрсәтмәс өчен, икенче ягыма әйләнеп яттым. Әти күз алдыма килде... Ул бичара хәзер ничек яши икән? Әле дә өйдән-өйгә кереп, гомерен уздыра микән?

— Ходаем, ник безне болай җәзалыйсың?..

Йөрәгем ачулы гайрәт белән суга башлады... Менә хәзер сикереп торсам... үткен сөңгеләр, кылычлар белән коралланып... шул каһәр төшкән авылга һөҗүм итсәм, бөтен авылның астын-өскә китереп, һәммә кешеләрен әткәй алдында тез чүктереп гафу үтендерсәм... шул чакта йөрәгем тынар, күңелем басылыр иде әллә!

Теге матур зур кара күзле ханым гадәтенчә акрын гына минем бүлмәмә керде. Мин аны «Сара» дип атарга теләдем. Үзенә дә шулай дип дәшә идем. Ул башта аптыраган кебек булса да, ахырдан күнде.

5. Вахит бу өзектәге вакыйгада да зарлана. Нигә зарлана?
6. Укып чыккан өзектә Вахитның яңа сыйфаты ачыламы?

XI

Беркөнне доктор миңа бик начар хәбәр китерде:

— Син терелдең... Инде хәзер сиңа чыгарга да ярый,— диде.

Кая чыгыйм? Чыгып кая барыйм?

Доктордан соң Сара килде. Ул шундый матур, шундый шат иде.

— Кайгырма, мин сине үзем алырмын,— диде.

---

[1] Гаҗиб — гаҗәеп.

Рәхмәт-фәлән әйтмәдем, чөнки минем өчен бу бик артык табигый күренде. Минемчә, ул мине үзеннән ерак җибәрмәскә тиешле иде.

Миңа күк йөзе ачылды. Аннан җир йөзенә бертуктаусыз нур ага. Адәмнәр шул нурда йөзәләр, рәхәт гомер итәләр иде. Әткәйнең бәхетле яшәвендә бер дә шигем калмады. Шөбһәсез, ул үзенең актык гомерен тыныч, рәхәт үткәрә. Аның җаны тыныч, тамагы тук, өс-башы бөтен...

7. Өзектәге «тиеш» сүзенә игътибар итик. Әсәрнең буеннан-буена Вахит холкы өчен иң мөһим сүз ул — «тиеш» сүзе. Кемнәрдер аңа һәрвакыт нидер тиеш була. Аңа һәм этисенә халык өй бирергә тиеш иде... дәвам итегез.
Вахит уенча ул үзе нәрсәгә дә булса җавап бирергә тиешме?

XI

...Чыктык та, яхшы арбага утырып, шаулап, гөрләп торган зур шәһәрнең бер ягындарак бакчалы бер өйгә туктадык.

Шулай бер бүлмәгә кердек. Өнме, төшме? Белмим.

Мондый матур, пакь, зиннәтле бүлмәләрне мин әкияттә генә күргәнмен. Мин шунда тора башладым.

Сара һәр көн килә иде. Мин камил тазарып җиткәч, ул мине укыта башлады.

Көннәрдән бер көн Сара белән... шәһәрнең уртасында... зур бер сарайга бардык... Залның диварлары сурәтләр белән тулы. Арада минем һушымны алган... рәсемнәрдән бигрәк тә икесе булды: бер карт, бер култыгына берничә агач кыстырып, тар гына басмадан су аша чыгып бара. Башы ялангач, аягында чабата, үзе күлмәкчән генә... Шуны күргән саен, атам исемә төшә...

Шулвакыт аны артык сагынам. Аның мине гафу итмәве, халык арасында таралган сүзләр сәбәбеннән мине күрергә теләмәве, мине кабул итмәве, миңа үзе өчен һичбер эш эшләргә ирек бирмәве, йөрәгемне әрнетеп, күз алдымнан кичәләр.

Аңардан ерак түгел хәзрәте Гайса[1] тора. Олы диңгез, шуның уң ягыннан зур таулар күккә күтәрелеп киткән; тын, рәхәт бер төн... Шулвакыт хәзрәте Гайса, таякка таянып, тау эченнән килеп чыга да, зур бер ташка утырып, айга карап уйга бата... Йөзе артык җитди, күзләре тирән уй белән каядыр юнәлгәннәр...

Моның хакында ни әйтергә белмәсәм дә, сәгатьләрчә тукталып карый идем.

Бервакыт Сарадан:

— Ул нәрсә уйлый икән? — дип сораган идем.

— Ул бәхетсез адәм балаларының рәхәте, сәгадәте хакында уйлый,— диде.

XIII

Күп еллар үтте.

Без инде Сара белән тора башладык. Мин дә күп үзгәрдем, ләкин җаным сызлаган сәгатьләрдә мин ихтыярсыз шул биек сарайга кереп югала идем. Ничә генә барсам да, басмадагы карт белән айлы кичәдә диңгез буенда ялгыз утырган Гайса мине үзенә тарта, сәгатьләрчә уйга чумдыра иде.

Беркөнне шундый уйлар белән газапланып йөргәндә, кинәттән йөрәгем «жу» итеп китте, аңа нәрсә беләндер чәнечтеләр. Ашыгып өйгә кайттым. Сара каршы чыкты.

— Әйт, ни булды? Балаларыбыз исәндер бит? — Ул миңа моңарчы таныш булмаган... бер тавыш белән:

— Балалар исән, ләкин әткәй вафат! — диде. Моңа минем артык исем китмәде. Ни эшләмәк кирәк, дөньясы шулай корылган инде; адәм туа, үсә, тормышның дулкыннары белән каядыр бармак булып сугыша, көрәшә дә бервакыт үлә. Ләкин бу башта гына шулай булды.

---

[1] Гайса — ярдәмгә мохтаҗ кешеләргә ярдәм кулы сузучы пәйгамбәр.

Бичара карт, бичара ата! Җитмеш ел туктаусыз эшләде. Билендә капчык, кулында озын чыбыркы — гомер юлыңны шуның белән үт тә бераүнең мал өендә, сәке астында, бозаулар арасында актык сулышыңны ал!

Безнең өй авыр матәмгә әйләнде. Бу минем хәятка һәм үз эшемә карашымда тирән эз калдырды. Адәмнәрнең яхшы яшәүләре, бәхетләре хакында эшләнгән эшләрнең, фикерләрнең һәммәсе хатадыр, һәммәсе нәтиҗәсездер кебек булды. Адәмнең бәхете... өчен гыйлем, фәлсәфә, мәдәният юлын күрсәтүче галимнәр! Күрсәткән юлыгызның... нинди нәтиҗә биргәнлеген күрәсегез килсә, рәхим итеп, менә шул абзарда бозаулар арасында җан биргән картның мәетен карарга килегез.

Сөйләгез! Без, тормышның төбендәгеләр, сездән җавап көтәбез! Ничә меңьеллык тәҗрибә иске юлларның хатасын ачмадымы; без җавап көтәбез!



Башында ертык бүрек, өстендә сәләмә кием, билендә җеп, аягында тузган чабата, аркасында капчык, кулында озын чыбыркы улдыгы хәлдә, озын таягына таянган да, батып барган кояшка карап, авыр тирән уйга баткан; теле сөйләми, ләкин аның бөтен торышы:

— Дөнья шундый матур, без ник болай бәхетсез соң, Ходаем?! — ди.

Шул торышы... Алланың барлык илчеләрен, мәдәни инсаниятнең[1] барлык көтүчеләрен җавапка чакыра иде.

Ләкин моңа кем җавап бирә алачак?

8. Сюжет вакыйгаларын бергә кушып сөйләгез.
9. Вахит холкын әйтегез.

Мөстәкыйль эш

Фатих Хөсни

Йөзек кашы

(Повесть)

I

...Безнең Янбулат авылында Айдарлар бер мин генә түгел. Мине Кәҗә Шаяхмәт Айдары дип йөртәләр иде. Ни өчен Кәҗә Шаяхмәт? Дуамалрак кеше иде минем әти...

Әтисе, бәхәсләшеп, кәҗә итен бер утыруда ашап бетерә. «Кәҗә» кушаматы аңа шул вакыйгадан соң тагыла, дип сөйли Айдар.

Хәер, төкерергә. Авылда кушаматсыз кеше буламыни. Кәҗә Шаяхмәт малае гына булсам да үскәнмен әле.

Истә калдырыйк: бәхәс вакыйгасы сюжет вакыйгаларыннан читтәрәк тора. Галимҗан Ибраһимов үзенә бер эчтәлеккә ия булган андый вакыйгаларны «Башлам» дип атаган. «Башлам», әсәр эчтәлеген аңлау өчен, бик мөһим өлешләрдән санала.

Таякны ат итеп уйнауларны, мулла бакчасыннан алма чәлдерүләрне сөйләп тормыйм. Алма дигәннән,

---

[1] Инсаният — кешеләр. Кешелек дөньясы.

безнең Янбулат авылына берчакны шулай алма сатучы килде. Әллә шуннан башлап китәргәме? Әй, шуннан башлап китимче әле. Июль ахырлары микән, август башларымы, әйе, алма сатучы килде. Госман, безнең күрше малай, ис сизәргә дигәндә аннан да җәһәт кеше юк иде. Алма исе иң элек аның курнос борынына барып кергән, ул, читән өстенә басып, миңа кычкырды:

— Әй... Айдар, алма сатучы килгән. Әйдә киттек!

Әйтүе булды, шул якка элдерүебез булды. Алма сатучы, атын җай гына атлатып, урам буенча бара да бара, үзе: «Алма сатам, ал-ма!» — дип кычкыра. Кешеләр күбрәк җыела төшкәч, атын туктатып, сату итә башлый.

Без, малайлар, арба артыннан ияреп йөрибез. Алманың исен иснәгән өчен акча сорамыйлар, алманың үзен алырга акчабыз юк, арба артыннан да ияреп йөрмәгәч, безгә ни кала соң?

Атын күргәнмен, арбасын күргәнмен, алмасын күргәнмен, ә менә алма әрҗәләре арасында кысылып утырган кечкенә генә кызны, түгәрәк ак беләкле, кап-кара күзле, башына салам эшләпә кигән кызны моңа чаклы күрмичә торганмын.

Бүтәннәр алма карыйлар, мин кыз карыйм. Кыланчык нәрсә икән, эшләпәсенә ал лента бәйләгән булган. Безнең авылныкы булса, мин аның эшләпәсен чәнчә бармак белән эләктереп алыр ием дә өй түбәсенә атып бәрер ием. «Алып бир дә, алып бир»,— дип, соңыннан минем тирәмдә тик бөтерелеп йөрсен. Безнең авылныкы түгел шул. Әллә, алма караган булып, якынрак килеп караргамы? Арбага якынрак елышам. Ә күрсен иде, каһәр. Әллә арба тәгәрмәченә басып караргамы? Бастым. Кинәт үсеп киттем. Кызны хәзер колак йомшакларына чаклы күрә башладым. Әллә агач ботагында алма белән бергә үстеме икән ул? Битләре нәкъ алма төсле. Чәчен зәңгәр лента белән кушып үргән, маңгае ап-ак, күзләре түгелергә торган төсле. Ә үзе

шул кечкенә генә куллары белән үлчәү тәлинкәсе тирәсендә маташкан була. Герләр алып сала, алма тутырыша, мине ичмасам бар дип тә белми. Ачуымны китерсә, чәч үргеченнән тартырмын әле. Уйлавым булды, тартуым булды. Карамас җиреннән карады кызың. Карады, аннары көлеп җибәрде.

Дөресен генә әйткәндә, әллә ни эшләдем мин. Алманың исен сизми башладым, үземнең Кәҗә Шаяхмәт малае гына икәнлегемне оныттым.

Мин арбадан бер читкә китәм, берсенә дә карамаган бер төс белән басып торам. Кыз күтәрелә дә карый, тешләрен күрсәтә. Үзем дә сизми калганмын, минем дә тешләр күренеп киткән тегеңә. Шуның артыннан озак та тормады, ул кыз бик зур, бик матур бер алманы сайлап алып, әтисе күрмәгәндә генә миңа атып бәрде.

Мин инде бик әйбәтләп кенә тотып алдым. Аннары нәрсә булган,— берсен дә белмим. Ник дисәң, кинәт башым әйләнеп китте минем, өйгә йөгердем. Малайларның әйтүенә караганда, аннары ул алма сатучы, атын җай гына атлатып, безнең авылдан чыгып киткән. Кая киткән? Берәү дә белми. Авылдан чыккан чакта аның кызы, каерылып-каерылып, безнең авыл ягына таба карап барган.

Ә Госман, курнос борын, мине мыскыл итмәкче була.

— Алма сатучының кызы алманы сиңа дип атмады, үлчәү тәлинкәсенә салам дигәндә кулыннан ялгыш төшеп китте,— ди.

Мәтәштерми генә тор. Ялгыш кына төшеп киткәч, нигә соң ул минем кулга килеп эләккән, нигә Госман кулына эләкмәгән?

Дусын дус та син, Госман, шулай да әллә нәрсә генә бар синдә. Нигә инде кешене алай үртәргә.

Биремнәр

1. Беренче бүлектәге вакыйгага исем бирегез.

II

Аннары ул менә болай була.

Кыш узып, яз җиткәч, сабан чәчүләре беткәч, безнең яктагы авылларда, борынгы гадәт буенча, җыеннар, Сабантуйлары башланып китә... Госман белән без әллә кайчан ук сөйләшеп куйдык инде. Җыеннар башланса, ат чаптырырга барабыз. Тизрәк җитсен генә.

Көтә торгач, җитте тагын. Әлек безнең авылда җыен булды — бездә шауладылар, аннары күрше авылларда җыен булды — аларда без шауладык. Әти, ат чаптырырга барасы булма дип, алдан ук колак итемне ашап куйган иде дә...

Теләсә ни булсын, быел теләгемә ирештем. Җиңел сөякле малай дип, гел мине эзләп йөриләр. Рәхәт тә соң ат өстендә килү! Бөтен халыкның күзе синдә. Атның кайнар ялы синең битеңә сирпелә. Ә алда, биек колга башында, берсеннән-берсе матур булып сөлгеләр күренәләр. Кайдадыр кычкыралар:

— Куала, Айдар, куала!

Йөри торгач, без Мамалай җыенына ук барып чыктык.

Ат җибәрер вакыт җиткән икән. Тизрәк мәйданга, халык арасына йөгердем. Госман инде бер атка менеп тә алган. Колагына яулык бәйләгән, ал күлмәген балкытып, атның аякларын кыздырып йөргән була. Ә күзләре халыкта. Янәсе, күрәләрме аны. Яратмыйм шулай болганып йөрүне. Йөреп-йөреп баш килсәң, тагын бер хәл. Ә иң актыктан сөйрәлергә калсаң, егыл да үл инде. Иң яхшысы — егетлекне кинәт күрсәтү, кеше көтмәгәндә күрсәтү. Язгы яшен төсле ялтырыйсың, аннары югалсаң да ярый.

— Кая, минем атны кем алып бара? — дигән бер тавыш ишетеп калдым. Икеләнеп торулар бөтенесе коелды: «Бир, абый, үзем»,— дип кычкырдым. Ике минуттан мин инде ат өстендә идем.

Атның аякларын кыздырып тормадым. Хуҗасы үзе дә таякны тиз сындырырга ярата торган кеше икән.

— Әнкәсен, бик чая мал, дип сатканнар ие. Йөрәгендә булса, аягында булыр. Әйдә атлан да кит,— ди. Аты болай җиңел күренә. Тояклары да түгәрәк, борын тишекләре дә парлы, бәлки нәрсә булса да чыгар.

Киттек. Барыбыз җидәү: Госман, мин, калганнары — ят малайлар. Атлар барысы да — күрер күзгә ягымлы маллар. Уйнаклап кына баралар. Арада бер озын торыклы байтал[1] мине бигрәк тә куркыта.

Барып җиттек. Тезелдек. Чыктык. Башта бер-ике чакрым җирне барыбыз да тигез килдек дип әйтерлек. Бу араны атлар җиргә түгел, хәйләгә басып килделәр. Госман, чыгу белән дип әйтерлек, камчысын айкый башлады. Ул бездән, бер җир буе дип әйтерлек, алда бара, шулай да үз атымның чамасы үземдә, камчы тидерергә ашыкмыйм — бар нәрсәнең дә вакыты була бит.

Ниндидер юл аермасын үттек, берәү шунда кинәт кенә:

— Һа! — дип кычкырып җибәрде. Күземне ачып йомарга өлгермәдем — кашка байтал минем алга сикереп чыкты.

Мин ике бармагымны тешемә кысып, сызгырып җибәрдем һәм беренче мәртәбә атыма камчы селтәдем. Уен түгел икәнлекне ат та сизенде булса кирәк, кинәт сикереп алды, мин чак кына артка очып калмадым... Бер-ике генә сикердем, Госманның артына килеп бастым. Аның атының ухылдавы ишетелә,— бу дәртлелек түгел, хәлсезлек билгесе. Атыма тагын бер селтәнеп җибәрдем — без хәзер аның белән тигез барабыз. Тагын бер селтәнсәм, мин аны артка калдырачак идем. Госманга бу ошамады. Атына шәп кенә пар өстәмәкче булып селтәнде дә минем атның алга сузылып бара торган борынына сукты. Күземә кинәт кан бәрелде,— күрә дә, уйлый да алмадым. Ачу белән ярсып, Госманның битенә камчым белән селтәп җи-

---

[1] Байтал — яшь бия.

бәрдем. Ул чайкалды, аты өстеннән очып төшеп калды. Соңыннан гына белдем, каты сугылган икән мескенгә, алты ай буена яңагын бәйләп йөрде, ә соңыннан гомерлек яра эзе калды.

Госманнан, тагын берничә ярканаттан җиңел генә узып китсәм дә, кашка байталдан узу ансат булмады. Ул сөлек төсле сузылган, ничектер агып бара.

Сөлгегә килеп җитәргә ярты чакрым чамасы җир калганда, без икебез дә бер тигезлектә бара идек. Мәйдандагы халыкның умарта корты төсле гөжләве ишетелә башлады. Кемдер, ярсулы тавыш белән:

— Каула, Айдар! — дип кычкырып җибәрде.

Тешләремне кысып, селтәнеп җибәрдем, сөлгегә ярты җир буе калды дигәндә, минем атым кашка байталның алдына сикереп чыкты. Күзләремә яшь килде,— үзем өчен түгел, кашка байтал өчен.

Мине ат өстеннән кочаклап алдылар, ә атның муенына бик озын сөлге эленде.

2. Икенче бүлек вакыйгасын кыскартып сөйләгез.
3. Аеруча мөһим вакыйга — кабатланган вакыйга. Ат чабышы вакыйгасы кабатланмады. Кайсы вакыйга кабатланды?
4. Бүлектәге кабатланган вакыйгага исем бирегез.

Әйтерсең лә әллә ни эшләгән, мине рәхмәт белән коендыралар гына. Атның хуҗасы — Исмәгыйль абзый дигән кеше, кайдадыр күргәнем дә бар күк үзен. Аема-ваема куймыйча, мине үзләренә кунакка алып китте. Бай гына кешеләр икән, өйләре калай түбәле, капкалары буяулы, идәннәре дә буяулы,— мин элек басарга да кыймый торган идем дә, бераз кунак булганнан соң биеп тә җибәргәнмен тагын.

Исмәгыйль абзый үзе гаҗәп күңелле кеше икән... Ул җырлаганда, мин аның авызына карап утырам. Иреннәре әллә ничек, миңа таныш төслерәк селкенә, кайда гына күрдем соң мин бу кешене? Хәтерләп карыйм, юк. Берни дә искә төшми. Барысы да юылган.

Ашагач-эчкәч, мин инде кайтып китмәкче булып, ишеккә карый башладым. Кунак булу рәхәт тә, шу-

лай да ишек дигән нәрсә бар бит дөньяда. Кергән ишектән вакытында чыгып китә белергә дә кирәк.

Тик Исмәгыйль абзый минем сүзне ишетергә дә теләмәде. Бүген бездә кунарсың, иртәгә ихтыярың, теләсәң кая бар, ди. Әллә чынлап, әллә юри әйтә: кичен менә кызлар уенына барырсың, дип ычкындыра. Хәйләкәр төлке син, Исмәгыйль абзый... Кайдан белгән соң ул минем кызлар яратканны?!

Ишегалдына чыгып киттем. Матур гына бакчалары бар икән. Алма, шомырт, миләш, карлыган, чия — баш тыккысыз. Шулай да кердем. Аптырап тик торам. Дөресрәге, бүрегем белән киңәш итәм: китәргәме, калыргамы? Кинәт бер карлыган агачы дерелдәп куйды. Карлыган агачы белән бергә минем йөрәк тә дерелдәде. Ни булыр бу? Карлыган агачы тагын селкенде, мин ни дип әйтергә дә өлгерми калдым, бер кул күренде. Башыма бер карлыган ботагы килеп төште. Тагын берәү. Тагын.

Калтырап тик торам, әй. Шулай да бераздан атладым. Үзенә таба якынлашуымны күргәч, теге кулның иясе агач төбеннән кинәт пырхылдап килеп чыкты. Ул карлыган куагының теге ягында, мин бу якта. Карлыган куагы безнең билебездән генә.

— Мин сиңа бервакытны алма белән бәргән идем, исеңдәме? — ди ул, вак кына тешләрен күрсәтеп көлә. Карлыган куагы безнең билебездән генә, кыз инде шактый ук үскән, кызлар төсе кергән.

— Сез безнең авылга алма сатырга килгән идегез,— дим мин.

Ул арада баскыч төбеннән: «Вәсилә, син кайда? Өйгә кер»,— дигән тавыш ишетелә. Шулай итеп шул, кош дигәнем Вәсилә булып чыкты. Әйбәт, бик әйбәт.

Вәсилә китмәкче булды, китмәде, тагын посты. Ә бераздан пышылдаган тавыш белән:

— Син китмә! Кун бездә, кун,— дип, кыска-кыска гына әйтеп куйды. Үзе бакчадан чыкты да йөгереп өйгә кереп китте.

Узган елдан бирле байтак кына су аккан, аз-маз гына акыл да кергән. Вәсилә дигәнем минем төшемә кереп йөдәтеп бетергән алма сатучы кызы икән.

Өйгә кердем дә Исмәгыйль абзыйны күреп әйттем:

— Бүген кунам инде мин сездә, Исмәгыйль абзый,— дидем.

III

Кундым. Ә кунмаган булсам яхшырак буласы икән. Вәсилә аш өе белән ике арада әле анысын, әле монысын ташыган булып чабулап йөрде дә, күрше кызлары белән, чыр-чу килеп, әллә кая чыгып киттеләр. Ишегалды бөтенләй бушап калды. Капка төбенә чыктым. Утырып тордым. Аннары әйләнеп кергән булдым. Ә Вәсилә күренми дә күренми. Йолдызлар күренә башладылар. Әллә нинди искитмәле йолдызлар. Үзләре яшькелт, үзләре баш очында гына диярлек, катырак җырлап җибәрсәң, өстеңә коелырга торган төсле. Безнең Янбулат авылында мондый йолдызларны һич күргәнем юк ие минем. Чынлап та, әллә нинди генә булды ул кич.

Шул кичне, иптәш кызлары белән уйнап кайтышлый, Вәсилә минем янга туктап, миннән:

— Син ни атлы? — дип сорады.

Мин исемемне әйтеп өлгермәдем, ул, балаларча чытлыкланып, икенче сүзгә күчте:

— Безнең атны тәки баш китердең бит син. Ничек курыкмадың?

Мин ни дип тә әйтә алмадым, ат өстендә килү кызлар белән сөйләшүгә караганда чүп кенә икән. Вәсилә үзе шулай чикерткә генә булса да, батыр булып чыкты.

— Ник сөйләшмисең, сөйләш, сөйләш инде! — дип, минем янымда таптангалап торды да:

— Безгә тагын кил, яме, Айдар! — ди бу миңа.

5. Вәсиләләр өендәге вакыйганы «Мәхәббәт» дип атап була. Кыз егеткә, егет кызга «яратам» дими. Ләкин белеп торабыз: егет кызны, кыз егетне ярата. Ничек белдек?

Юк, мин аларга ул җәйне тагын бара алмадым. Ник дисәң, киемем әйбәт түгел минем, оялдым. Ул чук төсле, ә мин эти кәҗәкиеннән бозып теккән кыска җиңле камзулдан. Кызлар сөйсен өчен, иң элек бер пар ялтыравыклы итек, бер тужурка, сатин күлмәк, хәтфә кәләпүш кирәк...

Җәйге эшләрне бетергәч, иң кимендә әнә шуларны эшләп кайту нияте белән, шахтага китәргә булдым. Әти белән әни каршы торып караганнар иде дә, авызларын тиз томаладым. Җилкәм үсте, синең искеңнән бозып теккән камзулга сыймый башладым, дидем. Шуннан үзләре аңладылар тагын. Эш хәзер конторда, паспорт алуда. Баштан ук шикләнгән идем, дөрес шикләнгән икәнмен, конторда күземне дә ачырмыйлар. Яшелрәк әле син, диләр. Тагын бер-ике җәй Янбулат кояшы астында пеш, аннары шахта тишегенә таман гына булырсың, дип көләләр. Мәтәштермәгез, бар пешүем җиткән минем, китәм булгач китәм. Контор идәннәренә төкермәдем дә ичмасам, паспортсыз-нисез киттем дә бардым.

Юлда Кәче авылы кешеләренә очрап, алар белән бардык. Безнең ярты авыл шахтада, үзебез урнаштырырбыз, диделәр. Яшькә яшь булсам да, буем бар минем, кулларым да бар. Кәче кешеләре ошатып ук куйдылар. «Молодец, йөрәгең җиткән»,— диләр.

Голубовка дигән шахтага килеп җиттек.

Нужаны мин безнең авылда гына дип уйлаган ием, монда да бар икән ул нужа, монда әле озынрак сакаллысы көтеп торган икән.

Эчмәдем, тартмадым, ике ай дигәндә, саф унбиш сум акча җыйдым.

Шулай да Вәсилә искә төшә, каһәр.

Табылмаган мал тау чаклы, диләр. Этиләр дә кайт та кайт дип, хат артыннан хат тупырдатып торалар. Вәсиләне дә сагындым, кайтмый булмас, ахры.

Ләкин китәр алдыннан эшләгәндә бәйләнеп теңкәсенә тигән техниктан Айдар үчен ала.

IV

Кайтып бер-ике көн тормадым, Кәҗә Шаяхмәт малае кайткан икән, баеп кайткан икән дигән хәбәр бөтен авылга таралып та өлгерде. Мыек астыннан гына көлеп тик йөрим, әйдә, дан китсен, дим. Мыек дип юкны сөйлим, кайда әле мыек. Шәп-шәрә малай. Ә чынлап та, борын астында сызылып киткән кара мыек булса начар булмас ие,— кара мыек, ялтыравыклы итекләр, сатин күлмәк, кесәле чалбар, куллар чалбар кесәсендә. Урамнан узасың, бөтенесенең күзе синдә: «Әнә, әнә, Айдар узып бара!»

Башкасы бар, мыек кына юк. Хәер, төкерергә. Болай да бик әйбәт йөрим әле. Кичә Сабир кызыннан — Хәдичәдән хат алдым. Кәгазьне чәчәкләп тутырган. Хәдичә торып торсын әле, анда мине, яшь тай төсле, ефәк чукларга күмелгән Вәсилә көтеп тора торгандыр.

Әйдә Мамалайга, синең апаңнарга кунакка барабыз дип, Госманга әйтеп караган ием, риза булмады.

— Ни атна, ни шимбә, килешми ул, без эш кешесе,— дигән була.

Ә мин әйтәм, килешә, дим. Киттем дә бардым.

Авылдаш дигән булып, Госманның апасына, Ниса түтигә төштем. Бер яулык белән бер исле сабын тоттырдым — эреде дә китте. Аяк астыңа ятып үлимсәнә дигән төсле йөри. Ул чаклысы кирәк түгел, шулай да менә бу кош теледәй хат кисәген Вәсиләнең үзенә генә илтеп бирче, Ниса түти.

Ярты сәгать тә узмады, Ниса түти, шундый ук «кош теле» тотып, әйләнеп тә кайтты. «Кичкә чишмә янында очрашырбыз, шунда кил»,— дигән.

Түзә алмыйм, сезнең Мамалайда кич тиз буламы соң ул дип, Ниса түтидән сорашасым килә. Ә ул — наян хатын — үзе кыбыр-кыбыр эшләп йөри, үзе сөйләнә.

Шулай да кич җитте тагын. Итекләремне ялтыратып, сатин күлмәк өстеннән пиджак элеп чыгып киттем. Чишмә буена барып бастым,— кызлар су китерергә тотынганнар гына. Бераздан, гармонь уйнатып,

берничә егет тә килде. Рәтлерәкләрен сугышка алып бетергәннәр, ахры, болары корырак сөякләр. Шулай да, эт оясында батыр дигәндәй, миңа таба кырын күзләрен салгалыйлар. Кайдан килгән чыпчык бу, янәсе. Исем дә китми, басып тик торам. Яшькә яшь булсам да, гәүдә бар миндә. Күләгәм коточкыч озын булып сузылган. Тегеләрнең күләгәләре минем күләгәм янында чебеш кенә.

Бераздан ак чиләкләрен асып килүче Вәсилә дә күренде. Әллә кайдан ук таныдым,— төшемә кереп йөдәткән кыз. Нык кына үскән, тулыланган, аяклары җиргә әллә тия, әллә юк — шул, нәкъ шул үзе.

Дөньядагы бөтен нәрсәне оныттым, сикереп каршысына чыгып бастым. Әлек икебез дә телсез калдык, аннары икебез дә берьюлы сөйләшергә тотындык. Мин аңа нәрсә әйттем, ул миңа нәрсә диде,— берсен дә белмим. Шахтада күргән азаплар онытылды, ялтыравыклы итекләрем дә онытылды, ахрысы, Вәсилә аларны бөтенләй күрмәде дә бугай.

Аннары ул, озак торырга ярамый, әнкәйләр ачулана дип, чиләкләренә су алып кайтып китте...

Айдар, чишмә янында Вәсиләне көтеп торганда, тагын сугыша. Мамалай авылы егетләре бәйләнгәч, староста малаеның битен яралый. Ябып куялар. Вәсилә егетне коткара, авылдан тизрәк китәргә киңәш итә.

Киттем. Шул китүдә авылдан ук киттем. Таң атып килә. Ә ай һаман батмаган. Юл яп-якты булып сузылып ята... Әкрен генә атлап кайтып барам. Вәсиләгә әйтергә дип уйлап та, әйтелмичә калган сүзләр берсе артыннан берсе искә төшәләр. Аңа дип, әллә ничә йөз чакрым җирдән саклап алып кайткан бүләгем дә кесәмдә онытылып калган.

Ә мин аны инде кайчан күрәм? Күрәмме, юкмы?

Шул китүдән мин, үз авылыма кереп тә тормыйча, җәяүләп, Урал ягына киттем._Шул китүдән ике елга якын йөрдем. Этиләргә дә, Вәсиләгә дә бер хат та язма-

дым. Әтиләргә ник язмадым? Буләсе малым булганнан түгел, үзем акча җибәрә алмаудан хурланып язмадым. Ике имана җирне сөрдерү өчен, яз саен байлар алдында бишкә бөгелгәнен белеп торам бит мин аның. Ә мин йөрим-йөрим — тапканым үземнән артмый.

Вәсиләгә ник язмадым, үзем дә белмим. Әллә нинди кеше булып барам мин. Кемнәрдәндер үч аласы килү, билгесез ачу кайный миндә. Китсен, җәһәннәмгә олаксын Вәсиләсе, дим кайчакта.

Шулай да Вәсилә, магнит төсле, яңадан мине авылга тартып кайтарды. Йә солдатка алып куярлар, күреп калырга кирәк, дип уйладым.

6. Айдарның дуамаллык сыйфаты кабатлана да кабатлана. Исбат итегез.

Кесәмдә әллә ни рәтем юк, шулай да өс-башым рәтләдем. Кайтуым ярап куйды тагын, Мамалайда гөрләтеп туй итеп яталар, Вәсиләне Сатыш авылының кибетче Зариф малаена кияүгә биреп куйганнар. Менә хат язмый йөрсәң. Ачуымнан нишләргә белмим. Эчтә бертуктаусыз кайнап йөргән билгесез ачу хәзер әзрәк билгеле була башлады инде. Чәйнәп ташларга кеше дә бар — кибетче Зариф малае.

Шулай да иң элек Вәсиләнең үзен күреп сөйләшергә кирәк. Ниса түтине җибәреп чакырттым, килде. Агарып калган кызый. Күз карашлары авыр, керфекләре тагын да озыная төшкән төсле, балачактагы ялкыны эчкә киткән, эчтән яна белә башлаганга охшый. Үзе башлап бер сүз дә дәшмәде, үпкәләгән булса кирәк. Иреннәре әйтеп тора. Ә үзе шундый матур, шундый матур,— каршымда май ае төсле балкып тора. Эчемнән генә әйтеп куйдым:

— Ни туры килсә, шуны эшлим, ә сине кешегә бирмим.

Болай үзем шактый ук усал кыланам:

— Туеңа кайтып өлгердем тәки, Вәсилә, әйе бит,— дим.

— Кайтып өлгергәч, яхшы инде,— ди ул, күтәрелеп карамыйча гына. Салкын итеп, ачу китерә торган итеп әйтә. Мин юри, кызны үчекләргә теләп, телемә салынам:

— Кибетче Зариф малае бөтен яктан кәеф булыр инде ул. Хәзер үк авызыңны прәннек белән тыгылдырган, сөйләшә дә алмый башлагансың.

Вәсилә кинәт яшеннән курыккан төсле сискәнеп куя, нидер әйтмәкче була, әйтми, бер читкә карап, тагын тынып кала.

Нәрсәдер бар кызда: куркырга да, кире кайтырга да уйламый. Барып, ике иңбашыннан тотам. Шундый рәхәт, салкын күмер тотып катып беткән кулларым йомшап ук киткән төсле булалар. Кулларым гына түгел, күңелем дә эри. Әллә нинди яхшы сүз әйтәсем килә, тел очыма гына килми.

— Их, Вәсилә, Вәсилә. Тагын әзрәк көтмәгәнсең бит. Мин сине үзем белән алып китмәкче булып кайткан идем.

— Бернинди хат-хәбәр җибәрмичә, тагын әзрәк йөрер идең,— ди бу, һаман шулай күтәрелеп карамыйча гына. Аннары кинәт күтәрелеп карый, күзләрендәге җәһәннәм очкыннары барысы да берьюлы минем өскә чәчелгән төсле булалар.

Ә мин кем? Акчасыз кесә. Менә кем мин. Андый җәһәннәм утларына ничек чыдап торыйм:

— Ярый, хуш, алайса,— дидем дә ишеккә таба атлый башладым.

Вәсилә кинәт үзенең балалыгына кире сикергән төсле булды. Кузгалды, җиңел гәүдәсе белән очып, минем муеныма килеп асылынды. Кочаклый, үбә, үзе елый-елый сөйләнә:

— Айдар, бәгырем, бәхетсез итмә башымны. Алып кит моннан. Иртәгә кияү килергә тиеш, ә син бүген алып кит. Синнән бүтән кеше юк минем өчен. Булмады, булачак түгел. Китик, җан кисәгем!

Болай булгач шатланырга, көләргә кирәк, ә ул, тинтәк кыз, елый. Күзеннән тозлы су агыза. Яратмыйм мин күз яшен.

— Ярый, авызың прәннек белән тыгылмаган булгач, бик яхшы. Бүтәнен рәтләрбез. Иртәгә кичкә әзерләнеп тор. Атка салам да алам да китәм.

Кызны шулай тынычландырдым да үзем, кешегә-карага күренмичә, тиз генә авылга кайтып киттем.

Икенче көнне, Сәфәргали җизнинең күк айгырын — төпкә, Госманнарның кара туры алашаларын прәшкәгә җигеп, пар ат белән киттек тә бардык. Әни:

— Кая болай җенләнеп йөрисез? — дип төпченмәкче булган иде дә:

— Кайткач күрерсең, җыеныбрак торыгыз,— дигәч, үзе шуннан аңлады бугай инде.

Госман, мин, атларны тотып торырга тагын бер малай алдык.

Барып та җиттек. Әле ярый Ниса түтиләрнең өйләре басу капкасы төбендә үк. Атларны ишегалларына кертеп, туармыйча гына куйдык. Теге малайны атлар янына бастырып, Госман белән без бакча артлатып кына киттек.

Вәсилә белән кичәнәк сөйләшенгән. Чыкмый да чыкмый.

Бераздан, кайдандыр еректан, эреле-ваклы кыңгырау тавышлары ишетелә башлады. Кияүне алып киләләр, кияү кайдадыр шушында, якында гына. Йөрәгем дөп-дөп тибә, әгәр Вәсилә чыкмаса...

Юк, чыкты. Әнә бакчага таба килә. Нәкъ сөйләшенгәнчә, кулында комган. Әнкәсе баскыч төбенә чыгып, йомшак кына итеп нидер дәште дә кереп китте. Кереп китмәсә дә, барыбер алып китәчәк идем кызын. Тудырган, үстергән — аның эше бетте, үскәч алып китү — безнең эш.

Вәсилә нечкә генә итеп тамак кырып куйды. Күз ачып йомганчы ул минем кулымда иде инде. Күтәреп алып бардым да җайлап кына бакча коймасының

өстенә куйдым, койманың теге ягыннан Госман кулын сузган.

Кызның уңганлыгына тагын бер кат иман китердем — очынып кына тора. Ник кенә куркып карасын. Ә бит без аны киявенең авызыннан диярлек тартып алып китәбез.

Ун минуттан без инде юлда идек.

Бүген инде безнең өйдә ыгы да зыгы. Әни йөри чабулап, Зөһрә апа йөри чабулап, мәче йөри чабулап. Килен үзе дә җиңнәрен сызганып алган, итәк кыстырулы, кулы кулга йокмый.

Хәер, үземнең дә кәеф күтәренке — өйләнәм дигән сүз бит.

Элек карт-коры, күрше-күлән, туган-тумача җыелып, үзләре генә утырдылар, безне кертмәделәр. Кич белән без утырдык, картларны кертмәдек. Мулла никахны укыды, Вәсилә хәзер минеке инде, теге вакыттагы төсле, алма белән атып кына китә алмас.

Әни ак келәткә бик әйбәтләп урын җәеп куйган, узганда-барганда кырын күзне салып йөрим. Шулай да кызны алып кайтышкан иптәшләрне, аннары тагын — җәйнең эсселегеннән авызлары кибеп йөри торган барлык авылдашларны бер сыйламыйча ярамый бит...

Егетләр телләренә салына башладылар, болай сыйлагач, иртәгә без сиңа тагын бер кыз урлап алып кайтып бирәбез, диләр. Ул мине мактау, ул этине мактау, фәрештә сөтеннән оешкан кешеләр булдык та калдык.

Үземне мактауга чыдап та утырган булыр идем, бервакытны Госман Вәсиләне мактый башлады. «Кызга тиендең инде, Айдар, кадерен белеп кенә тор, билен сындыра күрмә»,— ди. Тагын әллә ниләр лыгырдый. Түзмәдем, өйалдына чакырып чыгардым тегене.

— Йә телеңә салынмыйча гына утырасың, йә мин сине тәрәзәдән атам,— дидем.

Һаман тыелмый бу, ә күзләре шундый хәтәр ялтырый.

— Телемне өзеп алганчы, әйтәсе сүземне әйтеп бетерим дип тырышкан ием, ярый инде алай булгач, әйтәселәрен дә әйтми калдырам.

Эчемдә нидер кайнап уяна, бервакытта да болай булганым юк иде. Мин хәзер аңа тик тор дип түгел, сөйлә дип бәйләнәм. Ә ул, юри минем ачуымны китереп, күзгә карап тик тора.

Шулай да теленнән ычкынып китте:

— Нигә ул чаклы ярсырга аңа. Үзең дә тик кенә йөрмәгәнсеңдер әле... Вәсиләнең дә җаны бар ич. Син булмасаң, монда без калдык.

Моннан да артыгы кирәк түгел. Йә ул моны ничек булса да күрсәтеп бирә, йә мин үземнең бөтен еланнарымны берьюлы аның өстенә җибәрәм.

Эшнең шуңа таба баруын ул үзе дә сизде, ахрысы, кулын минем нәкъ күзләрем алдына китереп терәде. Аның чәнчә бармагында кашы йөрәк төсле итеп коелган көмеш йөзек ялтырый иде.

— Укы! — диде ул, миңа йөзек кашын күрсәтеп.— Монда нәрсә дип язылган?

Чынлап та, йөзек кашында кечкенә генә булып «Вәсилә» дигән исем янып тора иде.

Кинәт айнып киттем, кулымны Госманның якасыннан ычкындырдым. Янган баганадай тик басып торам, кайдан тотынырга, нәрсәдән элеп алырга икәнен белмим. Ә Госман, йөрәкне бозып, һаман сөйләнә:

— Ихтимал, ул сине кайтмас дип уйлагандыр, ике елга якын бернинди хәбәрсез йөрдең бит.

Бер сүз дә дәшмим, басып тик торам. Каршымда сукыр ут яна, әллә шул сукыр уттан тотыныргамы?

Күпме басып торганмын, чайкалып, башымны күтәреп җибәрдем. Өйдә шаулашалар, ник шунда асты өскә килми. Госман кереп китте. Ә мин нидән тотынырга белмичә торам да торам. Вәсилә чыкты. Чыкканда кояш төсле иде, мине күргәч, бөтенләй коелып төште.

— Нишләп болай үзең генә торасың, Айдар? Башың авыртамы әллә? — ди бу.

Куллары белән минем башыма сузыла. Кулларын кире этәрәм.

— Бар, кереп кит,— дим.

Ул кереп китми, минем янымда басып тора, үзе дерелдәгәннән-дерелди.

— Кереп кит, диләр сиңа! — дип кычкырып җибәрәм.— Синең белән сүз соңыннан булыр, бар, келәткә кер дә көтеп утыр.

Ярый, ныклап исәпләшәсе кешем хәзер минем кулда. Калганын әкренләп сүтәрмен әле.

Бөтен бәлам дә шунда: мин эшне уйлап эшли алмыйм. Ошыймы-юкмы дип тормадым, йөгереп урамга чыктым да, зур гына бер таш табып, шуның белән үз тәрәзәбезгә — ялт. Пыяла чалтырап коелды, калганын мин күрмәдем. Өйгә әйләнеп кергәндә, мәҗлес тузгыган, кешеләр, ташны кулдан кулга йөртеп, берсенә-берсе карашалар, тәрәзәгә каршы якта утырган Саттар башын тотып изалана, аның бармаклары араларыннан кан бәреп чыккан. Таш бөтенләй гөнаһсыз кешегә эләккән икән, чамаламыйчарак җибәргәнмен шул.

Кешеләр үзара буталышкан арада, мин тиз генә таеп өлгердем. Келәткә, Вәсилә янына кереп бикләндем.

Ул келәттә ялгыз елап ята-ята шешенеп беткән. Бер сүз дә дәшмичә, аягымны салып киендем.

Аңлаша башласам, озакка китәр, үч булгач үч булсын, үзенә түгел, кроватена да борылып карамадым.

— Мин хәзер әйләнеп керәм,— дидем дә келәттән чыгып киттем. Бу минем Вәсиләгә беренче мәртәбә ялганлавым булды, икенче мәртәбә ялганларга да, дөресен сөйләргә дә туры килмәде.

Шул чыгып китүдән, беркемгә дә әйтмичә, мин тагын Донбасс ягына юл тоттым.

Без Вәсиләнең бер гаебе дә юклыгын күптән аңладык инде. Вәсилә кебек кыз хыянәт итә алмый. Госман аның йөзеген коймадан күтәреп алган чакта салдырган. Госман кебек кешеләрдән теләсә нинди этлек көтеп була.

7. Мәхәббәт вакыйгасы һәм Айдарның дуамал холкы белән бәйле вакыйгалар повесть ахырында кушылдылар. Айдарның дуамаллыгы мәхәббәтеннән дә көчлерәк булып чыкты. Василәнең кинәт бәхетсез кызга әйләнүенә кем гаепле: Айдармы, Госманмы?
8. «Язмышлар» темасына инша языгыз. Персонажларның холыкларын истә тотып, повестьтагы вакыйгаларны дәвам итегез. Сез персонажларның кайсы турында язар идегез? Иншагызны Айдар булып та, Василә булып та, үзегез хикәяләүче автор булып та яза аласыз.

Сез татар яшьләре аеруча яратып укый торган «Йөзек кашы» повесте белән таныштыгыз. Аның авторы — күренекле татар язучысы, сүзләрдән гүзәл чәчәкләр ясый белүче Фатих Хөсни.

Әсәрдә автор бөтенләй күренми кебек. Андагы вакыйгалар турында Айдар үз исеменнән сөйли, персонажларга бәяне дә ул бирә. Ләкин Фатих Хөсни — үткен фикерле, җор телле әдип. Ул хәтта эче тулы усаллык, үч булган, яшәеш кагыйдәләренә төкереп караучы Айдарын да көлке хәлгә куя. Мактанчык, шул ук вакытта үз кимчелекләрен күреп, үзен тәнкыйтьләүче, ярата белүче, ләкин барыннан да бигрәк үзен генә яратучы егет итә. Әнә шундый үзе көлке, үзе беркатлы, үзе юньсезлекнең аръягына чыккан катлаулы холыклы персонаж иҗат иткән Фатих Хөсни. Айдар кыланышларына ул аптырап та, көлеп тә, борчылып та, ә кайчак нәфрәт белән карап тора.

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Драма әсәрләре — әдәбиятның тагын бер төре. Персонажларның үзара сөйләшүенә генә корылган әсәрләргә **драма әсәрләре** диләр. Аларны башкача **пьесалар** дип тә йөртәләр. Алар сәхнәдә уйнау өчен язылалар. Драма төренең дә үз жанрлары бар. Драма төренең эчендә хәтта драма жанры да бар.

Драма жанры дип үзәгендә кискен конфликт яткан, геройлары авыр кичерешләр белән яшәгән пьесаларга әйтәләр. Ә **мелодрама** дип, эче тулы җыр, күз яше булган драма әсәрләренә әйтәләр.

Жанрларның тагын берсе — **трагедия.** Трагедия дип фаҗига белән тәмамланучы әсәрләрне атыйлар. Көлкегә корылган пьесаларга **комедия** диләр.

Драма әсәрләренең үзенчәлекләре белән танышыйк.

1. Аларның эчтәлеге кичерештән гыйбарәт. Бу ягы белән алар лирик шигырьләргә охшыйлар.

2. Ләкин драма, лирик шигырьләр кебек, кеше кичерешләренең дәрәҗәсен, сәбәбен күрсәтү белән генә канәгатьләнми. Андагы кичерешләр дәвамлы була һәм вакыйгалар эчендә ачыла. Драма әсәрләренең үзәген персонажларның үзара каршылыгы тудырган кичерешләр тәшкил итә. Якларның каршылыгы көрәшкә әйләнсә, бу төр каршылыкка **конфликт** диләр. Бу сыйфаты белән драма әсәрләре чәчмә әсәрләргә охшыйлар.

Драма әсәрләренең үзенчәлегеннән чыгып, аларга анализ бирү юлларын да билгели алабыз.

1. Драмаларда тезмә һәм чәчмә әсәрләргә хас үзенчәлекләр бар, дидек. Димәк, драма әсәрләрен анализлаганда, тезмә һәм чәчмә әсәрләрне анализлау алымнарын куллана алабыз.

2. Драма әсәрләренең үзәгендә конфликт ята икән, димәк, аларның ике өлеше конфликтка кергән яклар була.

Кәрим Тинчурин

Сүнгән йолдызлар

(Дүрт пәрдәле драма)

УЙНАУЧЫЛАР:

Сәрвәр — ятимә кыз.

Исмәгыйль — аның сөйгәне, хәзрәттә ялчы. Ятим егет.

Надир мәхдүм[1] — бөкре, гаять ямьсез, утыз яшьләрендә.

Гөлнур — Сәрвәрнең әбисе.

Фәрхи — им-том итүче карчык.

Фатыйма — Сәрвәрнең дус кызы.

Сиражи — көтүче карт.

Шәйбәк — көтүче малай.

Сафый — кабер казучы.

Беренче егет.

Икенче егет.

Беренче кыз.

Саттар — староста.

Җиһанша — авыл карты.

Писарь.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Уртача тормышлы авыл өе.

Исмәгыйль. Сәрвәр җаным, сиңа сөенеч, үземә көенеч хәбәр китердем. (*Хат бирә.*) Менә мәхдүмнән хат! Үземнең баемнан үз сөйгәнемә хат тапшырырга мин тиеш, күрәсең. Мин ялгыштым. Сәрвәр, сине сөеп мин ялгыштым. Миңа үз тиңемне сөяргә кирәк иде.

Сәрвәр. Юк, юк, Исмәгыйль, син ялгышмадың. Мин сине генә сөям. Мин мәхдүмне сөймим, сөя алмыйм. Аны кызгансам да сөя алмыйм.

Исмәгыйль. Ул да бәхетсез шул... Мин ятим, кеше кулында гомергә ялчы булуым белән бәхетсез. Ә ул үзенең зәгыйфьлеге белән бәхетсез.

[1] Мәхдүм — мулла улы.

Сәрвәр. Менә миңа өйләнгәч, бәхетле булырсың. Мин сине бәхетле итәргә тырышырмын.

Исмәгыйль. Юк, Сәрвәр, безгә кавышу насыйп булмас. Шулай да безне аерырлар. Мин төшемдә шулай күрдем. Күзге караңгы төн, имеш. Күктәге йолдызлар шундый яктылар, имеш. Безнең авыл өстендәге йолдызлар башка йолдызларга караганда яктырак, имеш. Бер урында бик күп егетләр җыелганнар икән дә, һәркайсы үзенә берәр йолдыз алган икән. Син дә шул арада үзеңә йолдыз сайлагансың, ди. Мәхдүм дә сайлаган, минем дә йолдызым бар икән. Менә кинәт аждаһа төсле бернәрсә сызгырды да йолдызларны сүндерә башладылар. Минем йолдызым да сүнде, мәхдүмнеке дә, синең йолдызың да сүнде...

Сәрвәр (*елап*). Җитәр, җитәр... Ялган төш бу, дөрес түгел.

Исмәгыйль чыга, әби керә.

Гөлнур. Сәрвәр бәбкәм, кызыл канатның оясын таптым. Келәт астына оялаган икән...

Әүвәлгеләр һәм Фәрхи.

Фәрхи. Юлым уң булыр. Өйдә икәнсез. Саумы, Гөлнур, саумы, Сәрвәр бәбкәм. Сүзне боргалап-сыргалауда файда юк. Йомышым менә шул. (*Кулы белән Надирга изи.*) Сәрвәр бәбкәм, якынрак кил әле, хәзрәтебез Надир мәхдүменнән Сәрвәргә яучы итеп җибәрде.

Сәрвәр (*сискәнеп*). Нәрсә?!

Фәрхи. Бөтен туй чыгымын хәзрәт үз өстенә ала. Бер тун, ике йон күлмәк, мамык шәл, читек-кәвеш, шәһәр юрганы, камзул, бер мамыклы, бер мамыксыз бишмәт... Бәхетең бар икән, бәбкәм. Йә, Гөлнур, туйны кайчанга билгелисез?

Сәрвәр. Әбекәем җаным, мине мәхдүмгә бирмә. Минем сөйгән кешем бар. Әбекәем бәгырем, мине хур итмә!.. Мин аны сөймим.

Фәрхи. Никах, балакай, үзе мәхәббәт тудыра... Бәлки, син аның зәгыйфьлегеннән курка торгансыңдыр?

Бер сугуда бүре үтерерлек көч бар аңарда. Әбелем, гыйлем дисәң инде — дәрья.

Гөлнур. Кем, Фәрхи, Сәрвәр бәбкәм нәрсә дисә, мин шуңа риза инде. (*Чыга.*)

Мәхдүм керә.
Әүвәлгеләр һәм Надир мәхдүм.

Надир. Исәнмесез, Сәрвәр туташ!.. Фәрхи абыстай, минем Сәрвәр туташка бер-ике сүзем бар иде, мөмкин булса...

Фәрхи. Ярый, ярый, мәхдүм, мин дә чыгам. (*Чыга.*)

Сәрвәр. Фәрхи түти, чыкма. Юкса мин дә чыгам. (*Чыкмакчы була.*)

Надир (*каршы төшеп*). Сәрвәр туташ... Мине ярат-мавыгызны хатларыма җавап бирмәвегездән үк аңладым. Ләкин сез мине аңламыйсыз әле. Минем тышкы күренешем шайтанга охшаса да, миндә җан, йөрәк бар. Бәлки, минем җанымны, йөрәгемне аңларсыз.

Сәрвәр. Мин сезне, Надир мәхдүм, кызганам.

Надир. Мине кызганган кеше — минем дошманым. Мине Алла кызганмаган бит. Адәмнәр дә мине кызганмасыннар. Менә мин, Сәрвәр туташ, Алла тарафыннан җәберләнгән Сәләх хәзрәт баласы, зәгыйфь, шайтан кыяфәтле, гурбун мәхдүм. Сезнең мәхәббәте-

гезне сорарга килдем. Сез мине бервакытта да өзелеп сөя алмассыз... Мин аны беләм. Сез миннән җирәнмәсәгез, шул җитә. Ә мин сезнең аяк астыгызда гомергә туфрак булыр идем.

Сәрвәр. Мин сезне кызганам.

Надир. Мин сездән үтенәм, мине кызганмагыз... Мин ялгыз идем. Аңлыйсызмы, егерме биш яшькә кадәр ялгыз идем, сез ул ялгызлыкның авырлыгын белсәгез иде... Менә ике елдан бирле мин шул ялгызлыктан котылып тора башладым. Сез коткардыгыз, Сәрвәр туташ. Мин ике елдан бирле су буйларына, зиратларга, урманнарга барып җырлыйм. Егерме биш яшемә кадәр мин җырның нәрсә икәнен дә белмәгән идем. Сез миңа җан керттегез. Дөрес, мин мөнәҗәтләрдән башка көй белмим... Менә шул мөнәҗәт көйләрендә үземнең хисләремне күрсәтә алам. Менә хәзер дә җырлыйсым килә.

Пәрдә

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук өй.

Сәрвәр, Фатыйма, Исмәгыйль, Надир, егетләр, кызлар.

Фатыйма. Сиңа, егет, ни кирәк?
Исмәгыйль. Кара кашлы кыз кирәк.
Фатыйма. Ни эшкә соң ул кирәк?
Исмәгыйль. Әнигә килен кирәк.
I егет. Анаң юк ич синең.

Гомуми көлү.

Сәрвәр. Сиңа, егет, ни кирәк?
Исмәгыйль. Ак каз канаты кирәк.
Сәрвәр. Ни эшкә соң ул кирәк?
Исмәгыйль. Очарга.
Фатыйма. И-и өтек карга! Акчаң кайда?
Исмәгыйль. Акча сезгә кирәксә, менә ул тулы кесә.

Җыр һәм оркестр.

Кызлар. Каз канаты йомшак һәм ак.

Егетләр. Каз канаты сөттәй ак.

Барысы бергә. Кыйгак, кыйгак, кыйгак, кыйгак!
Без барыбыз бүген шат.

I егет (*читтә боегып торган Надирга*). Мәхдүм, син ничек болай монда киләсе булдың? Ясин укыргамы әллә?

Гомуми көлү.

Надир. Юк, син наданны күрергә килдем.

II егет. Тешли ул безнең мәхдүм.

I егет. Мулла халкында теш тә булмаса, ул нигә ярый. Бөтен авылның казларын ашап бетерер өчен кирәк бит ул аларга.

Гомуми көлү.

Надир. Ә син, егет, теленңә салынма. Бездә дә ул бар, менә ул. (*Үртәп телен чыгара.*)

Гомуми көлү. Сәрвәр уңайсызланып аптырап тора.

I егет. Коръән укый-укый шулай үскәнме әллә бәлеш ашапмы?..

Көләләр.

Надир. Син, егет, минем белән сынашып карарга уйлыйсың, ахры. Әйдә, көчеңне сынап кара. (*Җиләнен салып ташлап.*) Сугышасың киләме? Көрәшәсеңме? Әйдә...

Егетләр. Әйдә, әйдә, Гайфулла, курыкма!

I егет. Кибәнең ишелүдән куркам, мәхдүм.

Надир. Нәрсә, нинди кибән?! (*Калтырана башлый.*)

I егет. Җилкәндәге...

Гомуми көлү.

Надир. Их син, бозау... (*Егетне кысып алып, астына салып, тезе белән баса. Бөтенесе аптырап калалар.*) Син нигә минем бөкремнән көләсең?.. Ул сиңа уңайсызламый бит. Нигә көләсең? Икенче авыз ачасы булсаң, бугазыңны өзәрмен! (*Җибәрә.*)

II егет. И-и Гайфулла, сүздә генә икәнсең. Бәлеш корсактан, зәгыйфь кешедән җиңдереп маташасың!..

Надир. Син нәрсә дисең тагы? Нигә сез мине рәнҗетәсез? Нигә рәнҗетәсез?!

II егет. Сез муллаларны рәнҗетерсең.

Надир. Мин мулла түгел. Менә мин сезнең шикелле булыр өчен монда килдем. Аңлыйсызмы, сезнең шикелле үк.

II егет. Безнең шикелле булыр өчен бөкреңне юнасы бар әле.

Егетләр көләләр.

Надир. Көлмәгез миннән, көлмәгез. Юкса мин сезне... *(Пәкесен чыгара. Кизәнә.)*

Егетләр. Ярамый, ярамый, мәхдүм!..

Кызлар чинашалар.

Сәрвәр (*барып кулыннан тотып*).Мәхдүм, сансызланмагыз. Мәҗлеснең ямен җибәрмәгез. Егетләр, мәхдүм минем кунагым. Аны рәнҗетерлек бер генә сүз әйтсәгез дә, бәхил түгел.

Надир. Рәхмәт, рәхмәт, Сәрвәр туташ. Мин куям. Мин куям... Рәхмәт, сез мине аңладыгыз. Егетләр, туташлар, сез мине үз арагыздан бүген кумагыз. Менә шунда почмакта гына утырырмын. Әйе, почмакта гына. Сез уйнагыз, көлегез, миңа карамагыз... Мин сезгә уңайсызламам. Сәрвәр туташ, менә шул почмакта гына утырырга рөхсәт итегез. Гайфулла, Шакирҗан, килегез, килешик. Миңа рәнҗемәгез. Минем ачуым чыкты. Сез әйтмәсәгез дә, бөкрелегемне дә, шайтанга охшаган кыяфәтемне дә беләм бит. Менә, кызлар, сезгә бүләк. Менә бусага ялы... Миңа каз канаты кирәк түгел... Миңа аны сатучы булмавын белеп килдем. Уйнагыз, егетләр. Җырлагыз, биегез! Мин сезгә уңайсызламам. (*Почмакка утыра.*)

Кызлар. Мәхдүм, бүләкне бик күп алгансың... Рәхмәт.

Сәрвәр. Мәхдүм, сез инде безнең шаяруларны гаепләмәгез!..

Надир. Юк, юк, һич, уйнагыз, мине бөтенләй юк дип уйлагыз. Әйе, бөтенләй юк. Менә шулай. (*Утыра.*)

I егет. Мәхдүм, без инде надан кеше, тупас телле булабыз. Мин бит болай уйнап кына, кызык өчен генә синнән көлдем. Рәнҗемә... Әйдә, безнең белән бергә уйна...

Бию башлана. Надир биегәндә, староста, писарь һәм пүнәтәй килеп керәләр. Кызлар йөзләрен яшерәләр. Аптырашып калалар.

Староста. Бу ни эш, мәхдүм?.. Килешми, килешми. Егетләр, туктагыз! Йомыш бар. Писарь, кәгазьгә карап кычкыра башла!

Писарь. Гайфулла Шәмсетдинов...

Староста. Гайфулла энем, бас шунда. Егетләр, исемнәрегез чыкканнар менә шунда килеп басыгыз!

Писарь. Сирай Нәҗметдинов, Гатаулла Фәсхетдинов, Исхак Курамшин, Исмәгыйль Әхмәдуллин, Мөбарәкша Салихов...

Староста. Башкалар монда күренми. Егетләр, хәзер каравыл өенә әйдәгез. Иртәгә калага барабыз... Киләсе елга караласыларны хәзер үк наборга чакыралар. Ярман патшасы безнең патшага каршы сугыш ачкан.

Барысы бергә. Сугыш!!!

Катып калалар. Исмәгыйль Сәрвәргә ташлана.

Исмәгыйль. Менә ул сүнгән йолдызлар каян килеп чыкты...

Староста. Йә, әйдәгез, егетләр!!!

Кызлар елашалар, егетләр чыгып китәләр.

Надир (*шатланып*). Сугыш, әһә, сугыш!.. Мин сугышка бармыйм, мин калам. Мин зәгыйфь, мин бөкре. Мин гурбун!..

Сикерә, шатлана. Сәрвәр урынында катып кала. Урамда егетләр җырлап китәләр.

Каз канаты мамыксыз,
Ир канаты бәхетсез.
Илдә ризык калган булса,
Исәнлектә кайтырбыз!..

Пәрдә

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук өй. Сәрвәр һәм Фәрхи әби.

Сәрвәр. Фәрхи әби, анам бул, үтенечемне кире какма. Ни сорасаң, шуны бирәм. Даруыңны бир. Бәлки, шифасы булыр.

Фәрхи. Менә, кызым, картларны тыңларга кирәк. Мәхдүмгә чыккан булсаң, җаның тыныч, күңелең шат булыр иде. Ярман безнең авылга килгәндә дә, аны сугышка алмаячаклар. Хәзерге заманда шундый ир үзе бәхет...

Сәрвәр. Үткәннәрне оныт, Фәрхи әби. Мин Исмәгыйльдән башка барыбер тора алмас идем.

Фәрхи. Кара әле, Сәрвәр, бирсәм бирермен дә — бик кыйммәт бит. Синнән файда итүем түгел.

Сәрвәр. Күпме теләсәң, шулкадәр ал. Шифасы гына булсын.

Фәрхи. Шифасы була инде... Үткән елны дүрт авылдан унбиш егетне калдырдым. Менә хәзер дә унлап егет көтеп тора... Бәясе кырык пот арыш булыр.

Сәрвәр. Безнең арышыбыз юк. Менә туйга дигән күлмәкләрем. *(Сандыкны ачып.)* Мә, ал, менә сөлгеләрем, теләгәнчә ал!.. Шифасы гына булсын.

Фәрхи, күлмәкләр, сөлгеләр сайлап алып, ашъяулыгына төрә.

Фәрхи. Ярый инде. Сүзеңне кире какмыйм. Ике күлмәк, унбиш баш сөлге. Бер ашъяулык алдым.

Сәрвәр. Ал, ал, теләсәң, тагын ал.

Фәрхи. Ярый, тагын алыйм берәр сөлге, алайса, күбрәк бирермен... (*Кесәсеннән бер шешә чыгарып.*) Үземнең даруларга вакытым юк. Үзеңә генә өйрәтеп калдырам. Исмәгыйльне менә шунда ян белән яткыр. Уң колагы аста булсын. Каз канаты белән сул колагын арчып ал, шуннан соң менә шул даруны колагына сал да менә монысын аның өстенә сал... Башта авыртыр, чыдасын... Шуннан соң колагы тишелеп ага башлар. Яисә авызы, күзе кыйшаеп калыр... Бисмилла әйтеп эшлә. Төшендеңме? Кешегә әйтәсе булма!

Сәрвәр. Валлаһи, таллаһи, кешегә әйтмәм.

Фәрхи. Шифасы булып, Исмәгыйль кире кайтса, тагын түләрсез.

Сәрвәр. Бик рәхмәт инде, Фәрхи әби. Даруларга үзеңнең вакытың юкмыни?

Фәрхи. Әйтәм лә бит. Урак өсте... Сау бул... Шифасы булсын!

Фәрхи чыга. Гөлнур керә.

Сәрвәр. Әби, кеше-фәлән килсә, кертмә, ямә! Исмәгыйльнең колагына дару салабыз. Мин хәзер Исмәгыйльне алып киләм. (*Чыга.*)

Гөлнур. Ярый, ярый. Илаһи, шифасы гына булсын инде. (*Чыга.*)

Урамда егетләр җырлый.

Каз канатын кызлар сата,
Ир канатын кем сата?
Ир канатын патша сата,
Туган илне елата.

Исмәгыйль, Сәрвәр.

Сәрвәр. Ишекне яп! (*Сандыктан даруларын чыгарып.*) Менә шуны хәзер колагыңа салырга кирәк. Менә күр дә тор, каладан кире кайтарырлар үзеңне.

Исмәгыйль. Әллә нишләп күңелем бер дә тартмый бит.

Сәрвәр. Соң, шулай итеп, мине гомергә елатырга уйлыйсыңмы? Мин бит синнән башка бер көн дә тора алмам...

Исмәгыйль. Ярый, тапшырдык... Алай-болай була калса, бәхил бул.

Сәрвәр. Бернәрсә булмас. Бөтен ил шулай эшли бит.

Исмәгыйль. Булса да, үкенеч юк. Анда барып та барыбер. (*Ята.*)

Сәрвәр (*канат белән колагын арчып*). Шифасы гына булсын инде. Бисмиллаһ иррахман иррахим. (*Дару сала.*) Селкенмә... тик ят!..

Исмәгыйль. Аһ, аһ!.. Үтерә, яндыра!..

Сәрвәр (*елап*). Чыда, бәгырем, чыда!..

Исмәгыйль (*сикереп торып*). Юк, юк! Чыдар хәлем юк! Үләм... (*Идән буйлап тәгәри.*) Аһ... Аһ!.. Бәхил бул!.. Безгә кавышу насыйп булмаган икән. Сәрвәр, Сәрвәр, кил, кил... Үләм. Яндыра...

Сәрвәр (*кинәт елавыннан туктап, Исмәгыйльне капшап*). Ах!.. Үлде... Исмәгыйль! Бәгырем! Бер генә сүз эндәш!.. Аһ!.. Үлде... Мин үтердем... Мин, мин... Ярдәм, ярдәм итегез. (*Ишеккә таба йөгерә.*)

Бик каты елап, һушыннан тая язып сулкылдый, ыңгыраша башлый. Урамда егетләр җырлаган тавыш ишетелә.

Пәрдә

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук өй.
Гөлнур һәм Фәрхи.

Гөлнур (*елап утыра*). Суфидан тәлинкәләр дә яздырдым... Ишан хәзрәттән дә өшкерттем. Шифасы булмады.

Фәрхи. Кара әле, идән астына ябып, ашатмыйча, эчертмичә җиде көн, җиде төн тотарга кирәк. Җен зәхмәте уразадан курка, ди.

Гөлнур. Аның инде күргән газаплары да җитәрлек.

Фәрхи. Җенен качырырга кирәк, кыйнаганыгыз бармы соң?

Гөлнур. Син ни сөйлисең? Кыйнарга ничек кул күтәрелсен?

Әүвәлгеләр һәм Фатыйма.

Фатыйма. Саумы, Гөлнур әби? Сәрвәр кая?!

Гөлнур. Әллә кая чыгып киткән. Коега-фәләнгә төшеп үлмәсә ярар иде.

Фәрхи. Кара, кем, Гөлнур, ат селәгәе эчерергә кирәк. Ат исеннән җен кача, ди.

Фатыйма. Берсенең башына җиттең, инде монысын да үтермәкче буласыңмы? Убырлы карчык!

Әүвәлгеләр һәм Надир.

Надир. Сәрвәр йоклыймы әллә?

Гөлнур. Юк, мәхдүм, качып чыгып киткән.

Фәрхи. Мәхдүм, Сәрвәргә тәрьяк ашатырга кирәк.

Надир. Чык моннан, шайтан карчык! Чык дим, юкса... (*Җилкәсеннән тотып чыгарып җибәрә.*)

Фәрхи (*чыгып барганда*). Тәүбә, тәүбә, чынлап та саташкан, ахры. Җибәр дим, гурбун шайтан! Җибәр, бөкре шайтан!

Надир. Ә, шулаймы? Гурбун шайтанмы?.. Менә сиңа! Менә сиңа! (*Җиргә егып буа башлый, Фәрхи гырылдый.*)

Фатыйма. Чү, мәхдүм, нишлисең?

Гөлнур. Үтерәсең бит. (*Аералар.*)

Фәрхи. Менә кешегә ит яхшылык. Менә бөкре шайтанга Сәрвәрне димләп...

Надир, җилкәсеннән тотып, ишектән этеп чыгара.

Каравыл, каравыл! Үтерәләр, үтерәләр!..

Гөлнур (*керә*). Менә, мәхдүм, су эч!

Надир (*су эчә*). Рәхмәт, Гөлнур әби. Әби, Сәрвәрнең хәле һаман бер көе дисеңме?

Г ө л н у р. Алга бармый. Үләр инде, ахры, мескенем. Бигрәк бәхетсез бала икән. Ата-ана мәхәббәтен күрә алмый үсте. Сөйгәненнән дә вакытсыз аерылды... (*Елый.*)

Н а д и р. Елама, әби... Менә мин дә еламыйм әле... Минем кадәре аны сөюче, минем кадәре аны ихтирам итүче дөньяда түгел җәһәннәмдә дә булмас. Шулай да еламыйм... Нигә еларга... Барыбер мине аячы булмас, мине Алла үзе дә аямаган бит.

Ф а т ы й м а. Бик кызганыч, бичара.

Н а д и р. Кызганыч шул... Ә мин көннәр буе янында утырам. Менә шул шашкан Сәрвәр янында рәхәт табам. Ул минем белән сөйләшә, җырлый. Мин дә аңа кушылып җырлыйм. Читтән караган кеше мине дә, шөбһәсез, шашкан дип уйлар, ләкин мин гомеремдә шаша алмам, мин рәхәтләнеп шашар идем, ләкин булдыра алмыйм. Шашар өчен Сәрвәр төсле җаннар, Сәрвәр төсле кеше кыяфәтендәге фәрештәләр булырга кирәк. Ә мин гурбун шайтан бит, эт бит, һи-һи-һи.

Ф а т ы й м а. Нигә алай уйлыйсыз?

Н а д и р. Алайса, бөкре пәри, мунча пәрие, һи-һи-һи. Шулай бит? Сәрвәр туташ алай дими иде: ул, мине кызганып, минем ачуымны китерә иде. Шулай да күземә туры карый ала иде. Башкалар минем күземә туры карарга җирәнәләр... Без Сәрвәр белән Исмәгыйльнең каберенә барабыз. Ул җырлый, мин Коръән укыйм... Ә беләсезме нәрсә, Сәрвәр хәзерге хәлендә миңа акыллы чагыннан да сөйкемлерәк. Ул минем белән сөйләшә. Минем күзләремә туры карый. Кулларымнан тота. Миннән чирканмый, ә бит терелсә, икенче төрле булуы мөмкин... Гөлнур әби, кара аны, Сәрвәрне сакла. Дәвалыйбыз дип, агу эчереп үтерсәгез, менә валлаһи дип әйтәм! (*Пәкесен чыгара.*) Ярты авылны суеп чыгармын. Мин чыдасы кадәр чыдадым инде... Хәзер Сәрвәр минеке... Аны миннән бер кеше дә аерып ала алмас. Их, Фатыйма, әгәр сез минем йөрәгемне ярып карасагыз, һушыгыздан таяр идегез.

Җәһәннәм анда, чын җәһәннәм. Әгәр дә Алла эләксә, үзе дә янар иде анда, ихлас, янар иде, һи-һи-һи...

Фатыйма. Һаман Аллага тел озайтасыз, алай ярамый.

Надир. Ярамый шул, тәүбә, тәүбә. Әйттем исә кайттым... Фатыйма туташ, мәдрәсәдә минем бер шәригем[1] бар иде. Шул кеше Алланы сүгә иде, Алла юк, ди торган иде. Соңыннан шул кеше ишан булды... Менә дөньяда нинди кешеләр бар. Ә мине Фәрхи карчык: гурбун эт, ди. Шәп бит!.. Ә Сәрвәр туташны эзләргә кирәк. Коега батып куюы да бар бит... Ул чагында дөньяда торырлык калмый... Иң соңгы өмет тә югала. Дөньяда өметсез торып булмый. *(Еракта «Каз канаты» көенә Сәрвәрнең җырлаган тавышы ишетелә.)* Чү... бу аның тавышы... Ул кайта...

Сәрвәр каз канатлары, чәчәкләр, үләннәр, башаклы саламнар кочаклап керә. Күлмәге сәләмә, чәчләре тузган, яланаяк, чәчләренә үләннәр ябышкан, җырлый.

Сәрвәр. Каз канаты йомшак һәм ак,
Каз канаты сөттәй ак.
Кыйгак, кыйгак, кыйгак, кыйгак,
Без барыбыз бүген шат.

Канатларын идән буйлап тарата. Шуларны рәтләп тезеп, каранып аларга карап җырлый.

Канат сатам, канат сатам!.. Кая ул — мин алам... Акчаң җитәрме соң? Үзең чибәрме соң? Мә ал, нәрсә ул? Нәрсә ул?.. Ал... Ярый, кал!.. Чү, чү, йолдызлар сүнәләр... (*Надирга.*) Син кем?.. Әйе, әйе, син теге аждаһа ялчысы... Сәлам әйт аңа... Каз өмәсенә килсен... Хәзер колагыңа салырбыз!.. Хәзер, хәзер...

Гөлнур, Фатыйма елыйлар, Надир, агарып катып, Сәрвәргә карап тора. Сәрвәр, тезләнеп, канатларын кочаклап елый. Акрын гына пәрдә төшә.

---

[1] Шәригем — сыйныфташым.

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зират. Агачлар, каберләр, кабер ташлары.
Сиражи һәм Шәйбәк.
Көтүче Сиражи ялгызы, чыбыркы очы ишеп, бер таш өстендә утыра.

Шәйбәк. Бабай, көтүне урман авызына сөрикме? Анда үлән шәп булыр.

Сиражи. Монда да яхшы әле. Теге яңгырдан соң кырлар болын төсле булып китте.

Шәйбәк. Бабай, бу каберне таныйсыңмы?

Сиражи (*борылып*). Кайсын?

Шәйбәк. Менә монысын. Менә, менә!..

Сиражи. Юк, кемнеке соң ул?

Шәйбәк. Исмәгыйль абзыйныкы.

Сиражи. Кайсы Исмәгыйль?

Шәйбәк. Хәзрәттә хезмәтче булып тора иде бит. Сугышка бармас өчен колагына дару салып үлгән.

Сиражи. Аның кабере шулмы? (*Торып чыбыркысын шартлата.*) Чыбыркысы да чыбыркысы... Елан төсле, һуп! (*Шартлата.*)

Шәйбәк. Кая, бабай, мин дә шартлатып карыйм. (*Алып шартлата.*) Син, бабай, очына кыл иш. Нықка килә.

Сиражи. Кыл булса, шартламый. Аннан соң, акрын гына суксаң да, бик авырттыра... (*торып*). Шәйбәк! У-у-у!.. Кара, әнә теге чуар тана арыш кырына китмәкче була. Кайтар үзен... Ай, таяк белән бәрмә алай. Хайванны рәнҗетмә!.. Менә шулай... (*Җиһанша керә. Сиражи аны күреп.*) Саумы, Җиһанша?..

Җиһанша. Бу синмени, Сиражи... Игеннәрне карарга чыктым. Хәлләре ничек икән. Югары оч Хисамый күреп кайткан, ат күмәрлек булып, дулкын-дулкын булып торалар, ди.

Сиражи. Бирсен инде Ходай, иген дә булмаса, кортлар шикелле кырылырга гына кала.

Жиһанша. Игеннәрне хәере белән җыярга язсын инде. Булмады исә, егыл да үл... Ярый, барып карап кайтыйм әле.

Жиһанша чыга.

Шәйбәк. Бабай, һавада карлыгачлар уйный. Төнгә тагын яңгыр булыр.

Сиражи (*кулын маңгаена куеп, күккә карый*). Бирсен Ходай, карлыгачлар уйный шул. Болай булса, төнгә дә калмас.

Шәйбәк. Бабай, әнә урман артында болытмы ул, нәрсә ул?

Сиражи. Кая? Ә-ә, болытмы әллә янгынмы? Төтенгә дә охшый.

Шәйбәк. Бая аз гына иде, хәзер әнә ничек...

Сиражи (*кулын куеп карый*). Боз булмаса ярар иде. Бик гайрәт белән килә. Әйдә, улым, көтүне авылга якынрак сөрик.

Ерактан күк күкри башлый. Чыгалар. Сәрвәр керә.

Сәрвәр (*Исмәгыйль каберенә килә. Чәчәкләрен, каз канатларын, саламнарын кабергә сибә. Күк күкри*).

Нурлар чәчеп күк йөзендә,
Алсуланып таң атар.
Ярсыз калган кыз баланы
Кемнәр генә юатыр?

Чү, чү, йолдызлар сүнә, сүнәләр, сүнәләр. Йолдызлар сүнәләр...

Каты күк күкрәп, яшен ата.

Аһ, аһ, аһ!!!

Бик каты кычкырып егылып үлә. Күк күкри. Яшен яшьни, яңгыр ява башлый. Күк күкрәве еракланганнан-еракланa.
Күк йөзе ачыла башлый.
Кояш чыга.

Жиһанша кычкырып елап кайта.

Җиһанша. Ай Алла! Ай Алла!.. Инде нишләрбез? Кая барырбыз?

Надир, картлар керә.

Надир. Ни булды сиңа, Җиһанша бабай? Нигә елыйсың?

Җиһанша. Югары арыш басуын боз сугып эштән чыгарып китте.

Барысы бергә. Ә-ә-ә!!!

Җиһанша. Күз алдымда эштән чыгарып, балчык белән аралаштырып, бутка ясап китте. Аяк өстендә бер салам калдырмады. Ниләр генә күрәсебез бар икән! Бер буразнаны исән калдырмады.

Насыйр. Картлар, кырны барып карап әйләнеп чыгарга кирәк. Исән калган җирләре табылмасмы?

Сафый. Картлар, болытны җил кире кайтарды. Тагын монда таба килә.

Кырны карарга дип, икенче якка чыгалар.
Мәхдүм ялгыз. Исмәгыйль каберенә таба килә.

Надир. Бу ни бу?.. Сәрвәр мескен йокыга киткән. Йокла, нарасый, йокла... Чәчәкләр китердеңме? Бик яхшы, чын сөешү шулай була ул. Шулай сөярга кирәк аны. Чәчәкләр, саф чәчәкләр... Ә миңа аларны китерүче булмас. Минем бит беркемем дә юк... Мин ялгыз... Туган көннән бирле ялгыз... Үлгәч тә ялгыз... Мескен, чыланып беткән... (*Җиләнен салып каплый.*) Туңма, җаным, сиңа җылы булсын... Менә шулай... Чү... Салкын!.. Сәрвәр!.. Өне юк... Өне юк... Күгәргән!.. Ул, ул үлгән... Сәрвәр үлгән!.. Ахры, иң соңгы өметем дә сүнде. Тагын ялгыз!.. Сәрвәр күгәрченем, урманнарга кем белән чыгармын, кем белән менә шушы кабер янында утырырмын?.. Моннан соң «Каз канаты»н кем җырлар? (*Елый.*) Юк-юк, елап булмый. Яшь каткан... (*Ерактан күк күкри.*) Хуш, хуш, күгәрченем, хуш дөньядагы бердәнбер куанычым... Ходай, синең җаныңны алып, актык йолдызымны сүндерде... Сукырның актык таягын сындырды. (*Кинәт торып,*

чалмасын бөтереп.) Хәзер мин үземә ни эшләргә кирәген беләм... Моның өчен һичбер кешенең мине шелтәләргә хакы юк... (*Чалмасын агачка бәйли.*) Мин үземә үзем хуҗа!!! Мин үземә үзем хуҗа!..

Асылынып үлә, бик каты күк күкри, яшен яшьни, яңгыр ява.

Пәрдә

1923 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Беренче пәрдәне тагын бер тапкыр күздән кичерегез. Анда ике вакыйга бар. Шуларны табыгыз.
2. Вакыйгаларның икесен дә мөмкин кадәр кыска итеп сөйләп карагыз.
3. Икесенең дә конфликты нидән гыйбарәт?
4. Исмәгыйльгә бәя бирегез.
5. Икенче пәрдәне хәтерегезгә төшерегез. Бу пәрдәдә дә ике вакыйга бар. Берсе — егетләр белән Надир арасындагы конфликт. Икенчесе — Надирның бик аз вакыт арасында усалдан юашка, юаштан кабат усалга әйләнү вакыйгасы, һәр ике вакыйганың конфликты нидән гыйбарәт? Аңлатыгыз.
6. Өченче пәрдәдә беренче вакыйга мондый: Сәрвәр сөйгән егетен солдаттан алып калмакчы була. Ниятнең ни белән тәмамлануын беләсез. Бу вакыйганың нигезендә Сәрвәрнең эчке конфликты ята. Шул хакта сөйләгез.

Драманың төп конфликты

Пәрдәдән пәрдәгә көчәеп, кабатланып, көчәйгәннән-көчәя барган конфликт — Надирның үз эчендәге конфликты. Беренче пәрдәдәге икенче вакыйга Надирның акылы белән мәхәббәт хисе арасындагы кискен каршылыкны ачып сала.

Ялгыз, холыксыз, ямьсез, усал Надир авылның иң чибәр кызын ярата. Ничек кенә ярата әле! Мәхдүмнең мәхәббәт хисе тышкы котсызлыгы астына яшеренгән эчке матурлыгын өскә калкытып чыгара. Ә бит ул горур, шәфкатьле, игелекле, һәркем кебек матурлыкка, бәхеткә омтылучы бик гүзәл егет икән. Мәхәббәте өчен Надир гомерен дә, җанын да кызганмый.

Менә шундый сокланырлык мәхәббәт. Ә ярата белгән кеше, кем булуына карамастан, барыбер матур. Ярату үзе тормыштагы иң зур матурлык түгелмени?

Надирның бер генә минут та тынычлыгы юк. Ул өзлексез хәсрәтләнә. Тормышның һәр ваклыгыннан үзенә шатлык эзли.

Надирның эчке тынычсызлыгының бер ягында — аның көчле мәхәббәте. Ә икенче ягында — аек акылы. Акылы белән Надир дөньяда үзен иң бәхетсез кеше дип саный. Бәхетенең вакытлы, хыялый бәхет кенә булуын аңлый. Әмма хисе белән бу уйларын читкә этәрә. Хис белән акыл арасындагы конфликтта мәхәббәт хисе көчлерәк булып чыга. Надирны шул җиңү һәлакәткә китерә.

7. Пьесаның төп конфликтын үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.
8. Бу драмада сүз язмышның кешеләргә карата рәхимсез булуы турында бара. Ә соңгы пәрдәдә сүз чыбыркы һәм хайваннар турында. Табигать рәхимсезлеге белән чыбыркы вакыйгасы арасында нинди дә булса бәйләнеш юкмы? Мөгаен, бардыр, югыйсә автор әсәренә бу вакыйганы кертмәс иде.
9. Пьесаның исемендә нинди мәгънә булырга мөмкин?

Туфан Миңнуллин

Әлдермештән Әлмәндәр

(Ике пәрдәле комедия)

Күп йөргән, күпне күргән, дөньяның ачысын-төчесен татыган, ләкин күңел көрлеген югалтмаган авылым картларына багышлыйм.

КАТНАШУЧЫЛАР:

Әлмәндәр — Әлдермеш авылы карты, 91 яшендә.
Искәндәр — Әлмәндәрнең өлкән малае, 70 яшендә.
Өммия — Искәндәрнең карчыгы, Әлмәндәрнең килене, 65 яшендә.
Хәмдебану — Әлдермеш авылы карчыгы, 70 яшендә.
Евстигней — Әлмәндәрнең Антоновка авылындагы «знаком»ы, 85 яшендә.

Йөзембикә — Әлмәндәрнең карчыгы, Гөлфирә белән бер яшьтә.

Илсур — Әлдермеш авылының 5—6 яшьлек малае.

Мансур — Әлдермеш авылы егете, 18 яшендә.

Гөлфирә — Әлмәндәр улының оныгы, 17 яшендә.

Газраил — яше билгесез, ләкин карт икәне күренеп тора.

Әҗәл — ул да яшь түгел.

Фәрештә — Газраилнең секретаре.

Пролог

Җир шарының ике түгәрәккә бүленгән картасы эленеп тора. Карта каршына, кулына күрсәткеч таяк тотып, Газраил баскан. Ул, авыз эченнән генә ниндидер аңлаешсыз бер көйне көйләп, картадан Әлдермеш авылын эзли. Таба алмагач, кинәт борыла да кесәсеннән телефон трубкасын тартып чыгара.

Газраил (*телефон трубкасына*). Сезме? Минем янга керегез.

Фәрештә керә.

Фәрештә. Тыңлыйм сезне, Газраил әфәнде.

Газраил. Кайда монда Әлдермеш?

Фәрештә. Әлдермеш... Әлдермеш... Ул авыл Европаның көнчыгышында яки Азиянең көнбатышында булырга тиештер... Менә ул! Менә...

Газраил. Кара син аны, әкәянни, кайда качып яткан.

Фәрештә. Әкәянни түгел, Газраил әфәнде, окаянный.

Газраил. Күп белмәгез! Барыгыз, бер мең биш йөз илленче номерлы Әҗәлгә әйтегез, минем янга керсен.

Фәрештә чыгып китә. Бераздан Әҗәл керә.

Әҗәл. Мөмкинме?

Газраил. Эшсезлектән интекмисеңме? Сиңа тагын командировкага китәргә туры киләчәк... Менә монда. Әлдермешкә!

Әҗәл. Анда кем бар? Хәле начармыни?

Газраил. Әлмәндәр карт. Киресенчә, җир җимертеп йөри.

Әҗәл. Алайса нигә?..

Газраил. ...Әлмәндәр картка туксан бер. Бөек Алланың кодрәтенә буйсынмыйча, бер ел артык яшәгән... Ярты сәгать вакыт бирәм, Әлмәндәрне минем янга алып кил.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

I КҮРЕНЕШ

Әлмәндәр картның ишегалды. Верстак янында ышкыланган, ышкыланырга әзерләнгән такталар өеме. Койма буенда баскыч. Өй яныннан юл уза. Әлмәндәр карт, верстак янында көйли-көйли, такта ышкылый.

Әлмәндәр. Ала карга дигән, әй, асыл кош,
Тәүбә иттең мәллә очмаска?
Тәүбә итсәң дә син, мин итмәдем
Чибәр-чибәр кызлар кочмаска.

Әй, кем бар өйдә, чәй чыгарыгыз! (*Койма яныннан узучылар Әлмәндәргә сәлам биреп узалар... Ул аларның сәламен кабул итә. Кайберләре белән сөйләшә*).

Исән бит әле. Сәйфулла... Рәхмәт... Эшкә ашыгасыңмы?.. Карале, Сәйфулла, бригадир Гаптерине күрсәң әйт, Әлмәндәр абый сиңа ахмак дип әйтте, диген. Ни өчен, дисеңме? Үзе мине мыскыл итте. Эш бирми, син карт инде, рәхәтләнеп ял ит, ди. (*Кинәт кемнеңдер килгәнен күреп, урамга арты белән әйләнеп утыра.*)

Ә мин синең сәламеңне алмыйм. Син мине мыскыл иттең. Казанда укып кайткан да бригадир булган, имеш... Ни дидең?.. Иртәгәме?.. Сарыклар абзарын ремонтларгамы?.. Рәхмәт, Габдрахман энем. Юкка гына Казанда укып кайтмагансың икән. Һәмишә[1] шулай мәгънәле бул. (*Шатланыбрак җырлый башлый.*)

Урамда Хәмдебану карчык күренә.

Хәмдебану. Исәнлек-саулыкмы, Әлмәндәр абзый.

Әлмәндәр. Шәп бит әле, Хәмдебану. Ишегалдына уз, Хәмдебану, сөйләшеп утырыйк.

---

[1] Һәмишә — һәрвакыт.

Хәмдебану (*ишегалдына кергәч*). Үзең бер дә генә тик тормыйсың, Әлмәндәр абзый. Тагын ни ясарга җыенасың?

Әлмәндәр. Бакча уртасына дача ясап куям.

Хәмдебану. Ындыр табагы чаклы бу өегез кысанга киттемени?

Әлмәндәр. Китте. Килен явызланды. Картая башлады. Картайган саен явызлана. Булмады, малайның бәхете булмады, озын гомерле хатынга туры килде... Инде менә болай, Хәмдебану, сиңа күптән әйтергә йөрим, ялгыз башың яшәве җиңел түгелдер... Әллә, мин әйтәм... Чык син миңа кияүгә... Өрмәгән җиргә дә утыртмам, җәй көннәре дачада яшәрбез.

Хәмдебану. Килешмәгәнне... Олы башың белән әллә ниләр сөйләп утырасың, Әлмәндәр абзый. Җитмеш яшьлек карчыктан көлмәсәң...

Әлмәндәр. Көлмим мин, чынлап әйтәм, Хәмдебану. Ир башым белән килен кулына карап ята алмыйм ич инде мин.

Хәмдебану. Әстәгъфирулла... Тфү, кешедән оят!

Әлмәндәр. ...Әйтмәк бар, көчләмәк юк... Үзеңә яхшылык эшләмәкче идем. (*Капканы ачып, Хәмдебануны чыгарып җибәрә.*) Муладис карчык, нык тора... Әй!.. Әй, дим. Нәрсә анда, әллә йоклап ятасызмы? Чәй чыгарыгыз!..

Өммия (*тәрәзәдән*). Самовар кайнаган, өйгә кереп эч.

Әлмәндәр. Өйгә кереп эчәргә — беткән ди минем эшем...

Өммия. Кем кушкан сиңа... Кирәкле эш эшләп йөрмисең...

Әлмәндәр. ...Килен булсаң, телеңне тый... Уңмады, уңмады малай. Әрәм үтте гомере малайның. Шулай... Чурту-матыр, дөбер-шатыр, үтте-китте яшь гомер, диген.

Чынаяк күтәреп, өйдән Өммия чыга.

Өммия. Кая куйыйм? Бал белән эчәсеңме, эткәй, вәринья беләнме?

Әлмәндәр. Китер монда... Бал тирләтә, килен, шикәр чыгар... Әллә кая югалма, кычкырырлык булмасын! (*Верстак өстенә утырып, чәй эчә.*)

Шулчак койма өстендә Илсурның чуалган чәчле башы күренә.

Илсур. Бабай, нихәл!

Әлмәндәр. А-а-а... Илсур килгән. Төш әйдә минем янга, агай-эне ак мыек.

Илсур. Төшмим.

Әлмәндәр. Ник төшмисең?

Илсур. Ату канфит бирәсең.

Әлмәндәр. Бирсә ни...

Илсур. Мин аны ашыйм да тешем авырта.

Илсур капкадан керә дә верстак өстенә менеп утыра.

Әлмәндәр. Йә Илсур, агай-эне, күрешеп җибәрик. Шапылдатып күреш. Менә шулай. Инде кил, борыныңны сөртеп куйыйк. (*Күлмәк итәген әйләндереп, Илсурның борынын сөртә.*) Менә шулай. Юкса маңкалы борын белән йөрү егетләргә килешми, кызлар сөймәс үзеңне.

Илсур. Мин аны сөртәм, ул тагын чыга.

Әлмәндәр. Йә, нинди яңа җырлар өйрәндең?

Илсур (*кычкырып җырлап җибәрә*).

Су буенда тал-тирәк,
Тал-тирәккә су кирәк;
Кыска буйлы егетләргә
Озын буйлы кыз кирәк.

Әлмәндәр. Әйбәт! Тагын, тагын.

Илсур. Тагын әле өйрәнгәнем юк.

Әлмәндәр. Киләсе юлы күбрәк өйрәнеп кил, ярыймы.

Илсур. Ярый. (*Чыгып йөгерә.*)

Өммия (*ул Әлмәндәрнең кыланышларын тәрәзәдән карап торган*). Сабый да сабый, син дә сабый.

Әлмәндәр. Синең кебек тумас борын картаймам инде. Җиде бала үстереп, балалар яратмыйсың. Алар булмаса, бу дөнья ни чуртыма... Чәең бетте, чәй чыгар.

Өммия. Үләм, кай арада чүмереп бетердең? Мин сиңа афисәнке түгел.

Әлмәндәр. Телең тагын озынайдымы?..

Өйдән, кулына чынаяк тотып, Искәндәр чыга.

Искәндәр. Әй-яй, тынычлап ятып торырга да бирмисең, әти. Кереп эчсәң булмыймы?

Әлмәндәр. Булмый... Син эч чәйне яткан килеш.

Искәндәр. Беләсең ләбаса, мин авырыйм.

Әлмәндәр. Чирләшкә! Яшь-яшь башыңнан... Җитмеш яшендә чирләп ята...

Искәндәр. Ярый инде, синең белән бәхәсләшеп буламы.

Әлмәндәр. Бәхәсләшмә дә. Ник дисәң, үзең гаепле. Авырыйм дип, өйдә ятасың. Чир ул яткан кешене эзләп йөри. Эшләгән кешедән курка. Ник дигәндә, ул аңа ябышып тора алмый, тир белән юылып төшә.

Искәндәр, чынаякларны алып, әкрен генә өйгә кереп китә. Әлмәндәр аның артыннан карап кала.

Шулай... Чурту-матыр, Гитлер тәресе, әрәм итте әзмәвердәй егетләрне...

Әкрен генә капка ачыла, аннан Әҗәл килеп керә.

Әҗәл. Әссәламегаләйкүм. Әлмәндәр атлы карт син буласыңмы?

Әлмәндәр. Әлмәндәре мин булам, карты кайдадыр, белмим. Кем дип белим үзеңне, күргән-сөйләшкән кешем түгел, ахрысы.

Әҗәл. Бабаң кырыкта, атаң кырык биштә дөнья куйганнар. Син нишләп туксан бергә җиттең?

Әлмәндәр. Дөньялар үзгәреп, дөньялар матурланмаса, мин дә кырыктан әллә ни узмый идем... Туктале,

чурту-матыр, бар, үтбәләвәй, эшемне калдырып йөрмә. (*Кулына ышкы ала.*)

Әҗәл. Мин шаярырга килмәдем, Әлмәндәр. Мин шаяра белмим.

Әлмәндәр, аптырап, Әҗәлгә карап тора да кинәт артка чигенеп куя.

Әллә таныдыңмы, Әлмәндәр?

Әлмәндәр. Син Әҗәлме? Ник килдең? Мин сине чакырмадым.

Әҗәл. Теге чакларда да син мине чакырмаган идең. Ходаның кодрәтеннән узып, артык яшәгәнсең... (*Кесәсеннән кәгазь чыгарып.*) Менә шушы урынга кулыңны куй.

Әлмәндәр. Нәрсә ул?

Әҗәл. Повестка. Шуңа кулыңны куюың була, туптуры безнең шеф Газраил янына юнәләсең.

Әлмәндәр. Бик тиз була түгелме соң?

Әҗәл. Нинди тиз? Туксан бергә җит тә тиз, имеш.

Әлмәндәр. Ярый, уйлап карармын.

Әҗәл. Бернинди уйлау юк. Бер генә адәм баласының да мине җиңгәне юк әле. Галимнәр дә, патшалар — барысы да җиңелеп киләләр.

Әлмәндәр. Эшлисе эшләрем бар бит әле.

Әҗәл. Бер генә адәм баласының да дөньядагы эшне эшләп бетергәне юк.

Әлмәндәр. Менә хәзер үк дисеңмени?

Өммия (*тәрәзәне ачып*). Әткәй, кер әле. Нигәдер Искәндәр авырайды. (*Тәрәзә ябыла.*)

Әҗәл. Искәндәр дигәне малаеңмы? Чирлиме?

Әлмәндәр. Синең җилең кагылгандыр?

Өйгә таба бара. Аңа Әҗәл иярә.

Әлмәндәр. Кирәсе булма өйгә!

Әҗәл. Карап чыгыйм, бәлки ярдәмем кирәктер.

Әлмәндәр. Бусагадан атлыйсы булма, мин чыкканны көт.

Әҗәл. Сүзеңне тыңлыйм, Әлмәндәр. Тик озаклама, чык.

Әлмәндәр кереп киткәч, ишегалды буйлап йөренә, тәрәзәгә үрелеп, өй эчен күзли. Әлмәндәр өйдән чыга.

Әҗәл. Хәле ничек?

Әлмәндәр. Берни булмаган. Җибадур кебек таза кешегә ни булсын. Иркәләп үстердем малайны да, хәзер иркәләнеп ята. Хатыны да үзенә тиң, чебен тимәс чер итәр. (*Верстак янына барып, ышкылый башлаган тактасын ышкыларга керешә.*)

Әҗәл. Нишләвең, Әлмәндәр, сөйләштек ич.

Әлмәндәр. Нәрсә сөйләштек? Чуртым да сөйләшмәдек. Син сөйләдең. Мин тыңладым.

Әҗәл. Мин чыкканны көт, дидең, кулыңны куй.

Әлмәндәр. Куярмын, ашыкма. Тотып тор тактаның теге башыннан.

Әҗәл. Син минем белән алай сөйләшмә... Ачуым яман минем, мине тыңламаганнарга рәхимсез мин.

Әлмәндәр. Күзең чыкмаган булса күр, җыенам бит.

Әҗәл. Үләргә җыенган кеше такта ышкыламый.

Әлмәндәр. Ахмак! Минем каберемә чардуган кирәк булачакмы? Чардуган корыр өчен такта кирәкме?!

Әҗәл. Анысы икенче эш, әйдә, тизрәк ышкыла.

Әлмәндәр. Туксан бергә җиткәч, тиз ышкылап булмый шул. Тот дим тактаның теге башыннан.

Әҗәл. Мин монда такта башы тотарга килмәдем.

Әлмәндәр. Алайса, көт. (*Такта ышкылый, үзе җыр суза.*)

Ала карга дигән, әй, асыл кош,
Тәүбә иттең мәллә үлмәскә?
Син тәүбә итсәң, мин дә иттем
Әҗәл дуска кулым бирмәскә.

Әҗәл. Ә син нигә үзең эшлисең? Бүтәннәр эшләр иде чардуганыңны.

Әлмәндәр. Үз эшемне кешегә калдырганым юк.

Ә җ ә л. Карап-карап торам да, бик ни күренәсең... Бик алай нитмә, синең кебекләрне күргән мин.

Ә л м ә н д ә р. Мин дә сине күргән.

Ә җ ә л. Аһа! Ошый башладың әле син миңа, картлач. Кайберәүләр, мине күргәч, мәлҗерәп төшәләр. Кул куйганда, куллары калтырый. Алып китүе дә кызык түгел. Күрәм, синең белән шактый ук кызык булачак. Болай булгач көтәм, әйбәтләп ышкыла чардуганыңның тактасын.

Ә л м ә н д ә р. Карылдап торма янымда, бар, урамга чыгып утыр.

Ә җ ә л. Юк, мин синең яныңнан китмим.

Ә л м ә н д ә р. Эшләгән кеше янында торганчы, пес иткән кеше янында тор.

Ә җ ә л (*авызын зур ачып, рәхәтләнеп көлә*). Шәп! Күптән көлгәнем юк иде. Куеп тор эшеңне, Әлмәндәр, утыр яныма. Тагын көлдер мине.

Ә л м ә н д ә р. Такылдап утырма, чурту-матыр, килгән юлыңнан кире кит.

Ә җ ә л. Ничек инде кит?.. Ничек аңларга?

Ә л м ә н д ә р. Шулай. Кыягазыңа кул куймыйм. Газраилең үзе килсен.

Ә җ ә л. Алай булмый.

Ә л м ә н д ә р. Була. Минем анда барырга вакытым юк. Өйләнәсем бар.

Ә җ ә л. Нишлисең бар?

Ә л м ә н д ә р. Өйләнәсем.

Ә җ ә л (*тагын рәхәтләнеп көлә*). Әкәмәт кеше син.

Ә л м ә н д ә р. Нигә авызыңны ерасың? Әгәренки беләсең килсә, сугышта югалган дүрт малаемның икесе өйләнмәгән иде. Үзем өчен бер өйләндем, бер малаем өчен икенче өйләндем, икенче малаем өчен тагын бер өйләнәсем бар. Ә син, тинтәк, җанымны сорап килгәнсең.

Ә җ ә л. Гафу ит, мин сорамыйм, Әлмәндәр, таләп итәм.

Ә л м ә н д ә р. Куркытты. Әлмәндәрнең мыегы да селкенмәде.

Әҗәл. Алайга китсә... (*Әлмәндәр өстенә килә.*)

Әлмәндәр (*такта күтәреп*). Килеп кара.

Әҗәл. Әлмәндәр, кызмыйча гына, сабыр гына уйлап кара әле...

Әлмәндәр. Уйларга вакытым юк. Күтәр теге такталарны.

Әҗәл. Нишләтәбез?

Әлмәндәр. Такта ташыйбыз.

Әҗәл. Кая? Нәрсәгә?

Әлмәндәр. Төпченмә. Ташып бетергәч күрерсең.

Әҗәл. Вәт эләктем. (*Такталар күтәрә.*)

Ут сүнә.

II КҮРЕНЕШ

Алма бакчасы. Бакча рәшәткә белән уратып алынган. Рәшәткә яныннан сукмак үтә. Сукмактан узучылар Әлмәндәргә сәлам биреп узалар. Әлмәндәр җавап бирә, Әлмәндәр белән Әҗәл алачык ясыйлар. Әҗәл кадаклый, Әлмәндәр тактаны тотып тора.

Әлмәндәр. Чүкеч сабын алай тотмыйлар, сарык, бармагыңа сугасың. Менә болай тот. Әйдә, әллүр... Ярый, ял итеп ал. Йә минем урынга үзең аягыңны сузарсың...

Берсе — бүкәнгә, икенчесе алачык идәненә утыралар.

Әҗәл. Ял итик бераз.

Әлмәндәр. Алып китәм, дисең инде, ә?

Әҗәл. Шулай итәргә туры килә, Әлмәндәр... Сабыр гына уйлап кара әле, Әлмәндәр. Тагын, әйтик, утыз ел яшәдең, ди. Ул яшәүнең ни кызыгы? Кемгә кирәк син?

Әлмәндәр. Шаярма, Әҗәлетдин. Үзең ишеттең, присидәтел, лифкавай машинасы белән бакча янына туктап, нәрсә диде? Печән өябез, нигә эскерт башында торырга чыкмадың, Әлмәндәр бабай, дидеме?

Әҗәл. Ул бит көлеп әйтте. Күреп тордың, елмайды.

Әлмәндәр (*көлеп*). Тагын эләктең, Әҗәлетдин. Кеше мине күреп елмая икән, мин кирәк дигән сүз

була. Минем яннан елмаеп киткәч, бүтәннәр янында да елмая ул. Аның елмайганын күреп, бүтәннәр дә елмая. Минем аркада ничаклы кеше елмая. Шуннан соң кирәк булмыйммы инде мин?

Әҗәл. Өйләнәм диюең нәрсә инде? Туксан бер яшьлек картка кем чыксын?

Әлмәндәр. Чиләгенә күрә капкачы табыла... Тукта! Хәмдебану килә. Минем хатын булырга тиешле карчык... Ризалыгын бирсен. Өйләнәмме, өйләнмимме — анысын күз күрер.

Әҗәл. Хәмдебану ризалыгын бирсә, минем кәгазьгә кулыңны куясыңмы?

Әлмәндәр. Бәйләнчек эт булдың. Куйсам куярмын инде, чурту-матыр, мәтәлеп кит.

Әҗәл. Бар, алайса, тәвәккәллә.

Рәшәткә янында Хәмдебану күренә.
Әлмәндәр рәшәткә янына килә.

Әлмәндәр. Хәмдебану! Хәмдебану, әллә үпкәләдеңме?

Хәмдебану (*борылып килеп*). Үпкәләмәскә соң, Әлмәндәр абзый, тузга язмаганны. Үземнән үзем оялып йөрим. Башка берәү шулай дип әйтсә, таяк белән башын бәреп ярыр идем.

Әлмәндәр. Миңа ник сукмадың?

Хәмдебану. Сүзләрең тозсыз булса да, эчеңдә явызлык юк синең, Әлмәндәр абзый.

Әлмәндәр. Рәхмәт сүзеңә, Хәмдебану...

Бакча ягына Өммия чыга, Хәмдебану белән Әлмәндәрнең сөйләшеп торуын күреп, колак сала.

Бигрәк кире беткән хатын булдың. Өзеп әйтәсең инде, алайса? Миңа кияүгә чыкмыйм, дисең.

Өммия. И-и-и... И Аллам! И Ходаем! Үләм, үләм!.. Тагын ниләр кыланырсың икән? Әйтәм, малаеңа кереп әйтәм, урамга чыгып кычкырам, белсеннәр кем икәнлегеңне. (*Кереп китә.*)

Әҗәл. Көлдермә үзеңнән, әйдә, кулыңны куй да, китик тизрәк.

Әлмәндәр. Хәмдебану ризалыгын бирмәде, тыңлап тордың.

Әҗәл. Аның ризалык биргәнен көтсәң... Булмаганны өмет итмә...

Искәндәр чыга.

Искәндәр. Менә шулай, эти.

Әлмәндәр. Нәрсә шулай?.. Нәрсәнең шулай икәнен белмисең бит, улым. Хатының әйтә, кызык-кызык дип кенә яшәде, ди. Кызыкның нәрсә икәнен белми, мәгънәсенә төшенми... Хәлең ничек?

Искәндәр. Юк ла инде, беткән.

Әлмәндәр (*кинәт үзгәреп*). Зарланма! Зарланасы булма!

Искәндәр. Үзең сорыйсың бит.

Әлмәндәр. Яхшы диген. Көл! Җырла! Бие! «Шулай»ның мәгънәсе шунда, кызыкның да мәгънәсе шунда. Әгәр, син зарлана дип, мин зарлансам, син сукрана дип, мин сукрансам, ни була... Бераз гына утырып тор. (*Чыгып китә дә бераздан бер чирекле шешәне кочаклап керә.*)

Искәндәр. Ансыз гына сөйләшик.

Әлмәндәр. Нәрсә сөйлисеңне беләм... Эчегән бал эчеп, җырлашып утырсак, икебезгә дә шифасы тияр. (*Кружкага бал салып.*) Йәле, тотып куй.

Искәндәр балдан авыз итә дә кружканы Әлмәндәргә суза.

Менә шулай, улым.

Искәндәр. Нәрсә шулай?

Әлмәндәр. Үләргә ашыкма, дим... Син әле дүрт энекәшең өчен дә яшәргә тиеш. Кызык менә шунда була: сиңа Әҗәл килеп әйтә, Искәндәр, саубуллаш дөнья белән, ди. Барыбер зарланып ятасың, ди. Риза булмаска кирәк. Алдарга кирәк Әҗәлне.

Искәндәр. Алдарсың аны.

Әлмәндәр. Ә син алда. Җаен тап. Моның вакыты җитте дип, Әҗәл килә. Куркыткан була. Ә син сер бирмисең. Ул синең белән мәшәкатьләнгән арада, көн үтә, бүтәннәр янына барырга соңга кала, синең аркада бүтәннәр дә озаграк яшәп кала. Менә шулай...

Искәндәр. Өйгә керим. (*Көч-хәл белән торып, өйгә таба атлый.*)

Әҗәл. Үз хәйләңне үзең ачып бирдең, һаман мине алдап йөртәсең. Алайга китсә... Куй хәзер үк кулыңны...

Әлмәндәр. Яза белмим бит мин, Әҗәл дус.

Әҗәл. Хәйләләмә. Председатель булып эшләдең. Кил, кулыңнан тотып яздырам.

Әлмәндәр. Орынма. «Әлмәндәр» дип искечә яза беләм. Тик аз гына сабыр ит, бал кабып куйыйк.

Әҗәл. Өйрәнеп алдым мин сине. Бал кабам дип, этлек эшләргә җыенасың.

Әлмәндәр. Кил, утыр, торма каршымда тасраеп. (*Кружкага бал салып.*) Йә, тотып куй, минем исәнлеккә.

Әҗәл. Юк, юк... Беренчедән, миңа ярамый, икенчедән, ничек инде синең исәнлеккә эчим ди? Мин бит синең янга исәнлек-саулык теләп килмәдем.

Әлмәндәр. Минем җаным өчен тот, алайса. Озакка сузма, кул да куясы бар.

Әҗәл. Шулай дисәң генә. (*Кружкадагы балны эчеп куя.*)

Әлмәндәр. Йә инде, Әҗәл дус. Күпкә түзгәнне, азга түз инде. Җырлыйммы?

Әҗәл. Ала карга дигән асыл кошны җырлама... Әллә нинди, шомлы.

Әлмәндәр. Әһә, шомлыны син дә яратмыйсың икән... Ярый, мәтәлеп кит, чурту-матыр, бүтәнне җырлыйм.

Мин җырлыймын бырдыйны —
Бырдый белән шырдыйны;
Җырламас идем шырдыйны,
Тыңлаучысы шыр тиле.

Әҗәл. Мин, Әлмәндәр, синең янга килгәннән бирле, гел синең сүзеңнән чыкмый йөрим, әйеме? Син гел мине мыскыл итәсең, әйеме? Ярамый болай, Әлмәндәр дус. Яратам бит мин сине. Яратмаган кеше белән араны тиз өзәм мин.

Әлмәндәр кычкырып көлеп җибәрә.

Йә, нигә көләсең инде, ә, нигә көләсең?

Әлмәндәр. Көлке. Үлемне әйтәм. Үлем көлке!.. (*Русча җырлап җибәрә.*)

Ассалуди, былгаруди
Гулять иттек кыз белән...

Әҗәл. Валлаһи дип әйтәм, тимәс идем мин сиңа... Ништлим... Кил, Әлмәндәр дус, кочаклап үбим бер үзеңне.

Әлмәндәр. Анысы булмый, Әҗәлетдин.

Әҗәл. Яратмыйсың син мине, Әлмәндәр, беләм. Дошман күрәсең. Эх!.. (*Әлмәндәрнең казакие өстенә ава да гырлап йокыга китә.*)

Әлмәндәр, Әҗәлнең йоклаганына ышангач, казакиен тартып алып, шыпан гына бакчадан чыгып ычкына.

Пәрдә

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

III КҮРЕНЕШ

Антоновка авылындагы Евстигней картның бакчасы. Евстигней умарта карап йөри.

Әлмәндәр. Ястәгнәй! Знакум!

Евстигней. Шайтан! Нихаль, Альмандар? Яхши?

Күрешәләр.

Әлмәндәр. Деревня. Свая деревня. Тибя давна ни видал.

Евстигней. Яхши! Бик яхши! Айда, кил, утыр монда. Мин да уйлаган сингa барырга. Вот умарта, бал кирәк. Син бал бар?

Әлмәндәр. Мнугы... Тибя кислый мед есть? Меня есть. Әлмәндәр мюд пил. Әҗәлдән бижал, Әҗәл спал.

Евстигней. Азяль? Кем Азяль?

Әлмәндәр. Смирт. Пришул... Яшәдек без, ә? Җырлап яшәдек. Күпме гомер бергә. Алтмыш ел, ә? Күршеләр, знакумнар... Хәтерлисеңме, безнең якка аклар килгәч, бергәләп, урманда кызылларга кушылып киткән идек. Исеңдәме, колхоз төзегәндә, мине үлемнән коткарып калганың, хәтерлисеңме, сугыш вакытында...

Евстигней. Да, много прошло.

Әлмәндәр. Яшисе килә, Ястәгнәй... Китәсе килми. Әҗәл килде миңа, сизеп торам. Шуңа күрә синең янына чаптым, җәяүләп килдем, Ястәгнәй, саубуллашып кайтыйм дидем... Хәтерлисеңме, синең Иваның белән минем Хәйретдиннең үле хәбәрләре бер көнне килде.

Евстигней. Да-а...

Әлмәндәр. Әйдә, безгә киттек, Ястәгнәй. Куып йөрсен әле безне Әҗәл.

Евстигней. Ю-ук, Альмандар. Син минеке кунак. Минем избада йоклыйсың.

Әлмәндәр. Твая снаха ругать будет.

Евстигней. Ю-ук, килин яхши. Син яратам. Посиди немного, я скажу... (*Чыгып китә.*)

Әлмәндәр, Евстигнейның битлеген киеп, умарта янына килә дә хәле бетеп туктый. Әҗәл күренә.

Әҗәл. Шулай диген, Әлмәндәр, качтым, диген.

Әлмәндәр. Ни булды дисәм, син икәнсең әле.

Әҗәл. Әйе, мин фәкыйрегез. Әйдә, Әлдермешкә кайтабыз.

Әлмәндәр. Китер кәгазеңне, кул куйыйм, котылыйм син сабакыдан.

Әҗәл. Юк, Әлдермешкә кайтабыз башта.

Әлмәндәр. Кайтырлык хәлем бетте.

Әҗәл. Хәйләләмә... Минем өчен кайда кул куйсаң да барыбер, үзең өчен әйтәм. Туган-үскән нигезеңдә, үзең ясый башлаган алачыгыңда...

Әлмәндәр. Шулай дисеңме?.. Ястәгнәй чыксын инде, саубуллашып китим.

Әҗәл. Бәлки, кирәкмәс... Ул да яшь кеше түгел, син авырайганны күрер дә кәефе китәр...

Әлмәндәр (*урыныннан торып*). Бигрәк төче теллегә әйләнгәнсең...

Әкрен генә чыгып китәләр.

Ут сүнә.

IV КҮРЕНЕШ

Әлмәндәр карт бакчасы. Эшләнеп бетмәгән алачык идәнендә Әлмәндәр белән Әҗәл утыралар. Вакыт — төн.

Әҗәл. Валлаhи, билләhи, төнлә алып китмим сине. Таң атканда, кояш чыгар алдыннан, көн уянганда. Күңелең гел яктыда булгач, үлемең дә яктыда булсын. Ә бүген төнлә син теләгән нәрсәңне эшли аласың. Уйла. Үкенечләрең калмыймы?

Әлмәндәр. Юк. Мин кылган эшләремә үкенмәдем. Эшләргә ниятләгән эшемне ахырына җиткезеп туктадым. Ярты юлда менә шушы алачык кала, тагын... тагын... Дөнья кала. Төзелеп бетмәгән дөнья кала. Төзеп бетерәсе иде. Кешеләр үлсәләр дә, ичмасам, минем яшемә җитеп, үз үлемнәре белән үлсеннәр иде.

Кыскарган күренешнең эчтәлеге: Искәндәрнең оныгы Гөлфирә белән күрше егете Мансур бер-берсен яраталар. Ләкин хисләрен сөйләргә оялып, аңлаша алмый йөриләр. Әлмәндәр, шаярта-шаярта, егетне кыюрак булырга өйрәтә. Әҗәл белән тарткалашып торган чакта, егет белән кыз килеп керә. Әҗәл белән Әлмәндәр, яшьләргә күренмичә, аларның серләшүен тыңлап торалар. Яшьләр, бер-берсенә төртке сүзләр әйтә-әйтә, ниhаять, аңлашалар. Гөлфирәнең кыюлыгына, шаянлыгына сокланып, Әлмәндәр, үземә охшаган, дип шатлана. Мансур, Гөлфирәнең дә үзен яратуын белгәч, кычкырып җырлап җибәрә. Яшьләрнең бәхетле вакытын күрү Әлмәндәргә нык тәэсир итә. Ул үзенең шундый ук яшь, бәхетле чагын исенә төшерә. Күңеленнән үзенең яраткан кызы белән тагын очраша. Әлмән-

дәр шулай үзенең яшьлеге белән, мәхәббәте белән хушлаша. Ул үзен басма өстендә итеп хис итә. Егыла язып, чайкалып китә.

Бакчага Өммия белән Искәндәр чыгалар.

Әлмәндәр. Улым, синме соң бу?

Искәндәр. Мин, әти, мин...

Әлмәндәр. Мин әле әниең белән сөйләшеп утырдым... Килен, син дә мондамыни?

Өммия (*куркыбрак*). Монда, әткәй, монда.

Әлмәндәр. Ачуланма инде, килен... Авыр сүз әйтеп, күңелеңне рәнҗеткәнем булмады бит, килен. Ачуланганда да яратып, үз итеп ачуландым.

Өммия. Шулай, әткәй, шулай...

Әлмәндәр. Әй телең, килен. Бигрәк тәмле. Сандугач кебек сайрыйсың. Шундый телне кырык ел миннән яшереп яшәдең... Минем белән әрепләшү синең үзеңә дә дөнья рәхәте бит, килен. Синең юньсез ирең көнозынына өч сүз дә әйтми. Ә хатын-кыз сөйләшмичә тора алмый... Килегез, тезелешеп утырыйк әле. (*Алачык идәненә утырып.*) Улым, син уң ягыма, килен, син сул ягыма утыр.

Утыралар. Өммия шикләнебрәк кырыйгарак утыра.

Әлмәндәр. ...Менә шулай. Күрәсезме, балалар, таң ата... (*Искәндәргә.*) Син нигә өстеңә кимәдең? Таң атканда салкын була. (*Өстендәге казакиен Искәндәр иңенә яба.*)

Өммия. Авырткан җирең юктыр бит, әткәй?

Әлмәндәр. Йөрәгем урынында түгел. Кош булып очып йөри... Килен, бар әле, Хәмдебануны чакырып кер...

Өммия. И Ходаем... (*дия-дия, бакча капкасына таба бара. Анда Гөлфирә белән Мансурны очрата*). Кайда йөрисең син бу вакытка чаклы? Дәү бабаң...

Гөлфирә. Нишләгән?..

Өммия. Нишләгән, нишләгән... Акылы җиңеләйгән... (*Китә.*)

Гөлфирә (*тиз генә бакчага керә, Әлмәндәр янына килә*). Дәү бабай...

Әлмәндәр. Бар, алып кер.

Гөлфирә. Анда беркем дә юк, дәү бабай.

Әлмәндәр. Алып кер.

Гөлфирә, бакча капкасына барып, Мансурны чакырып керә. Мансур кыюсыз гына Әлмәндәр янына килә.

Менә, Искәндәр улым, оныгыңның кияве шушы егет була. Белә идеңме? (*Гөлфирәгә.*) Дәү әниеңә охшагансың икән син, кызым, бәхетле булырсың. Кил, утыр янема. Син, кияү... Мансурмы әле исемең?.. Илсур атлы энең бармы әле синең? Алып кил. Йокысыннан уяна алмаса, күтәреп алып кил...

Мансур чыгып китә. Бакча капкасы янында Хәмдебану белән Өммия.

Әлмәндәр. Кил әле, утыр әле яныма. Кит, улым, читкәрәк, кыз белән егет сөйләшкәнне тыңлап утыру гөнаһ. Утыр, Хәмдебану, курыкма...

Хәмдебану. Утырам, Әлмәндәр абзый, нидән куркыйм. (*Утыра.*)

Әлмәндәр. Егерме биш яшеңдә ирсез калып, берәүне дә якын җибәрмәдең шул. Һаман берьялгызың. Үзсүзле хатын булдың, Хәмдебану. Димләп карадым... Сүземне тыңламадың. Үземә кияүгә чык дип бәйләндем — ачуландың. Рәхмәт, рәхмәт, Хәмдебану, сынатмадың. Ирең мәрхүмне рәнҗетмәдең. Әгәренки мин хөкүмәт башында торсам, синең кебекләргә мидал бирер ием! Ишетәсеңме, Гөлфирә кызым?

Өй ягыннан бакчага Евстигней чыга.

Евстигней. Син — шайтан, Альмандар. Кая качтың? Бакча чыгам — син юк. Аптыраш. Бригадирга барам, ат бир әйтәм. Альмандар барам... Килям. Ызба керәм — юк.

Әлмәндәр. Садис, Ястәгнәй. Сын, снохa, дучка, Хәмдебану сидим балакыем, хураша.

Өммия. Зрастуй, Ястәгнәй дәдәй. Старик не слушай. Маклашка давай. Один сад ходит, писнә поют.

Евстигней. Ничего! Яхши, килин. Ну как кайткан? Мин курыккан.

Әлмәндәр. Хураша, Ястәгнәй. Ассалуди, былгаруди. Спасибы.

Йоклаган Илсурны күтәреп, Мансур керә. Уятырга тырыша.

Тимә! Ник тиясең малайга.

Мансур. Уянмый ич.

Илсурны җиргә бастыра. Илсур җиргә утыра. Күзләрен уа.

Әлмәндәр. Таныдыңмы? Мин ич бу. Канфит кирәкме?

Илсур. Кирәкми.

Өммия. Интектермә инде баланы.

Әлмәндәр. Илсур, мин китәм бит.

Илсур. Кая?

Әлмәндәр. Уянсаң, китмим... Яле, бер җырлап җибәр әле.

Илсур. Җырлыйсым килми.

Әлмәндәр. Мин җырлыйммы соң?

Илсур. Җырла.

Әлмәндәр (*көйләмичә генә*).

Без андый малай түгел,
Без мондый малай түгел:
Безнең башлар балык түгел,
Куырып ашамаслар.

Илсур (*елмаеп*). Алай түгел.

Әлмәндәр. Ничек соң?

Илсур (*көйләмичә генә*).

Без андый малай түгел,
Без мондый малай түгел:
Кая барсак та ярыйбыз,
Күгәргән калай түгел.

Әлмәндәр. Муладис! Әйдә, хәзер көйләп...

Илсур. Алма бир.

Әлмәндәр. Хәзер, хәзер... (*Якындагы алмагачтан алмалар өзеп, Илсур алдына өеп куя.*) Менә... Булдымы?

Илсур. Булды. (*Җырлый.*)

Без андый малай түгел лә,
Без мондый малай түгел.

Илсурга Әлмәндәр кушыла.

Кая барсак та ярыйбыз,
Күгәргән калай түгел.

Әлмәндәрнең күзе алмагач артында басып торган Әҗәлгә төшә.

Әлмәндәр. Йәле, Илсур, тагын берне сыздыр. «Шырдый»ны...

Илсур. Мин җырлыймын бырдыйны,
Бырдый белән шырдыйны.
Мин җырлаганны ошатмасаң,
Үзең җырла шундыйны.

Илсур җырлаганда, Әлмәндәр Әҗәл янына бара. Әҗәлнең кулыннан кәгазь-карандаш алып, кәгазьне Әҗәлнең сыртына җәеп, кул куя. Җырның соңгы ике юлын кабатлап җырлап, алачык янына килә.

Әлмәндәр. Мин җырлаганны ошатмасаң,
Үзең җырла шундыйны.

Ут сүнә.

Эпилог

Прологтагы күренеш. Сәхнәнең бер ягыннан Газраил, икенче ягыннан Әҗәл чыга.

Газраил. Кайда Әлмәндәр?

Әҗәл. Алыгыз, сезнеңчә булды.

Газраил. Кайда үзе?

Әҗәл. Алгы бүлмәдә утыра.

Газраил. Алып кер.

Алгы бүлмәдә Фәрештәнең чәрелдәп кычкырганы ишетелә, һәм Фәрештә, атылып, Газраил кабинетына килеп керә.

Газраил. Ни булды?

Фәрештә. Ул, ул мине кочаклый.

Газраил. Кем?

Фәрештә. Карт.

Әҗәл. Карт түгел, Әлмәндәр, Әлдермештән Әлмәндәр!

Алгы бүлмәдән Әлмәндәрнең «Бырдый белән шырдые» яңгырый.

Пәрдә

Пьесага анализ ясыйк

Драма әсәрләренә анализны нәрсәдән башларга тиешбез? Алдагы дәрестә өйрәнгәннәрне исегезгә төшерегез.

Иң элек әсәрне икегә бүләргә кирәклеген беләбез. Драма әсәрләренең нигезен каршылык, ягъни конфликт тәшкил итә дигән идек. Димәк, әсәрнең ике өлешен табу өчен, андагы төп каршылыкны табарга кирәк була. Пьесаның эчтәлеген кыска итеп сөйләп чыгыгыз. Аннан соң, тагын да кыскарак итеп, үзегез иң кирәкле дип исәпләгән урынын сөйләгез. Ни өчен иң кирәк урын дип исәпләвегезне дә әйтегез.

Пьесада сүз күбрәк Әлмәндәр карт белән Әҗәл турында бара. Алар сәхнәдә күп тапкыр икәү генә калалар һәм өзлексез сүз көрәштерәләр. Хәтта бер-берсенә һөҗүм итүгә кадәр барып җитәләр. Уйлап карасак, Әлмәндәрнең башка кешеләр белән очрашуы, эшләре дә үлеме якынаюына бәйле икәнлеген күрә алабыз. Димәк, төп каршылык башка вакыйгаларны да үзенә буйсындырып килә икән. Шуннан чыгып, Әлмәндәр карт белән Әҗәл арасындагы каршылык — әсәрнең төп каршылыгы дигән нәтиҗәгә киләбез. Димәк, әсәрне ике каршылыклы өлешкә аерабыз. Бер якта Әлмәндәр карт, икенче якта Әҗәл, дибез. Ләкин алар нигә бәхәсләшәләр соң? Җавапны бик кыска итеп әйтеп бирегез.

Әлмәндәрнең дөньяда яшисе килә, ул әсәрнең ахырына кадәр шуның өчен көрәшә. Әҗәлнең Әлмәндәрне бу дөньядан алып китәсе килә. Ул да әсәр ахырына кадәр шуның өчен көрәшә. Икесе дә үз теләкләрен тормышка ашыру өчен көрәшәләр.

Истә калдырыйк: драма әсәрләренә анализ ясар өчен иң элек аны көрәшүче якларга бүләргә кирәк.

Драма әсәре эчендәге көрәшкә **конфликт** диләр. Әсәрдәге ике як көрәшен төп вакыйга итеп саныйбыз. Башка вакыйгалар төп вакыйга конфликтын көчәйтеп һәм дәлилләп киләләр.

Сораулар һәм биремнәр

1. Ике өлешне, гадәттәгечә, аерым-аерым өйрәник. Башта Әҗәлнең ни өчен көрәшүен белик. Ни өчен көрәшә, Әҗәлнең теләге нинди?

2. Хәзер каршы якны өйрәнәбез. Әлмәндәрнең теләге нинди? Ул ни өчен көрәшә?

3. Иң җиңел җавап мондый: Әлмәндәрнең үләсе килми, шуның өчен көрәшә. Әмма ул бит барыбер үләсен белә. Дөньядан китү кәгазенә үз теләге белән кул куя. Дөрес, аның әле үлемен беркадәр чигерәсе килә. Ни өчен чигерәсе килә? Әҗәлдән яулап алган аз гына вакыт аңа нигә кирәк?

4. Бу сорауга җавап бирергә кыенсынсагыз, әлеге Әҗәлдән яулап алган вакыт эчендә Әлмәндәр эшләгән эшләрне санап чыгыгыз.

Әлмәндәрнең шул вакыт арасында эшләгән эшләрен, үткән заман, бүгенге көн һәм киләчәк белән бәйле эшләр дип, өч төркемгә (өлешкә) җыеп була.

5. Әлмәндәр өчен яшәгән еллары үткән, беткән, онытылган вакыйгалар түгел. Ул яшьлегендәге матур вакыйгаларны да, хәсрәтләләрен дә күңелендә саклый. Әллә кайчан үлсәләр дә, үзе яраткан кешеләр Әлмәндәр хәтерендә бүген дә тере булып яшиләр. Ул аларны һаман искә ала, алар белән күңеленнән сөйләшә. Әлмәндәрнең үткән тормышы — аның күңел байлыгы, җанлы шатлыгы, яшьле хәсрәте. Шатлык-хәсрәтләре барысы да бер йөрәгенә сыешканнар, бергә яшиләр.

Менә шундый нәтиҗә ясап була. Ләкин бу әйткәннәр нибары нәтиҗә генә. Сез шул нәтиҗәне исбат итегез.

6. Ә бүген Әлмәндәр ни эшли? Бүген ул Әҗәл белән көрәшә... Тагын ни эшли? Шул эшләрне санап, сөйләп чыгыгыз.

7. Әлмәндәр — акыллы карт. Үләсен дә белә. Шулай булгач, ни өчен күршесе Хәмдебануга өйләнергә йөри? Күрше карчыгы кияүгә чыгудан баш тарткач, Әлмәндәр аны мактый. «Маладис карчык»,— ди. Ни өчен күршесе баш тарткач, «маладис» ди?

8. Шушы вакытта Әлмәндәр туганнарына, дусларына, күршесенә ярдәм итә. Карт ярдәм күрсәткән кешеләрне санап чыгыгыз. Ничек ярдәм итә? Сөйләгез.

9. Әлмәндәр киләчәк турында да кайгырта. Үзе исән чагында әле ул тормышның килмәгән җирләрен төзәтеп, тәртипкә китереп йөрде. Ә ул киткәч ни булыр? Бабай киләчәк турында ничек кайгырта? Сөйләгез.

10. Бабай үткәне, бүгенгесе һәм киләчәк белән яши. Һәр заманның үз шатлыклары, үз хәсрәтләре бар. Ә бит ул хисләр хәтердә вакыйгалар булып сакланалар. Үткән заман вакыйгалары, бүгенге вакыйгалар, киләчәк вакыйгалары. Бу вакыйгалар, билгеле инде, кешеләр белән бәйле. Игътибар итегез: Әлмәндәр хәтерендә кешеләргә карата үч, ачу, нәфрәт белән бәйле вакыйгалар юк. Өч заман тудырган хисләр һәм вакыйгалар үзләре Әлмәндәр картның эчке дөньясын тәшкил итәләр. Әнә бит нинди бай, катлаулы, серле һәм матур ул кешенең эчке дөньясы!

Әсәрдән Әлмәндәрнең шундый бай эчке дөньясын ничек беләбез? Ул бу хакта кемгә дә булса сөйлиме? Сөйләсә, кемгә һәм ни өчен сөйли?

11. Анализның чираттагы гамәленә күчкәнче, моңа кадәр ниләр эшләгәнне искә төшерик: башта әсәрне икегә бүлдек. Аннары һәр өлешне аерым-аерым өйрәндек. Ә хәзер, шул ике өлеш эчтәлеге ачыклангач, алар арасындагы бәйләнешне эзлибез.

Әҗәл белән Әлмәндәр язмышларын чагыштырыйк. Әҗәл — мәңгелек. Шул мәңгелеге белән горурлана да. Әлмәндәрнең гомере чикле. Үлем — аның өчен авыр хәсрәт. Әсәрнең ахырын искә төшерегез: Әҗәл үлемсезлектән баш тарта. Ә Әлмәндәр, үзе бу тормыштан китсә дә, мәңгелек истәлек калдырып китә. Димәк, Әлмәндәр мәңге яшәүче булып чыга.

Күрдегезме: әсәр нинди кызыклы каршылыкка төзелгән! Драмадагы геройларның һәр икесе үзләренең капма-каршысына үзгәртелгән. Алай гына да түгел әле. Әҗәл сәхнәгә җиңүче булып, елмаеп килеп керә, ә Әлмәндәр исә аны куркып, хәсрәтләнеп каршы ала. Әсәр ахырында, киресенчә, Әҗәл хәсрәткә бата, ә Әлмәндәр хәтта теге дөньяда да көлүен дәвам итә. Ул Әҗәлне җиңә, җиңүче булып кала.

Әҗәл ни өчен үзгәрә? Әлмәндәр ничек җиңүче була? Чынлыкта барыбер Әҗәл белән китәргә мәҗбүр була бит. Драманың әле генә өйрәнелгән башка вакыйгаларыннан файдаланып, җавап бирегез.

ЮМОРИСТИК ҺӘМ САТИРИК ӘСӘРЛӘР ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Юмористик әсәрләр дип көлкеле әсәрләргә әйтәләр. Көлкеле вакыйгалар уйлап табучыга **юморист** диләр.

Юморист чынбарлыкның җитди кимчелекләре белән эш итми. Аны көнкүрештәге эч пошыра торган чиксез күп ялгышулар, холыклар да канәгатьләндерә. Аның максаты — көлү һәм укучысын көлдерү.

Юморист яратмаган кешесеннән аны мактаган булып, яраткан кешесеннән кимчелек тапкан булып көлә.

Сатираның максаты башка. Сатира үзен әллә кемгә куйган буш кешедән көлә. Мактанчык буш кешедән кем яратып көлсен, сатирик язучы аларны мыскыл итеп көлә. Ләкин сатира, ачуы килсә, бөтен бер социаль төркемне дә, милләтне дә, илне дә хур итеп ташлый ала. Менә нинди көчкә ия әдәбиятның бу жанры!

Кемнең дә булса кимчелеген табып, ул кимчелектән ачы итеп көлүгә **сатира** диләр. Ә сатира әсәрләрен иҗат итүче **сатирик** була.

Юмор белән сөйләү сәләтенә ия кеше элек-электән абруй казанган (Хуҗа Насретдинны яки Әлмәндәр картны искә төшерик). Андый кешеләр, гадәттә, башкалар белән дә уртак телне тиз таба, кыен вакытларда төшенкелеккә дә бирелми, кайгылы кешеләрне дә юата. Чит илләрдә андый кешеләрне теләсә кайсы эшне бүтәннәрдән яхшырак башкара дип исәплиләр. Бер эштән икенчесенә күчкәндә бирелгән таныкнамәдә, иң күркәм сыйфаты итеп, юмор хисенә ия булуын күрсәтәләр.

Юмор-сатира белән бәйле тагын бер бик матур атама бар: көлкеле вакыйга уйлап табучыны, юморны тыңларга һәм юмор әсәрләрен укырга яратучыларны, хөрмәт итеп, **үткен фикерле кеше**, диләр.

«Көлке көлә килә, артыннан куа килә»,— ди халык мәкале: чамасын белеп көлдер, урынсыз көлмә — хур булырсың, дип кисәтә. Юморист белән сатирик андый ялгышны эшләмиләр.

Без ни өчен юмор һәм сатира әсәрләрен өйрәнәбез?

Мюнхгаузен маҗаралары турындагы китапны укымаган яки ишетмәгән кеше аздыр. Шул китапның авторы Эрих Распе китабының керешендә менә ничек язган: *«Мюнхгаузен маҗаралары турында язам. Максатым — сезне көлдерү, көлдереп күңелегезне күтәрү. Ләкин шуның өстенә иҗади фикерләргә өйрәтү. Уегызны тапталган сукмактан аерып, үз сукмагыгызны салырга күнектерү»*,— ди.

Дәреслеккә юмор-сатира бүлеге шушы максатны күздә тотып кертелде.

КИЛЕШКӘН БУЛЫП ШУНЫҢ КАПМА-КАРШЫСЫН ӘЙТҮ АЛЫМЫ

Юморист та, сатирик та гадәти фикерләүче кешеләр кебек уйлый, ләкин, гадәти сөйләмнән аермалы буларак, алар баштагы әйтелмә эченә кетмәгәндә генә тагын берне — баштагысына капма-каршы булган әйтелмә салып куя. Шул сәбәпле юморист яки сатирик башкалар бер генә нәрсә турында уйлаган арада ике нәрсә турында уйлап өлгерә һәм тыңлаучысын, яки укучысын аптыраштa калдыра.

Башкача әйтик: юмор алымнарының иң таралган алымы — **килешкән булып шуның капма-каршысын әйтү.**

Бер энәгә — бер сыер

(Мәзәк)

Чит илдә әйберләр арзан дип, Әхмәт авылын ташлап китәргә җыена.

— Бәяләр кайда да бер ул. Кеше сүзенә ышанып ялгышма,— дияр иде авылдашы. Ләкин ул үткен фикерле кеше икән, Әхмәт белән ризалашкан булып, читтәге арзанлыкның ялган булуын бик нык арттырып әйтә:

— Шулай, читтә бар нәрсә дә арзан: «Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер бирәләр»,— дип көлә.

Истә калдырыйк: авылдашы Әхмәт әйткәнне кире какмады, «ялгышасың» димәде. Киресенчә, хуплады. Читтә, чыннан да, бар нәрсә дә арзан, диде. Ләкин аның хуплавында бөтенләй башка бәя ята: «Бер нәни энәгә бөтен бер сыер алмашканны каян күргәнең бар, тиле»,— ди мәкаль әйтүче. Үткен фикерле агай арттыру алымы белән юмор тудырды.

Әйбәт эт

— Гали, синең этең ят кешене үзенә якын китерәме? — дип сораган Вәли.

— Әлбәттә, якын китерә. Якын китермәсә, ничек тешләсен, ди, ул аны.

Каршылыкны бергәләп ачыклыйк

Мәзәкнең беренче өлешен үз сүзебез белән әйтик: «Вәли Галидән этең усал түгелме?»— дип сорый. Үзенә якын китергән эт усал булмый, дип уйлый. Вәли усал түгел, дип җавап бирә (эте якын китерә бит). Мәзәкнең беренче өлешен таптык. Ул Вәли этенең юашлыгы турында икән.

Мәзәкнең икенче өлеше беренчесенең киресе — Вәли эте усал икән.

Ләкин Вәли Галигә каршы әйтмәде, «Якын китерәме?» соравына «Якын китерә» дип җавап бирде. Ләкин «якын китерә» сүзләрендәге юашлык мәгънәсе хәзер үзенең капма-каршысына әйләнде.

«Якын китерә» өземтәсе ике мәгънәле булып чыкты. Вәли аңа «тешләмиме» мәгънәсен салган булса, Гали шуны белә торып, юри «тешли» мәгънәсен салды.

Уңай бәя астына кире бәя салу — үткен фикерле кеше табышы ул.

Бирем

Мәзәкләрдәге автор табышын аңлатыгыз.

Тәртипле бала

— Безнең Хәсән ошадымы сезгә? Бик тәрбияле бала, шулай бит? — дип сорый кунагыннан бала әнисе.

— Бик әдәпле, бик тәрбияле бала. Тик ул мине табиб дип белде бугай, мине күрү белән телен чыгарып күрсәтте,— ди кунак.

Булдыксыз

Бер егет, тегермәннән ашлык тарттырып кайткач, әнесен чакырып бик нык ачуланган:

— Капчык авызын бик начар бәйләгәнсең. Юл буе чишелеп интектерде. Атны ун тапкыр туктатып, ул капчык авызын ун мәртәбә яңадан бәйләдем,— дигән.

Күрешмә

(Мәзәк)

Бер карт, хәле авырайгач, улына әйткән:

— Васыятем шул, мин синең инсафлы, абруйлы кеше булуыңны телим. Башкалар үзеңне хөрмәт итсеннәр дисәң, башлап бирәүгә дә кул бирмә,— дигән.

Әтисе үлгәч, егет кешеләр белән күрешми башлаган, башкаларның беренче булып кул биргәннәрен көткән. Тора-бара егеткә якын танышлары да кул бирмиләр икән. Аның турында «тәрбиясез» дип сөйли башлаганнар. Егет бу хәлгә тәмам аптыраган. Әтисе васыятен үтәүнең нинди нәтиҗәгә китерүен бер абзыйга сөйләгән. Абзый елмаеп куйган да:

— Син, улым, әтиең әйткәннәрне аңламагансың. Ул бит сиңа эшкә башкалардан алдарак кил. Эшли башла. Шулай итсәң, бар да сиңа беренче булып кул сузарлар,— дигән.

Егет әтисе әйткән сүзләрнең мәгънәсен шунда гына аңлаган.

Бирем

Картка һәм аның улына бәя бирегез.

Шәүкәт Галиев

Озак яшәүнең сере

Күрше бабайга кердем,
Көйләп бер сәлам бирдем,
Ике куллап күрештем,
Хәл-әхвәлен белештем.

Соравымны тыңлагач,
Болай диде бабакай:
— Озак яшәүнең сере —
Татулыкта, балакай.

Әбиең белән бергә
Яшибез җиде дистә,
Сүзгә килгән юк һич тә.

Тиргәшкән дә юк, шөкер,
Әрләшкән дә юк, шөкер,
Ачу килгән чакларда
Эндәшкән дә юк, шөкер!

Сүз куештык өйләнгәч,
Без бик ныгытып кына:
Беребез тузынганда,
Беребез чыгып тора.

Менә әле бүген дә
Ул тузына тегендә...
Үтте ярты гомерем
Шушы капка төбендә.

Ә бит монда нинди тын,
Каймак кебек саф һава.
Ә саф һава, беләсең,
Организмга дәва!

...Бу сүзләрдән сез шуны
Төшенергә тиешле:
Озак яшәүнең сере —
Шаянлыкта, кәнишне!

1968 ел

Бирем

Бу шигырьдә дә автор яманны яхшыга әйләндергәндә, Габдулла Тукай кебек, хәйлә алымын куллана. Исбат итегез.

ЮМОР ӘСӘРЛӘРЕНДӘ АРТТЫРУ АЛЫМЫ

Юмористлар һәм сатириклар яратып куллана торган **алым — адәм ышанмаслык вакыйгаларны чын итеп язу.** Ләкин моның өчен дөньяда була алмый торган вакыйга эчендә кечкенә генә булса да дөреслек ятарга тиеш.

Арттырып сөйләүчене алдакчы диләр. Ләкин үткен фикерле әдип укучысын алдамый. Киресенчә, юри арттырганны укучым белеп торсын дип, көлке дәрәҗәсенә җиткереп арттыра.

Сатира яман күренеш белән башта килешә, ә килешүе астына нәфрәтен салып куя дигән идек. Арттыру алымы да — шулай ук **килешеп кире кагу алымының** бер төре.

Мәсәлән, ялганчы барны юк дип, ә юкны бар дип сөйли, яки чынны арттырып, ә ялганны чын итеп күрсәтә. Әйтик, сатирик ялганчының ялганын фаш итә, ди. Сатира кагыйдәсенә буйсынып, ул ялган белән килешә. Дөрес, ди һәм ялганны хуплаган булып, тагын да күпертеп, арттырып әйтә. («Бер энәгә бер сыер» мәкален исегезгә төшерегез.)

Тәмле тамаклар

(Мәзәк)

Бер агай өстәлгә эченә май салган чүлмәк куеп, чүлмәкнең өстен ябып, бик әйбәтләп бау белән бәйли икән. Улларына ипине чүлмәк тышына ышкып ашарга куша, ди. Бу гаиләдә майны көн дә шул рәвешле тәмләп ашый торган булганнар. Эшкә киткәндә, агай, чүлмәкне сандыкка салып, сандыкны йозак белән бикләп китә торган булган. Көннәрнең берендә агай ниндидер йомыш белән көндез өенә кайткан. Ишекне ачып керсә — уллары ипи телемнәрен сандык йозагына ышкып ашыйлар!

— Тәмле тамаклар, майсыз бер генә телем ипи дә ашарга теләмисез! — дип орышкан агай улларын.

Биремнәр

1. Мәзәкне ике өлешкә бүлегез. Өлешләр каршылыкта торырга тиеш.
2. Мәзәк авторлары кешенең саранлык сыйфатыннан арттыру алымы белән көләләр. Ничек көләләр?

Эт койрыгы

— Торак бүлмәгез бик кысан булса кирәк? — дип сорый Садрый Фәйзулладан.

— Каян беләсең?

— Этегез койрыгын астан өскә болгый, шуңа әйтүем,— дип җавап бирә Садрый.

Бирем

Арттыруның ни өчен көлке булуын аңлатыгыз.

> Сәнгать әсәрләрендә чиксез арттырып сурәтләү алымына **гипербола** диләр.

Өч аучы һәм бер балыкчы

(Әкият)

Өч аучы һәм бер балыкчы бергә туры килгәннәр дә күргән-белгәннәрен сөйләшәләр икән.

— Беркөнне шулай урманда эзләнеп йөргәндә, каен башында утырган көртлекне күрдем,— дип башлап киткән беренче аучы.— Ныклабрак карасам — каен төбендә бүре утыра! Нишләргә? Әгәр дә көртлеккә атсам, бүре куркып кача, бүрене атсам, көртлек очып китә. Тоттым да икесенең нәкъ уртасына аттым. Бер атуда икесен дә егып салдым.

— Андый хәлләр була ул! — дип, аны куәтләгән икенчесе.— Буразнада шулай су буенда үрдәк сагалап йөргәндә карыйм: тезелешеп ун үрдәк утыра бит, агай. Үрдәкләрнең иң кырыйдагысына төбәдем дә атып җибәрдем һәм шул секундта мылтыгымны бер яссы чамасы борып куйдым. Үрдәкләрнең унысын да чалгы белән кырган кебек кырып салдым.

Өченче аучы да сүзгә катнашкан:

— Бервакыт шулай чабып барган куянга атып җибәрдем,— дигән ул,— куян агач кырыена барды да утырды. Башын күтәргән дә миңа карап тора. Беренче атуда тимәгәндер дип, янә аттым, китми куян, колакларын гына селкетә. Бу каһәр сукканга тими икән дип атам да атам. Патроннарым беткәч, барып карасам, куян беренче атуда ук үлгән икән. Аткан саен колагы гына селкенә икән тегенең. Куянны алып кайтып тунаган вакытта эченнән биш кило ядрә чыкты.

— Һәй, бер дә искитәрлек нәрсә юк икән сездә! — дигән балыкчы һәм кызып-кызып сөйләп киткән: — Кичә булды бу хәл, гаҗәп дисәң дә гаҗәп! Кармак белән ун килолы бер чуртан эләктереп алдым.

Шунда аучылар аны бүлеп:

— Булмас, Сәмит дус, ун килолы балыкка кыл түзмәс, өзелер,— дигәннәр.

— Юк, кыл түзде, чуртан түзмәде — яртысы өзелеп калды,— дигән балыкчы.

Биремнәр

1. Аучылар сөйләгән вакыйгаларга уртак исем бирегез.
2. Өч вакыйгада өч ялган. Ялганнар бер-берсеннән кай яклары белән аерыла? Арттырылган урыннарны табыгыз.

Иҗади эш

Бер авылда ике ялганчы яшәгән. Берсе авылдашларына үзенең күргән-белгәне турында болай сөйли икән:

— Мин бит башка җирдә туып үстем. Безнең якларда таулар бик күп. Безнең авыл тавыклары, шул тауларга менеп, күктән йолдызлар чүплиләр. Шуның белән туенып торалар.

Авыл халкы моның сүзләренә ышанып бетмәгән.

— Әйдәгез әле, Гаптеригә барып сорыйк, ул да читтән килгән кеше. Таулар турында сөйләгән дөрес микән,— дигәннәр һәм Гаптеригә киткәннәр...

Бирем

Гаптери — бу авылның икенче ялганчысы. Шулай булгач, Гаптери әлеге ялганны дәвам итә. Гаптери сүзләрен уйлап табыгыз. Кайсыгыз ныграк арттыра ала?

Үзенең әйтүенчә, фәкать үз башыннан үткән вакыйгаларны гына төкми-чәчми, аз гына да арттырмыйча сөйләүче барон Мюнхгаузенның чираттагы маҗарасы белән танышыйк. Бу юлы ул үзенең руслар ягында төрекләр белән сугышуын искә төшерә.

Эрих Распе

Бaһадир

Ни генә күрмәдем дә, нинди генә куркыныч хәлләрдә калмадым мин бу сугышта.

Берзаман шулай төрекләрдән качарга туры килде. Алдымда баткаклык. Нишләргә? Бу куркыныч урынны атыма атланып сикереп чыгарга ниятләдем. Ләкин атым сикереп аргы ярга җитә алмады. Без, шап итеп, сыек ләмгә чумдык. Бата башладык. Бетте баш, котылыр чара юк, дип уйлап алдым. Атымның гәүдәсе күмелде. Минем баш та, бата-бата, сазлык эченә керде. Тышта тик чәч-паригымның толымы гына тырпаеп калды.

Нишләргә? Әгәр дә минем кулда үгез егарлык көч булмаса, без, һичшиксез, аска киткән булыр идек. Мин — искиткеч көчле кеше. Толымымны учлап алдым да бар көчемә шундый итеп күтәрдем — үзем белән бергә атымны да сөйрәп чыгардым.

Шулай, шулай, үземне дә, атымны да котылгысыз үлемнән коткардым. Ничекме? Мин аны аякларым белән, келәшчә кыскандай, кысып күтәрдем. Бу эшне теләсә кем булдыра ала, дип уйласагыз, мин эшләгәнне үзегез эшләп карагыз.

Биремнәр

1. Хикәянең төп герое Мюнхгаузен, күрәсез, мактана. Ничек мактана? Бер генә җөмлә белән әйтегез.
2. Хикәядәге ялганнар арасыннан авторның үзегезгә ошаган табышын — иң зур ялганын әйтегез.
3. Ялган эчендәге кечкенә генә дөреслеккә охшаган урыннарны табыгыз.

Барон Мюнхгаузен турында

Үзе турында Мюнхгаузен болай дип яза:

«Ялганчы кешеләрне җенем сөйми минем. Минем үз гомеремдә бер генә тапкыр да ялганлаганым юк. Мин язганнарны укыгач, үзегез дә күргәнсездер, аларда

ялганның заты да юк. Ялганчы кеше — минем җан дошманым. Мин бик бәхетле, чөнки дус-ишләрем, туган-тумачаларым мине дөньядагы иң гадел кеше дип мактаудан туктамыйлар».

Андый кеше чыннан да булган. Ул моннан ике йөз ел элек Германиядә яшәгән, тулы исеме Карл Фридрих Иероним фон Мюнхгаузен икән. Аңа күп илләрдә булырга туры килгән, күп күргән. Хәтта Россия армиясендә дә хезмәт иткән.

Бер дә харап икән. Тузга язмаган вакыйга уйлап чыгару булдымы иҗади фикерләү, диючеләр булыр. Шикләнүчеләргә хикәянең соңгы җөмләсенә охшатып җавап бирик. Ә сез шундый кеше көлдерә торган вакыйга уйлап карагыз әле?

Дональд Биссет

Артур һәм аның Гарри исемле аты турында

Кайчандыр бу дөньяда Артур исемле полисмен һәм Гарри исемле ат яшәгән.

Артур көн дә полисменнар киемен киеп, биленә резин күсәген таккан һәм, Гаррига атланып, шәһәр урамнарын әйләнә торган булган.

Гарриның яраткан шөгыле автобус тәрәзәсенә сулау булган. Автобусны куып җитә икән дә арт тәрәзәсе тирләгәнче өрә икән. Шуннан соң Артур күтәрелеп, тирләгән тәрәзәгә бармагы белән төрле-төрле чырайлар ясый икән. Гарри ул чырайларга карап рәхәтләнеп көлгән.

Бу эш белән алар көн дә шөгыльләнгәннәр: Гарри тәрәзәгә сулаган, ә Артур тирләгән тәрәзәгә кызыклы чырайлар ясаган. Шуңа күрә аларның җинаятьчеләр тотарга вакытлары бөтенләй калмаган.

Бик матур иртәләрнең берсендә Реджинальд исемле полиция инспекторы, сержантын чакырып:

— Сержант! Ни өчен Артур жуликлар тотмый? — дип сораган.

— Белмим шул, сэр,— дип җавап биргән сержант.

— Безнең өчен бик зур кимчелек бу. Бар, сәбәбен белеп кайт,— дигән инспектор Реджинальд.

— Хәзер үк барып тикшерермен, сэр! — дип җавап биргән сержант һәм урамга чыгу белән атына атланып чапкан.

Бик әйбәт булган аның аты: автобуслар белән кызыксынмаган, аларның арт тәрәзәләренә сулышын өрергә яратмаган. Сержант һәм аның акыллы аты Артур белән Гаррины шәһәр бетереп эзләгәннәр.

Эзли торгач тапканнар. Гарриның тәрәзәгә өреп, Артурның кызыклы чырайлар ясавын күреп шаккатканнар.

— Кара нинди шаяннар! Ә бит мавыктыргыч эш белән шөгыльләнәләр икән. Әллә миңа да шундый чырайлар ясап карарга мы? — дип уйлаган сержант.

Шулай дигән дә атын автобус артыннан чаптырган. Куып җиткәч, аты тәрәзәгә борынын төртеп сулаган. Ә тәрәзә тирләгәч, сержант алга таба бөгелгән һәм бармагы белән инспектор Реджинальд сурәтен ясаган.

Аның бу эшен башка бер полисмен күреп алган. Рәсем ясау эше аңа да ошаган. Аның да тәрәзәгә кеше сурәтләре ясыйсы килгән.

Бераздан шәһәрдәге барлык полиция атлары автобусларның арткы тәрәзәләренә сулышларын өргәннәр, ә полисменнар аңа кызыклы чырайлар ясый башлаганнар.

Шәһәр жуликларын эзәрлекләүчеләр дә, тотучылар да булмаган.

— Полициягә ни булган? — дип аптырашканнар жуликлар. Уйлана торгач, бу хәлнең сәбәбен белергә кирәк дигән карарга килгәннәр. Һәм полисменнарның җыйнаулашып автобуслар тәрәзәсенә кызыклы чырайлар ясавын күреп алганнар. Аларның жуликлар артыннан чабарга бер минут та вакытлары юклыгын белгәннәр.

— Бик күңелле эш тапканнар икән,— дигәннәр жуликлар һәм...

Биремнәр

1. Хикәяне тәмамлагыз. Жуликлар нишләгәннәр?
2. Артур белән Гаррига полисменнарның иң югары түрәләре ни дигән?
3. Хикәядә атның тәрәзәгә өрүе арттыру түгел. Артурның, жуликлар тотасы урынга, автобус тәрәзәләренә кеше башлары ясап йөрүе дә арттыру түгел. Болар — дөньяда була алмый торган вакыйгаларны уйлап табу дигән сүз. Әйтергә кирәк, искиткеч уңышлы табыш. Авторның алдавын күреп торабыз, ә үзебез чын күңелдән көләбез.
Ләкин хикәядә шундый ук уңышлы арттыру табышы да бар. Табыгыз.

Фатих Әмирхан

Сәмигулла абзый

Өйдәге һәммә нәрсәне идарә итү Маһитап абыстайга тапшырылган булса да, чәй-шикәрне Сәмигулла абзый һәрвакыт үзенең хосусый химаясе[1] астында тота иде.

Һәр чәй янына килеп утырышында, Сәмигулла абзыйның иң әүвәлге эше чәй савытын тотып селкетеп карау, аннан соң, аның капкачын ачып, чәйгә бер күз салу вә аннан да соң бер иснәп караудан гыйбарәт була, вә шул эшләрдән соң, Ходаның бирмеш көне, түбәндәгечә сүз була иде.

— Анасы, чәең аз калган икән инде.

— Ник аз булсын, әле яртысы да бетмәгән.

— Юк, алайга калгач, күпкә бармый инде ул... Инде кайсы чәйне башларсың икән, анасы? Беркөн алып кайткан Кузнецов чәен башларсың микән, әллә өченче көн алып кайткан Үтәмиш чәен башлап карармыз микән? Хәер, әле безнең җәй көне алган теге яшел пичәтле чәйнең дә берәр кадагы булырга тиеш: аны башлап карарга да ярый.

— Кайсы туры килсә, шунысын башларбыз инде. Аның өчен әле бу көннән үк баш вата тормыйм.

---

[1] Химаясе — игътибары.

— Юк, анасы, алай түгел ул. Теге яшел пичәтлесен башлап карыйк; аны җәй көне эчтек эчүен дә, озак торып, тәме башкарып китмәсен дим.

— Шуңар күрә мин сиңа һәрвакыт: «Чәй җыеп кайтма»,— дим шул, күп торгач, айный торгандыр ул.

— Юк, анасы, алай түгел ул. Өйдә чәйнең мул торганы яхшы, чәй бетеп китсә, уңайсыз була ул.

Бу сүзләр тәмам булгач, Сәмигулла абзый капкачы ачылмаган шикәр савытын да бер селкетеп, шалтыратып карый вә аннан соң, капкачын ачып, шикәргә карап тора да:

—Анасы, әле безнең шикәр күптер? — дип сорый иде, һәм Маһитап абыстай кирәк күп дип җавап бирсен, кирәк аз дип җавап бирсен, Сәмигулла абзый мотлак[1]:

— Алла теләсә, бер бик күпләп алып куярмын әле шул шикәрне,— дип куя иде.

Әгәр Сәмигулла абзый чәй янына чәй чәйнеккә салынмас борын чыкса, Маһитап абыстай башына бер мәшәкать арта иде.

— Кара әле, анасы, чәйне бик күп үк салмасаң да ярар: мин күп эчмим, хәер, белмим тагы, син үзең күбрәк эчмәкче булсаң, ни әйтим. Алай да бик аз да салма, безнең балалар чәйне эчәләр бит.

Бу сүзләрне әйткәч, Сәмигулла абзый Маһитап абыстайның чәй салганын бик дикъкатьләп[2] карап тора да чәйле балкашыгы чәйнекнең авызына килеп җитәр-җитмәс:

— Юк, анасы, тагы бераз салмасаң, бу азрак булыр әле,— ди вә, икенче балкашыкны инде бик дикъкатьләп карап: — Бу — күп, бу — күп, карчык! Без үземез әллә нихәтле эчмибез бит,— ди һәм Маһитап абыстайның алган чәенең яртысын савытка кайтарганын күргәч: — Юк, карчык, син бигрәк саранланып киттең

---

[1] Мотлак — һичшиксез.

[2] Дикъкатләп — игътибар белән.

тагы; монысы азрак булды. Балкашыкның очына гына эләктереп, тагы бераз өстәп җибәрми ярамас, анасы,— ди торган иде...

Сәмигулла абзыйның шушы чәй-шикәр мәсьәләсендәге артык катышучанлыгы кайсы вакытта Мәһитап абыстайга бик зур уңайсызлыклар да ясап куя иде. Бу уңайсызлыкларның берсе моннан ике ел элек булды: Сәмигулла абзый белән Мәһитап абыстай кызларын кияүгә бирделәр. Туйлар булды, кияүләр керде, фәләннәр булды. Көннәрнең берсендә кияүнең ата-аналары үзара гына бер мәҗлескә чакырылдылар. Менә бервакыт килен-кыз чәй салырга тотынды. Сәмигулла абзый, гадәтенчә, моны бик эшлекле борчылу белән карап тикшереп тора иде. Килен-кыз бер балкашык чәй салды, ике балкашык чәй салды, өченче балкашыкны тутырырга чәй савытына кашыкны тыкты, Сәмигулла абзый чыдый алмады:

— Чү, кызым, җитте. Ике балкашыгы салдың бит инде! — диде һәм, гадәтенчә: — Мин күп эчмим, анаң да әллә ни күп эчми. Хәер, белмим тагы, ни әйтим, кунаклар күп эчә торган булсалар гына,— дип тә өстәп җибәрде.

Кода белән кодагый бик тизлек белән:

— Юк, юк, җитәр, җитәр, безнең эчәсемез килми,— диештеләр һәм, уңайсызланып, бер-берсенә карашып алдылар.

Кирәк килен-кыз вә кирәк Мәһитап абыстай кызарындылар, оятларыннан нишләргә дә белмәделәр. Кунаклар исә, әүвәлге чынаякны эчкәч тә, чынаякларын каплап куйдылар вә һичбер төрле кыстау да инде аларны икенче чынаякны эчертә алмады.

Кунаклар киткәч, кирәк Мәһитап абыстай вә кирәк кызы Сәмигулла абзыйны бик орыштылар:

— Мондый мәҗлесләр гомер эчендә бер генә мәртәбә киләләр, әүвәл мәртәбә килгән кодаларыңнан чәй дә кызганып утырган шикелле сүз сөйлә, имеш. Бигрәк тә оятка калдык, фәлән-төгән...— диделәр.

Берәр атна үтеп, вакыйганың хатирәсе онытылу белән, Сәмигулла абзый яңадан чәй-шикәр мәсьәләсе белән шөгыльләнә башлады.

Әле менә быел да, күптән түгел генә Сәмигулла абзыйның бу табигатеннән тагы бер уңайсызлык туып алды: Сәмигулла абзый улы белән бергә Мәкәрҗәгә барырга җыена иде...

Карчыгы аңа саквояжын табып бирде.

— Карчык, мин нинди чәй алырмын икән юлга? — дип, Сәмигулла абзый, әүвәл кадаклы чәйләр янына барып, аларны берәм-берәм алып караса да, ахырдан, аларның берсенә дә күңел утырта алмыйча, өстәл өстендәге чәй савыты янына килеп, аны селкетеп карады, капкачын ачып күз салды, иснәп бакты һәм:
— Карчык, монда сезнең чәй дә аз калган икән. Кая әле, китер әле әнә теге өстән өченче тора торган «Кәрван» чәен; шуның сыйган кадәрлесен монда салып, калганын үзебезгә юлда эчәргә алырмын,— диде.

Ләкин Маһитап абыстай «Кәрван» чәен алып биргәч кенә, Сәмигулла абзыйның планы тагы үзгәреп китте:

— Юк, алай түгел, анасы... Бу «Кәрван» чәе торып торсын әле; бу Мәкәрҗәдән кайткач эчәргә яхшы булыр. Син миңа әнә теге астан икенче, Үтәмиш чәен алып бир әле. Юл өчен ул яхшы булыр,— дип, Сәмигулла абзый, өелеп куелган кадаклы чәйләрне таратып, Үтәмиш чәен алдыртты. Ләкин кулга тотып һәм төргән кәгазе аркылы иснәп карагач, Сәмигулла абзыйга юл өчен бу чәй дә муафыйкъ[1] булмас шикеллерәк тоелып китте:

— Юк, карчык, әле моңар караганда әнә теге иң астагы алтын пичәтле чәй юл өчен яхшырак булыр, ахры,— дип, ул тагы бертөрле чәй алдырып карамакчы булса да, бу юлда инде Маһитап абыстай аңар ирек бирмәде:

---

[1] Муафыйкъ — кулай, яхшырак.

— Йә, ярар инде, карт, шул кулындагыны гына ач та шуның белән булсын,— диде. Сәмигулла абзый:

— Юк, анасы, алай түгел ул, чәй белән чәйнең аермасы бар аның. Бәгъзе[1] чәй прахутта эчәр өчен чыгышсыз була ул...— дисә дә, артык үзсүзләнмәде, кулындагы чәйнең кәгазен ачарга тотынды.

Кадаклы чәй кәгазен ачу Сәмигулла абзыйның дөньяда иң яратып эшли торган эшләренең берсе иде... Бу юлы да ул чәйне гадәтенчә, тантаналы ачты, иснәп карады, як-ягыннан каккалап, бераз әллә нишләтте вә аннан соң, Мәһитап абыстайны чакырып китереп, аңар чәйне савытка бушатырга ярдәм итте... Ләкин сәфәр хәзерлеге моның белән тәмам түгел иде әле.

— Анасы, шикәрне нишләрмен икән мин? — диде Сәмигулла абзый.

— Алырсың! — диде Мәһитап абыстай.

— Алуын алам инде. Әле тик кайсы шикәрдән алырмын икән дигән сүзем: башлыдан ватып бирерсең микән, әллә өйгә дип ватып куйганнан гына алырмын микән? Әллә теге пилүни шикәрдән бирәсеңме?

— Кайсысыннан бирим соң?

— Шуңа аптырап торам әле үзем дә. Булмаса, бар әле, анасы, һәммәсен дә китер әле; барысын да карап уйлашып багыйк.

Шикәрләр китерелгәч, Сәмигулла абзый беразы ватылып алынган башлы шикәрне күтәреп карады, калын кәгазьгә төрелгән ватылган шикәрне, кәгазьнең әле бер ягын, әле икенче ягын күтәреп, шалтыратып бакты. Пиленый[2] шикәр тартмасын да селкетеп шалтыратты вә, аннан ике шакмакны алып, бармаклары белән кысып-кысып карап куйды.

— Пилүни шикәр ләззәтсез була, анасы, юлга аны алмам; ватканны бирерсең, ахры, син. Хәер, белмим тагы, ватканы өйгә аз кала дип уйласаң, башлыдан

---

[1] Бәгъзе — кайбер.

[2] Пиленый шикәр — шакмаклы шикәр.

ватып бирсәң дә ярар. Алай дияр идең, аны кайчан ватып тормак кирәк. Шулай, анасы, хәзергә әле ватканны алып торыйм...

Сәмигулла абзый, зур бер кәгазьне җәеп, ватылган шикәрдән аңар алып сала башлады: бер уч салды, ике уч салды, дүрт уч салды да бераз уйланып, каранып торды:

— Анасы, болай күбрәк булып китте, ахрысы?

— Күбрәк булса, беразын кире салырсың.

— Шулай итми ярамый, карчык.

Сәмигулла абзый бер уч кайтарып салды, ике уч кайтарып салды да бераз уйланып, каранып торды:

— Юк, анасы, болай бигрәк азаеп китте.

— Беразын яңадан алып сал соң.

— Шулай итми ярамый, карчык.

Сәмигулла абзый бер учны яңадан кайтарып салмакчы булды да, ләкин, бөтенләй салып бетермичә, өч шакмакны кулында тотып вә бераз уйланып торганнан соң, аны өйгә каласы шикәрләр арасына ыргытты.

Хәзер эш тәмам иде инде. Сәмигулла абзый... шикәрне төрде дә саквояжга салды вә үзе бер арыган сымак сулап куйды һәм, сәгатенә карап:

— Һа, сәгать ун тулган. Юлга хәзерләнә торгач, базарга соңгарак та калганмын,— дип, ашыгып, базарга хәзерләнә башлады.

Базардан кайткач, Сәмигулла абзый, саквояжны ачып, чәй-шикәрне карады һәм Мәһитап абыстайга:

— Кара әле, карчык, бу чәй күбрәк булыр, ахры. Миңа бер кәгазь бирсәң, мин моның беразын бушатып, монда калдырыйм... — диде һәм әйткәнен җиренә җиткерде вә аннан соң, шикәр кәгазен ачып карап, андагы шикәрне азсынды булырга кирәк, тавышсызтынсыз гына, өйгә калдырган шикәрләр төргәгеннән биш-алты шакмак алып килеп өстәде.

Сәфәр китәчәк көнне иртә белән Сәмигулла абзый, карчыгыннан калай чәй тартмасы эзләтеп таптырып, юл өчен хәзерләнгән чәйне шуңар бушатты. Шикәр

өчен катыргы конфет тартмасы сорап алды вә аннан соң улына:

— Мин чәй-шикәрне хәзерләдем инде, Хәкимулла, башка кирәк-яракны син кара. Әйберләрне җыештырып, хәзерләп куй, базардан кайту белән прахутка китәрбез,— диде.

Сәмигулла абзый чыгып киткәч, әйберләр җыештырылды, төеннәр төйнәлде, һәммә нәрсә тәмам хәзер ителде. Ләкин Сәмигулла абзый базардан яңа план белән кайткан иде. Бәйләп куелган төеннәрне һәм саквояжны күтәреп карады да ул:

— Юк, анасы, без чәйне-шикәрне юкка саквояжга салганбыз, аларны менә шушы мендәрләр төененә бәйләргә кирәк,— диде. Саквояжны ачтырды вә пөхтәләп, нык итеп, каеш белән бәйләнгән төенне чиштерде һәм, үзе хәзерләп куйган чәй-шикәрне тоткан килеш, шактый уйлап торганнан соң:

— Кара әле, карчык, мин юлга бер дә башланмаган кадаклы чәй алыйм, ахры, китер әле әнә шул алтын пичәтле чәйне. Прахут өчен шундый чәй чыгышлы була. Калганы үзегезгә. Мәкәрҗәдә эчеп тотарга булыр,— диде. Ләкин моның белән генә дә эш тәмам түгел иде әле: — Карчык, шикәрне дә, ахры, алыштырмый ярамас. Монысын бушатып, пилүнине тутырырга кирәк булыр. Ник дисәң, чөнки прахутта шикәрне салып эчеләә. Пилүнинең ике шакмагы бер стаканга таман гына була. Әмма ваткан шикәр алай түгел...

Базардан ашыгып кайткан Хәкимулла, үзе төенләп чыккан төеннәрнең таратылып ташланганын вә картның һаман әле чәй-шикәр белән булышканын күргәч, аптырап китте:

— Кара әле, эти, прахут китәргә бары ярты сәгать вакыт калган, син монда чәй-шикәрне авыш-түеш китереп азапланасың.

— Юк, улым, алай түгел ул... һәммә нәрсәнең җае бар аның: чыгышсыз чәй белән прахутта нишләмәкче буласың... Алай түгел ул. Алла теләсә, бу

прахутта ашыйсы ризыгыбыз булса өлгерербез. Бер дә курыкма.

Хәкимулланың ашыктыруына да карамыйча, төеннәрне яңадан рәтләп җиткерүгә чирек сәгать вакыт киткән иде. Мөсафирлар ашык-пошык атка чыгып утырыштылар. Ат кузгалып киткәч, Сәмигулла абзый, артына борылып:

— Аллага тапшырдык, карчык! Теге калай савыттагы чәйне үзең карап тотарсың инде! — дип, ахыргы саубуллашу сүзен әйтте.

Ләкин сәгать ярым вакыт уздымы, юкмы, безнең мөсафирларыбыз, төянеп, кире кайтып керделәр. Хәкимулла кәефсез вә бераз ачулырак, әмма Сәмигулла абзый бераз төчерәк вә бераз гафу үтенгән кыяфәттә иде:

— Анасы, бу прахут белән китү насыйп түгел икән безгә. Барып җиткәндә, яңа гына пристаньнан кузгалып торадыр иде,— дип, ул карчыгына төче бер караш белән карады.

— Юк нәрсә белән җенләнгәч, шулай була ул, әти,— диде аңар каршы Хәкимулла. Сәмигулла абзый:

— Юк, алай түгел ул, Хәкимулла,— дип, бу турыда үзе гаепле түгел, бары тәкъдир гаепле икәнлеккә дәлил китермәкче иде дә, ләкин андый бер дәлил табылмады вә шунлыктан ул сүз булсын дип кенә:

— Бүген актыккы прахут иде шул ул... Актыккы прахутка төшкәндә һәрвакыт шулай берәр эш булмый калмый. Менә иртәгә Ходай теләсә, иртәнге прахут белән китәрбез,— диде.

Кичке чәй янында утырганда, Сәмигулла абзыйның башына өр-яңа вә гаять муафыйкълы бер фикер төшсә дә, ул Хәкимулла алдында аны карчыгына әйтергә батырчылык итмәде: «Юк, алай түгел ул. Безнең Хәкимулла эшнең җаен белми. Дөнья күрмәгән ул»,— дип уйлады...

Карт белән карчык бүген йокларга гадәттәгедән дә иртәрәк яттылар. Сәмигулла абзый үзе йоклап китәр алдыннан, куерып кына ята торган карчыгын уятып:

— Кара әле, анасы, мин Мәкәрҗә бүләгенә өләшергә дигән яшел чәйне ничә кадак алсам ярар икән? — дип сорады һәм, карчыгының йокысын бүлеп җавап бирергә теләмәгәнен күргәч:

— Ярый, йокла алай булса, анасы. Иртәгә уйлашырбыз әле,— диде дә, бераз торгач, инде тәмам йоклап киткән карчыгына:

— Без өйдә юкта үзегез теге яшел чәйне башлап эчеп карасагыз да ярар: мин, Алла теләсә, өйдә эчеп тотар өчен дә, яшел чәйне күпләп алып кайтырмын,— диде. Аның үзенең дә йокысы тәмам җиткән иде инде...

Сәмигулла абзый бүген йокысында да гаять ләззәтле төш күрде, гүяки ул зур бер бакчада йөри, имеш.



Бу бакчада алмагачы шикелле агачларда, алмалар урынына, кәгазьгә төрелгән такта чәйләр үсеп утыралар, имеш. Гүяки Сәмигулла абзый ул чәйләрне иснәп карый да, «бик арамат-лы, хуш исле» дип, мактап йөри, имеш. Ул арада каты җил исеп китеп, чәйләр, алмагачларыннан өзелеп, туп-туры җиргә төшә башладылар, имеш; гүяки Сәмигулла абзый шулардан берсен Маһитап абыстайга иснәтеп карар өчен алып кайтырга карар бирде, имеш; гүяки бу агачлар арасында, үләннәр урынына, кәгазьгә төрелгән хәлдә, башлы шикәрләр үсеп утыралар, имеш; гүяки бу бакчаның бакчачысы Сәмигулла абзый үзе, имеш... һәм рәхәт, һәм ләззәтле иде бу төш!

1916 ел

Сәмигулла абзый хикәясендә арттыру алымы

Бу хикәядә арттыру бармы соң? Берәү дә алдамый, берәүнең дә тавыклары күктән йолдыз чүпләми, ә этәчләре айны, җиргә төшереп, туп итеп уйнамый. Сәмигулла абзыйның чәй-шикәр турында сөйләнеп йөрүе гадәти бер сөйләнү генә бит!

Ләкин ни өчен аның бу сөйләнүен берәү дә яратмый? Балалары да, хатыны да Сәмигулла абзыйның сүзләрен йөзләрен чытып кабул итәләр.

> Берәүнең хәтта эчпошыргыч кына булса да гамәле бер-ике мәртәбә кабатланса — мәгънәсезлеккә әйләнә. Әгәр әдип аны күп мәртәбә кабатласа, арттыру алымы белән көлке тудырган була.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хикәядәге кабатланган вакыйгаларны табыгыз.
2. Хикәяне өлешләргә ничек бүләбез? Юмор әсәрләрендәге үзенчәлекне искә төшерегез.
3. Сәмигулла абзыйның холкын әйтегез.
4. Сәмигулла абзый бәхетлеме? Аның мавыгуы зарарлымы? Хикәя дәреслектә кыскартып бирелде. Шуңа күрә Сәмигулла абзыйның чәй-шикәр турындагы сүзләре аз сыман күренә. Хикәяне тулы килеш укып чыгыгыз.

КАРШЫ ЯКЛАРНЫҢ УРЫННАРЫН АЛЫШТЫРУ АЛЫМЫ

Диюләрне җиңгән

(Әкият)

Бер авылның бакча артында гына урманы бар, аударсаң, бакча коймалары өстенә төшәр, шундый якын. Тик бу урманнан бер агач та ала алмыйлар, урман каравылчысы җибәрми.

Көннәрдән бер көн куркак кына бер кеше урманга чыгып китә. Колач җитмәстәй ике чыршыны кисә дә аудара бу. Менә берзаман урман каравылчысы килеп чыга:

— Нишлисең син? — ди.

— Мендә тәрәзә астында ике бүрәнә черегән, шуңа ике бүрәнә алып кайтам әле,— ди.

— Синең атың кайда? — ди каравылчы.

— Ат нигә миңа? Икесен ике култык астыма кыстырам да китәм,— ди бу.

— Әйдә, бүрәнәләрең качмас,— ди каравылчы,— безгә чәйгә кер.

Ярар, керә бу. Урман каравылчысы дию затыннан икән. Ярлыны төнлә берәр төрле җай белән дөньядан юк итәргә уйлыйлар.

Бик сыйладылар моны. Кичкырын түбән өйгә урын җәеп бирделәр. Аларның пышын-пышын нинди сүз сөйләшкәннәрен бу азрак аңышты. Толып астына чырагачлар салды да бу, үзе мич артына кереп утырды. Берзаман югары өйдән җәйгән урын өстенә дөбердәп тегермән ташы килеп төште. Шуннан соң бу ятты да йоклады. Иртә белән хуҗалар коймак пешергәннәр дә моны чәйгә уяталар. Килеп утыра бу бик әйбәт кенә.

— Төшеңдә ниләр күрдең? — диләр.

— Төштә, ди, әллә ни күрмәдем. Киленегезнең орчык башы өстемә төшкән иде дә, мин аны аяк очынарак куеп йокладым,— ди. «Уф алла»,— диләр болар, аталы-балалы шаккатышалар.

— Тагын бер кич кун инде син,— диләр. Бу кунарга була.

Тагын кич булды шулай. Егерме чиләк су кайнаталар болар, төнлә моның өстенә су коймакчы булалар. Ярар. Бервакытны кайнар суны коялар, бу тагы мич артына кереп утыра.

Иртәгесен тагы ашау-эчү хәзерлиләр.

— Соң, ничек, кунак, тыныч кына йокладыңмы? — диләр.

— Бик тыныч йокладым,— ди, бу әйтә,— тик бераз җылы яңгыр гына сибәләп үтте,— ди.

Тегеләрнең моңа исләре китә. Китәр алдыннан бу кеше әйтә:

— Бик әйбәт дус булдык без,— ди.— Сез мине илтеп тә куегыз инде,— ди.— Моннан соң бер-беребезне өстебезгә атландырып йөртешле булсын,— ди. Тегеләр әйтәләр:

— Бик шәп, бик яхшы булыр,— диләр. Урман каравылчысының малае моны атландырып илтергә чыга. Юлда ауган бер чыршы күрәләр.

— Иптәш, ди, син бу чыршыны да ал әле, ди, сиңа казан ассак, кирәк булыр,— ди.

Теге чыршыны да өстерәп кайта.

Кайта-кайта, бер юл чатындагы тегермән ташы күрәләр. Бу әйтә:

— Әни белән хатын оршышканнар, ахры,— ди,— әни ачу белән хатынның орчык башын тәгәрәтеп җибәргән, алып кайтыйк инде аны,— ди.

Дию малае моны да күтәрде.

Кайтып керделәр. Дию улын түр башына, тәрәзә янына утыртты. Ул арада чәй дә өлгерде. Чәй эчеп утырганда, ире әйтте хатынына:

— Аш пешер әле, кунакны сыйларга кирәк бит,— ди. Хатыны әйтә:

— Әй, син тагын үз чамаңны үзең белмисең, бернәрсә дә юк бит,— ди.

— Ник булмасын,— ди, ире әйтә,— амбарда бөтен дию утыра, шуны ботарлап бирермен,— ди.

Бу дию тәрәзәне ватып чыга да йөгерә.

Биремнәр

1. Әкиятне мөмкин кадәр тулы килеш сөйләгез.
2. Әкият эчтәлеген вакыйгаларга бүлеп сөйләгез.
3. Вакыйгалар бер-берсенә охшамаган кебек. Ә сез охшаганнарын табыгыз. Охшаган вакыйгаларга уртак исем бирегез.
4. Мөмкин кадәр кыскартып сөйләгез.

Бергәләп уйлыйк

Әсәр төзелешен табу өчен, аны башта үз сүзең белән кыскартып сөйләргә кирәклеген беләбез. Сөйләп карыйк.

1 нче вариант

Әкиятнең баш өлешендә көчсез, куркак кеше белән бик көчле дию очрашалар. Дию көчсез кешене җиңәргә тиеш иде. Ләкин әкият әнә ничек тәмамлана: көчсез, куркак кеше көчле, батыр булып үзгәрә, ә көчле дию көчсез, куркакка әйләнә.

2 нче вариант

Көчсез кеше көчле диюне җиңә. Көчле дию җиңелә.

Нәтиҗә ясыйк: каршы яклар урыннарын алмаштылар.

Бу әкияттә каршы якларның урыннарын нәрсә алыштырды соң? Хәйлә алыштырды. Башкача әйтсәк, каршы якларның бәйләнеше хәйлә була.

Әкият бик кызыклы өлешләргә бүленә икән: беренче өлеш — көчсезнең көчлене җиңү вакыйгасы, икенче өлеш — көчленең җиңелү вакыйгасы. Ә алар арасындагы бәйләнеш — хәйлә.

Истә калдырыйк: әкият яза башласаң, көчле геройны үзгәртә-үзгәртә көчсез итәргә кирәк. Әкиятләрдә көчсез — көчле, персонаж хәерче булса — бай, бай булса — хәерче, ямьсез булса, матур була.

Эрих Распе

Күздән чәчрәгән ут

Петербургта үткән күңелле көннәремне әле дә искә алам.

Монда көн дә диярлек адәм ышанмаслык вакыйгаларга тап булдым. Шуларның берсе миңа аеруча кадерле.

Хикмәт шунда: минем йокы бүлмәсе тәрәзәсеннән зур буа күренә. Андагы кош-кортның чуты юк.

Беркөнне буага киек үрдәкләр төшкәнен күреп алдым.

Мылтыгымны эләктердем дә күз ачып йомганчы өйдән чыгып чаптым.

Ләкин артык ашыгудан башымны ишеккә шундый итеп бәрдем: күземнән утлар чәчрәде. Ләкин сызланып тормадым, буага йөгердем. Менә килеп тә җиттем. Мылтыгымны иң симез үрдәккә төзәдем. Атам дигәндә генә кылт итеп исемә төште: мылтыкның чакматашы бүлмәмдә калды бит! Ә чакматашсыз мылтык атмый.

Нишләргә? Бүлмәгә кайтып килергәме? Ул арада үрдәкләр очып китәчәкләр.

Мылтыгымны төшердем дә язмышымны каргыйкаргый утырам... Кинәт башыма искиткеч матур бер фикер килде.

Йодрыгым белән бар көчемә уң күземә тондырдым. Күземнән утлар чәчрәде. Мылтыгымдагы дары шунда ук гөлт итеп кабынды.

Шулай! Дары гөлт итеп кабынды, мылтык атты, һәм мин бер атуда менә дигән ун үрдәк атып төшердем.

Үз тәҗрибәмнән чыгып киңәш бирәм, ут кабызырга кирәк чакта, бер дә аптырап калмагыз. Утны күзегездән алыгыз дип киңәш итә Мюнхгаузен.

Биремнәр

1. Хикәянең нинди алым белән язылуын исбат итегез.
2. Зур ялган эчендәге дөреслеккә охшаган урынны табыгыз.

Дональд Биссет

Чикерткә һәм Әкәм-төкәм

(Әкият)

Дэнди исемле чикерткә яшәгән. Ай-һай кыланчык булган ул чикерткә. Кечкенә чакта ук уйнаганда, ул башка чикерткәләрдән биегрәк сикерә торган булган.

— Син, Дэнди, биеккә генә сикерәсең. Кыска арага сикерергә дә өйрән,— дип үгетли торган булган аны укытучысы.

— Мин башкалар кебек түгел. Мин биеккә, еракка сикерергә генә яратам,— дип җавап бирә икән аңа Дэнди.

Үзсүзле Дэнди тәки кыска арага сикерергә өйрәнмәгән.

Бермәлне ул, сикерә-сикерә уйнарга дип, урамга чыккан. Бер-ике сикерү белән каядыр баручы Әкәм-төкәмне куып җиткән.

— Көне буе өеңне аркаңа салып шуышасың да шуышасың, шундый әкрен тормыш туйдырмыйммы сине? — дип сораган.

— Нигә алай дисең? Миңа шуышу бик ошый. Миңа, гомумән, Әкәм-төкәм булу бик ошый. Яңгыр яуса куанып туя алмыйм: коры, җылы өемә керәм дә ятам.

Рәхәтнең рәхәте бит! Аннан соң мин бервакытта да өйгә кайтырга соңга калмыйм. Өем һәрвакыт үзем белән. Һи! Әкәм-төкәм булу бик күңелле ул,— дип җавап биргән Әкәм-төкәм.

— Җаны теләгән — елан ите ашаган, әйдә шуыша бир. Сау бул! — дигән чикерткә һәм үзеннән-үзе бик канәгать булып киткән.

Ул, чыннан да, менә дигән сикерүче булган. Дөрес, башка чикерткәләр дә сикерергә яратканнар. Ләкин Дэнди бер сикерүдә утыз сантимер ара үткән. Үзенең озынлыгы ул арадан ун тапкыр кечерәк булуны искә алсак, ай-һай, озын ара ул утыз сантиметр. Ләкин Дэндинең бер кимчелеге булган: ул кыска арага сикерә алмаган. Ун сантиметрда да, унбиштә дә туктап кала алмаган. Яшьли өйрәнми калган. Һоп! Сикерә — утыз сантимер җир артта кала. Тагын сикерә, тагын шул ук ара!

Әкәм-төкәм белән сөйләшкән арада, төшке аш вакыты да килеп җиткән. Дэнди өенә кайтып киткән. Сикерә-сикерә, ишек төбенә үк диярлек төшкән... Күп булса, ун сантимер ара гына калгандыр... Ләкин күпме тырышса да, ишеген ачып керә алмаган. Сикергән саен өен узып китә икән. Тагын сикергән, тагын узган... Шулай булмый ни! Кыска арага сикерергә өйрәнмәгән бит ул.

Мескен Дэндинең бөтен сабырлыгы беткән. Ачуыннан канатларын өзеп ташларлык хәлгә килгән. Ләкин бәхете бар икән: каршына кем килеп чыккан дип уйлыйсыз?..

Биремнәр

1. Әкиятнең беренче өлешен укыдыгыз. Андагы вакыйганы кыскартып, үз сүзләрегез белән языгыз.
2. Әкиятне дәвам итегез (икенче өлешен языгыз).

Гамил Афзал

Мыек борам

Тәрәзәдән карап торам,
Гайрәт белән мыек борам.
Төрле хәвеф-хәтәр белән
Тулып яши безнең урам.
Мөмкин түгел күрми узу,
Адым саен тәртип бозу.
Иртә-кичен һәр урамда
Эчеп йөргән хулиганга
Бирер идем каты җәза,
Килеп чыгар бәла-каза...
Тешне кысып карап торам,
Гайрәт белән мыек борам.
Үгез күзле аю егет,
Трамвайда бушка килеп,
Мәсхәрәли кондукторны,
Ул ишәктә намус зурмы?!
Ничек түзим тыныч калып,
Якасыннан борып алып
Бирер идем каты җәза,
Килеп чыгар бәла-каза...
Күрмәмешкә салынып торам,
Гайрәт белән мыек борам...
Түзеп торып булмый алай,
Өй түрендә малай-шалай,
Иртә димә, кичен димә
Чыр-чу килеп футбол тибә.
Ачу эчтә тынмый һич тә.
Күрше малай бөтен көчкә
Капкага дип бер тибә дә
Чалтырата тәрәзәмә...
Бирер идем каты җәза,
Килеп чыгар бәла-каза...
Форточкадан карап торам,
Гайрәт белән мыек борам,
Минем көннәр шулай үтә,
Минем мыек һаман үсә...

Бирем

Беренче өлеш тәмамланды. Икенче өлеш нинди булырга тиеш? Уйлап табыгыз.

Каюм Насыйри турында

Хәзер күләмле әсәр укырга күчәбез. Аның авторы — моннан ике гасыр элек яшәгән татарның күренекле улы Каюм Насыйри. Ул хәзерге Яшел Үзән районына кергән Олы Шырдан авылында туган. Мәдрәсәдә укыган. Казан дәүләт университетында төрле фәннәргә өйрәнгән. Ләкин галим булырлык белемен, башлыча, үзлегеннән укып алган. Чит ил галимнәренең фәнни китапларын укыр өчен, тиз арада төрек, гарәп, фарсы, рус телләрен өйрәнгән. Күп тә үтми, танылган галим булып җитлеккән. Күп еллар укытучы булып эшләгән. Ничек өлгергәндер, шул ук вакытта 37 китапның авторы булган. Алар арасында «Әбүгалисина» кебек дәреслекләргә кергән әдәби әсәрләр дә бар. Укыту һәм иҗат эше белән берлектә балта остасы, слесарь һөнәрләрен үзләштергән, көзгеләр ясаган, музыка кораллары эшләгән, аш-су пешерү остасы булган.

Каюм Насыйри

Әбүгалисина

Гыйлем эстәп, ерак юлга

Борын-борын заманда Бохара шәһәре янындагы Шәҗегъ дигән авылда бер ир белән хатын яшиләр иде. Көннәрдән бер көнне боларның игезәк ир балалары булды. Ата белән ана бик шатландылар. Балаларның берсенә Әбүгалисина, икенчесенә Әбелхарис дип исем бирделәр.

Айлар, еллар үтеп киттеләр, балалар дүрт яшькә җиттеләр. Аларны мәктәпкә укырга бирделәр.

Әбүгалисина үзенең үткенлеге, зирәклеге белән башка балалардан аерылып тора иде. Ул, укытучы сөйләгәннәр белән генә канәгатьләнеп калмыйча, яшьтән үк китаплар укырга бирелде. Халык сүзе белән әйткәндә, ул кылны кырыкка яручы бер бала иде.

Ул вакытларда мәктәпләрдә, асларына киез салып, идәнгә тезләнеп укыйлар — парталар булмый. Әбугалисинаның иптәшләре аның киезе астына бер бит кәгазь кисәге салып куялар, ә үзләре, Әбугалисина нишләр икән дип, кызыксынып карап торалар.

Әбугалисина урынына утыра, аннары бер югары, бер түбән карап тора. Аңа сорау бирәләр:

— Нишләп алай карангалыйсың? — диләр.

Әбугалисина:

— Белмим, мәктәпнең түшәме төшкәнме, әллә идәне күтәрелгәнме? Ни булса да бар, элеккечә түгел,— ди.

Унике яшендә Әбугалисина бик күпне белүче гыйлем иясе булып җитешә. Төрле фәннәрдән үзе дә балаларга сабак укыта башлый.

Тагын берничә ел үтеп китә. Әбугалисина зур галим булып җитә. Бохара тирәсендә аңа тиң, аның белән сүз көрәштерерлек кеше калмый. Ләкин ул үзе моңа гына риза булмый, тагын да тирәнрәк белем алырга тели. Туганы Әбелхарис белән бергәләп, белемнәрен арттыру нияте белән, алар туган илләреннән тагын да еракракрак китәргә уйлыйлар.

Ата белән ана, балаларыннан аерылу бик кыен булса да, аларның яхшы теләкләренә каршы килмиләр. Ике туган юлга чыгалар.

Көн бардылар, төн бардылар, күп юллар үттеләр, ерак җирләргә җиттеләр. Йөри торгач, бер шәһәргә барып керделәр. Аны карап йөргәндә, зур гына базарга килеп чыктылар. Ни күрсеннәр: бер җирдә бик күп халык җыелган, уртада бер кеше нидер сөйли:

— И җәмәгать! Тыңлагыз, ишетми калмагыз! Иртәгә мәгарә ишеге ачыла. Кереп карарга, белем алырга теләсәгез, хәзер торыгыз... Ләкин шуны аңлагыз: мәгарәдән китап алып чыгарга яки андагы белемнәрне кәгазьгә күчереп алырга рөхсәт ителми...

Әбугалисина да, Әбелхарис та бу хәбәр белән бик кызыксындылар. Шундагы берәүгә сорау бирделәр:

— Ул нинди мәгарә? Аның ачылуы нидән гыйбарәт?

Кеше җавап бирде:

— Борын заманда Фисагурис дигән атаклы бер галим булган. Ул үзенең гыйлеме белән бөтен дөньяда дан тоткан. Шул галим үлгәч, китаплары таралмасын дип, барлык китапларын җыеп, бер мәгарәгә урнаштырганнар. Ул мәгарәнең ишек төбенә сакчылар куйганнар. Менә шул мәгарә ел саен бер вакытта өч сәгатькә генә ачыла.

Әбүгалисина, бу сүзләрне ишетеп, уйга калды. Әбелхариска:

— Эзләгәнебезне таптык. Ләкин өч сәгать эчендә генә безгә әллә нәрсә алып булмас, ныклап әзерләнергә, кирәк-яракларыбызны әзерләп бетергәч, киләсе елда кереп, ел буенча мәгарәдә калырга кирәк булыр,— диде.

Әбүгалисина белән Әбелхарис таулар арасына чыгып киттеләр. Алар бик аз ашыйлар һәм бик аз эчәләр, шулай итеп, үзләрен аз ашап торырга күнектерделәр.

Алар җәя белән уклар ясадылар, тау араларында йөреп, кыр кәҗәсе ауларга керештеләр: кыр кәҗәсен аталар да, эчен ачып, йөрәген алалар, йөрәкләрне киптереп төяләр дә он ясыйлар. Зәйтүн җимеше җыйдылар, аннан май чыгардылар. Онны май белән катнаштырып, чикләвек зурлыгындагы бавырсаклар ясадылар, аларны кояшта киптерделәр.

Мәгарәдә яндыру өчен, бер елга җитәрлек май һәм башка кирәк-яракларны да хәзерләделәр.

Мәгарәнең ишеге ачылыр көн җитте. Әбүгалисина белән Әбелхарис, ишек ачылу белән эчкә кереп, бер почмакка яшеренделәр. Өч сәгать вакыт бик тиз үтеп китте. Мәгарәгә кергән кешеләр ашыга-ашыга чыгып беттеләр. Шап итеп ишек ябылды, бикләнде. Егетләр чакма чагып ут кабыздылар, аннары мәгарә эчен тамаша кылырга керештеләр. Бу мәгарә зур бер куыш икән. Стена буйларында зур-зур шкафлар. Алар барысы да китаплар белән тулган. Егетләр укырга утырдылар.

Ләкин бер-берсенең нәрсә укуы һәм нәрсә белүе турында сорашмаска сүз куештылар. Утны бервакытта да сүндермәделәр. Чиратлашып йокладылар.

Исәп буенча инде бер ел вакыт үтеп бара. Шушы вакыт эчендә Әбүгалисина белән Әбелхарис, күп тырышып, әллә никадәрле белем алдылар.

Менә шалтырап ишек ачылды. Тыштан төртешә-төртешә халык агылды. Шул ыгы-зыгы арасында Әбүгалисина белән Әбелхарис мәгарәдән чыгып киттеләр. Аларны беркем дә күрмәде.

Әбүгалисина белән Әбелхарис, ел буе мәгарәдә ятып, кеше кыяфәтләрен югалтканнар, чәчләре, тырнаклары җитеп, коточкыч бер төскә кергәннәр иде. Аларны күрү белән сихерчеләр дип белеп, тотып алдылар. Патша икесенең дә башын кисәргә боерды. Аларны мәйданга алып килделәр, җәлладлар башларын чабарга хәзерләнделәр.

Шулвакыт Әбүгалисина, Әбелхарисга карап:

— Мин киттем,— диде дә үзенең гыйлем көче белән җәлладлар күзеннән юк булды. Барысы да аптырап калдылар. Җәлладлар «һай-һу» дип Әбүгалисинаны эзләп киттеләр. Ыгы-зыгы белән хәтта Әбелхарисны да оныттылар. Аның кул-аякларын бәйләгән баулар чишелделәр, сарай түбәсенә таба сузылдылар. Әбелхарис, шул бау буенча үрмәләп, сарай түбәсенә менде дә юк булды.

Әбүгалисина Мисыр шәһәрендә

Әбүгалисина бик еракта булган Нил дәрьясына килеп чыкты. Аннан Мисыр шәһәренә барды. Базарларда йөри торгач, хәлвә сатучылар рәтенә килеп чыкты. Бер хәлвә кибетенә керде. Монда гаҗәп матур бер егет басып тора. Бу егет һәр көн кичтән хәлвә пешереп, аны шушы базарга чыгарып сата, шуннан килгән акча белән карчык анасын тәрбияләп яши иде. Ул бик булдыклы һәм оялчан да иде.

Хәлвәфрүш, Әбүгалисинаның үзенә болай текәлеп карап торганын күргәч, бик оялды, уңайсызланды. Аңа бераз хәлвә кисеп бирде. Әбүгалисина хәлвәне авызына капты да кире төкереп ташлады. Бәлки, ул бик оста хәлвә пешерүчедер дип, егет аны кичкә үзенең өенә чакырды.

Караңгылык төшкәч, Әбүгалисина Хәлвәфрүшнең өенә китте. Егет аны бик хуплап каршы алды. Бераз сөйләшеп утырдылар. Ләкин егетнең иртәгә сату итү өчен хәлвәсе әзер түгел иде. Ул сүзне шул якка борды:

— Вакыт бик аз калды, әфәндем, иртәгә сатарга хәлвәм юк. Ни боерасыз? — диде.

Әбүгалисина:

— Мин, сезне бу хезмәт һәм мәшәкатьләрдән коткарып, башка берәр һөнәр өйрәтергә уйлаган идем. Теләгегез хәлвә пешерү булгач, ярар алайса, бер капчык кибәк китерегез, мин сезгә кибәктән хәлвә пешереп күрсәтим,— диде.

Ничек итеп кибәктән хәлвә булсын инде?!

Шулай да егет сабыр итте. Әбүгалисинаның алдына бик күп кибәк китереп өйде.

Әбүгалисина кибәкләр тирәсендә нидер эшләде: кибәкләр барысы да хәлвәгә әверелделәр. Моңарчы мондый татлы хәлвәне беркемнең дә күргәне һәм берәүнең дә татып караганы юк иде.

Хәлвәфрүш Әбүгалисинаның, хикмәтле кеше икәнен белеп, үзенең өендә калуын үтенде.

Шул көннән алып, алар бергә тора башладылар.

Хәлвәфрүш һәм патша кызы

Әбүгалисина, симия гыйлеме белән, базар уртасында Хәлвәфрүш өчен күп бүлмәле зур кибет барлыкка китерде. Кибет бик зиннәтле булып, өстендә чарлагы да бар иде. Әбүгалисина белән Хәлвәфрүш шул чарлакка урнаштылар.

Ара-тирә Хәлвәфрүш хәлвәне урамда күтәреп йөреп тә сата башлады.

Көннәрдән бер көнне ул патша сарае турысыннан үтеп бара иде, аны патша кызы күрде. Аның матурлыгына хәйран булды, хәлвә алыр өчен дигән булып, аны сарайга чакырып кертте. Хәлвәфрүш, аз гына башын күтәреп, күз кырые белән генә кызга карап алды. «Бу кыз җир йөзендә булган вакытта, кичләрен тулган айның, көндезен якты кояшның кирәге юк икән»,— дип уйлады.

Хәлвәфрүш кибетенә кайтты. Аның төсе киткән, агарган иде, Әбүгалисинаның аягына егылып, башыннан үткәннәрне сөйләде. Патша кызына гашыйк булуын яшермәде.

Бик үтенеп сорагач, Әбүгалисина аның үтенечен кире кагарга батырчылык итмәде. Нәрсәдер эшләгән кебек итте. Шул арада күк күкрәгәндәй, җир тетрәгәндәй булды. Кинәт ишек ачылды. Ишектә гүзәлләрнең гүзәле патша кызы күренде.

Кыз, егеткә карап:

— Бу ни хәл? Сез пәриме, җенме әллә хикмәт гыйлеме белүче акыл иясе кешеме? Мин монда ничек килдем? — дип сорады.

— Шиккә төшмәгез, мин дә сезнең кебек үк бер кеше. Мин бозык кеше түгел. Сезгә зарар итәргә исәбем юк. Гаҗәп матурлыгыгызны күрдем, гашыйк булдым. Тагын бер мәртәбә күреп, нәфис тавышыгызны ишетеп, күңелемне юатырга теләдем. Борчуым өчен мине гафу итегез, ләкин монда ничек килүегез турында, зинһар дип әйтәм, сорамагыз...

Алар, төн буе сөйләшеп, дуслыкларын уртаклашып, төннең үткәнен сизми дә калдылар.

Яктыра башлады. Шул вакытта Әбүгалисина кереп, аерылырга вакыт җиткәнен белдерде. Озак та үтмәде, патша кызы үзенең сараенда булды.

Биремнәр

1. Укылган өзек — сюжетның төенләнү өлеше. Ни өчен төенләнү өлеше дип атала?

Кыз, сарайга кайткач, бу эшләрнең ахыры ничек булыр дип борчыла башлый. Үзенең патша кызы булуын, халык арасында яман аты чыкса, начар булачагын күз алдына китерә.

Кыз, шулай төрлесен уйлап, атам башка кешеләрдән ишеткәнче, үзем белдерим дип, бу төндә булып үткәннәр турында озын хат язды.

Патша, хатны укыгач, вәзирләрен, галимнәрен, хәкимнәрен һәм баһадирларын җыйды. Күп киңәшә торгач, шундый карарга килделәр: төн буе йокламыйча, кызның бүлмәсен бик нык сакларга, кораллы сакчылар куярга.

Менә йолдызлар калыкты. Хәлвәфрүш Әбүгалисина янына килеп ялынды, ялварды, бүген дә кызны үзе янына китерүне үтенде... Ул төнне дә кыз Хәлвәфрүш бүлмәсендә үткәрде.

Бу эшкә патшаның бик ачуы килде. Күп уйлый торгач, шундый карарга килделәр: әгәр тагын шундый хәл була калса, кызның кулын зәгъфранга[1] буяп җибәрергә кирәк, диделәр. «Кыз кич бара торган йортның ишегеннән кергәндә, аның тоткасында зәгъфран

---

[1] Зәгъфран — шәмәхә төстәге чәчәк.

буялган бармак эзләре калыр. Шул эзләр буенча ул йортны табу җиңел булыр»,— диделәр.

Чыннан да кыз, Хәлвәфрүшнең ишегеннән кергәндә тотканы тотып, биш бармак эзе калдырды.

Әбүгалисина бу хәлне белгән иде. Бер минут та кичекмәстән, шәһәрдәге йортларның һәм кибетләрнең ишек тоткаларына шундый ук биш бармак эзе төшерде.

Патша гаскәр башын чакырып алды да:

— Хәзер үк шәһәрдәге барлык йортларның ишек бауларын тикшерегез,— диде.

Гаскәр башы үзе белән берничә кеше алды да сарайдан чыгып китте... Ләкин кайсы гына йортка барып кермәсеннәр, барысының да ишек тоткасында бер үк төрле эзләр ярылып ята иде.

Моны ишеткәч, патша сакалын йолкып бетерде.

Аптырап-йөдәп беткәч, патшага әйтәләр:

— Багдад патшасының Әбелхарис исемле бер вәзире бар. Бу бәладән бары ул гына коткарса коткарыр,— диләр.

Әбелхарисның Багдад патшасында хезмәте

Әбелхарис, Әбүгалисинадан аерылгач, Багдад шәһәренә килеп чыкты. Урманга барып, кырык агач кисеп алып кайтты. «Барыгыз да кешеләр булыгыз»,— диде. Зифа буйлы кырык егет барлыкка килде. Әбелхарис егетләренә җиде көн эчендә кырык бүлмәле мунча салырга кушты. Шәһәрнең күренекле урынында мунча салынды.

Моның турындагы хәбәр патшага да барып ишетелде. Патша Әбелхарисны үзенең сараена чакыртты.

Багдад патшасы яшь бер егет иде. Ул, кешеләрдән ишетеп, Саба патшасының кызына гашыйк булды. Сорап карады, атасы риза булмады.

— Кызны минем яныма китерә алсагыз, хезмәтегезне һич тә онытмас идем! — дип, патша елап җибәрде.

Әбелхарис, үзе белән ияртеп, бер егет алып килгән иде, шуның колагына нидер әйтте. Егет баш иеп чыгып китте. Әбелхарис кире урынына утырганчы, егет, ә аның артыннан барлык кешеләрне үзенең матурлыгы белән истән яздырырлык бер гүзәл кыз керде.

Озакламый дөньяда охшашы булмаган туй ясалды. Әбелхарис патшаның иң якын киңәшчесенә әйләнде.

Әбелхарисның Мисырга килүе һәм Әбүгалисинага каршы көрәше

Багдад патшасы Мисыр патшасыннан Әбелхарисны җибәрүен үтенеп язган хат алгач, бу турыда Әбелхарисның үзе белән киңәшергә уйлады.

Моңа каршы Әбелхарис:

— Әгәр фәрманыгыз булса, баш өсте, мин анда барыйм,— дип ризалык бирде.

Әбелхарис симия гыйлеме көче белән шул көнне үк Мисырга барып та җитте. Әбелхарис Мисыр патшасына чын күңелдән ярдәм итәргә теләвен белдерде һәм эшенә дә керешге. Багу тактасын алып, хикмәт капчыгын чишеп, айны айга, туфракны туфракка орып, тирән уйга чумды.

Шуннан соң ул патшадан кызны күреп сөйләшергә рөхсәт сорады. Кыздан барысын да җентекләп сорашты. Симия гыйлеме белән ерткыч бер карчыга барлыкка китерде. Аны кызга бирде.

— Менә бу карчыганы ал. Егет өенә кергәч, аны җибәрерсең, ул сине җәфа чиктерүче кешенең йөрәген чукып, аны һәлак итәр,— диде. Тагын ул йортта ятрак ризык булса, шуның берәр кисәген алып кайтырга кушты.

Кыз, үзе генә калгач, кан яшьләре агызып елады. Ул, бер яктан, Хәлвәфрүшне ярата, ә икенче яктан, никадәр яратса да, аңарга кәләш булуны үзенә түбәнлек саный иде...

Әбүгалисина бу хәлне дә сизеп алган иде. Ул егеткә:

— Кызның кулында карчыга булыр, кыз бүлмәңә килеп керү белән, менә шушы яулыкны карчыганың башына капла,— дип, симия гыйлеме белән ясалган яулык бирде.

Әбүгалисина Хәлвәфрүшнең бүлмәсен Һиндстан тирәсендәге Мосасакия утравы йортларындагы бүлмәләргә охшатып бизәде. Табынга шул утрау тирәсендәге суларда гына була торган фил балыгы итен куйды.

Кыз бүлмәгә килеп керде. Карчыганы җибәрмәкче булды; Хәлвәфрүш тиз генә карчыганың өстенә яулыкны ябып өлгерде, карчыга һәлак булды.

Алар озак сөйләштеләр, бер-берсенә төрле үпкә сүзләр әйтештеләр. Кыз төрле-төрле ризыкларны мактыйм-мактый ашады. Шулай да ул бер кисәк фил балыгы итен алып, кулъяулыгына төреп, кесәсенә тыкты.

Фил балыгы итен күргәч, Әбелхарис бик шатланды:

— Бу балык Һиндстан диңгезендә була. Димәк, утлы утрау да анда булырга тиеш. Хәзер без җинаятьченең эзенә төшәрбез,— диде.

Патша, Һиндстан патшасына ашыгыч рәвештә хат язып, аннан ярдәм сорап, илчеләр җибәрде.

Һиндстан патшасы Мисыр патшасына болай дип хат язды: «Әгәр ут эченә кереп йөрергә көченнән килсә, шул ахмак хәкимегезнең үзен монда җибәрегез. Ул башлап керсә, без аның артыннан барырбыз».

Хатны укыгач, патшаның ачуы килде. Әбелхарисны бик каты әрләп ташлады:

— Син ахмак кеше икәнсең. Синдә гыйлем дә, хикмәт тә юк икән,— диде.

Әбүгалисина беркөнне мунчага барды. Юынып чыкканнан соң гына, түләргә акчасы юклыгын белде. Акча китергәнче, яулыгын калдырып торырга уйласа да, мунча хуҗасы риза булмады. Әбүгалисинаны әшәке сүзләр белән сүкте. Әбүгалисина мунча хуҗасыннан

үч алырга теләде. Мунча миче янында нидер эшләде. Шул минутта мунча сүрелә башлады. Озак та үтми, сулар катты, стеналар ап-ак кар белән капланды.

Бу хәбәр патша сараена да барып җитте. Әбелхарис патшага:

— Мин хәзер эшнең төбен аңладым: бу шәһәрдә симия гыйлемен бик яхшы белүче кеше булырга тиеш. Мунчачы ярдәме белән ул кешене эзләп табарбыз,— диде.

Мунча хуҗасына берничә кеше ияртеп, шәһәрдән дәрвишне эзләргә чыгарып җибәрделәр.

Әбүгалисина һәркем күрерлек бер җирдә утырып торырга булды. Эзләүчеләр аны күрделәр. Мунчачы:

— Менә ул дәрвиш, шушы кеше! — диде.

Гаскәр башы, килеп җитеп, Әбүгалисинаның якасына ябышты:

— Син кайда качып йөрисең? Сине сарайга чакыралар, әйдә киттек! — дип өстерәргә тотынды.

Шул арада Әбүгалисина кыяфәтен үзгәртте: үзе дә гаскәр башы кыяфәтенә керде. Әбүгалисина да, гаскәр башының якасына ябышып:

— Кайда качып йөрисең, әйдә, сине сарайга чакыралар,— дип өстери башлады.

Шулай якалашып, алар патша сараена барып керделәр. Боларның кайсы чын гаскәр башы икәнен белми аптырап калдылар.

— Боларны ни эшләтергә? — дип, шәһәр казыена сорау бирделәр. Ул:

— Икесен дә асарга кирәк. Бер гаскәр башы үлгәннән әллә ни булмас! — диде.

Әбүгалисина үзен асарга әзерләнгән баш җәлладны гаскәр башы кыяфәтенә кертте, үзе баш җәллад кыяфәтенә керде. Ярдәмче җәлладларга кушып, гаскәр башы белән җәлладны астырды.

Бераздан асылган кешеләрнең гаскәр башы белән баш җәллад икәнен беләләр. Шәһәр халкы бу ике явызның үлүенә бик шатланды.

Комсызлык бәласе

Хәлвәфрүш, Әбүгалисинага ялынып, ихфа[1] гыйлемен өйрәтүен үтенә. Әбүгалисина башта:

— Син ихфа гыйлемен өйрәнсәң, тиешсез урында файдаланып һәлак булырсың,— дип өйрәтергә теләми. Ләкин егет бик нык вәгъдәләр биргәч, күзләренә ихфа сөрмәсе сөртеп, кеше күзенә күренми йөрергә өйрәтә.

Көннәрдән бер көнне Хәлвәфрүш, күзенә сөрмә сөртеп, сарайга китә... Егет, кичкә кадәр сарайда торып, кызны юатырга тырышты. Үзенең һәр көн кич күренә торган егет икәненә кызны ышандырырга теләде. Кичен, саубуллашып, сарайдан китеп барды.

Егет киткәч, кыз бу вакыйганы үзенең тәрбиячесенә сөйләде. Ул патшага ирештерде. Патша Әбелхарис белән киңәште. Әбелхарис:

— Аны кулга төшерергә була,— диде һәм ничек эш итәргә кирәклеген өйрәтте. Икенче көнне Хәлвәфрүш тагын сарайга килде. Кыз аны ачык йөз белән каршы алды, бер йомыш тапкан булып чыгып китте.

Кыз чыккач, ишекне бикләп алдылар. Бүлмә эченә төтен җибәрә башладылар. Егетнең күзенә төтен кереп, яше ага башлады. Яше белән сөрмә дә юыла барды. Шулай итеп, егетнең бөтен гәүдәсе күренә башлады. Аны тотып, патша каршына алып бардылар. Патшаның һәрбер соравына каршы егет тик тору белән җавап бирде.

Патшаның бик ачуы килде:

— Бу бәдбәхетне, барабан кагып, мәсхәрә кылып, шәһәр буенча йөртегез. Җиде көн йөрткәннән соң, шәһәр капкасына асып үтерегез,— диде. Хәлвәфрүшне урам буйлап йөртергә алып чыгып киттеләр.

Әбүгалисина да, бу хәбәрне ишетеп, урамга чыкты. Хәлвәфрүшкә таба карап, кулы белән бер кизәнде, богаулар, чылбырлар өзелделәр, Хәлвәфрүш юк булды.

---

[1] Ихфа — тылсым.

Сарай һаман тынычланмады

Патша вәзирләрен җыеп киңәш итте. Ахырда бер карарга килделәр: кызны шәһәр буенча алып йөрергә уйладылар.

— Бәлки ул үзе килеп йөри торган йортны табып күрсәтер,— диделәр.

Күп көннәр йөри торгач, алар Хәлвәфрүш яши торган урамга килеп керделәр. Кыз, Хәлвәфрүшнең өен танып, сакчыларга күрсәтте. Патша:

— Миңа аның кайда торганлыгын белү кадерле иде. Корал көче белән кулга төшерермен! — диде.

Гаскәр җыелды. Патшага ат һәм корал бирделәр. Патша, үзенең гаскәре белән Хәлвәфрүшнең кибетенә якынлашкач:

— Дәрвишнең бүлмәсен камап алыгыз, ут төртегез! — дип боерды.

Әбүгалисина моны күрде, йокыга киткән кеше кебек, башын бөгеп бераз утырды. Озак та үтмәде, кибеттән яхшы коралланган атлы һәм җәяүле гаскәрләр чыгып, патша гаскәрләренә каршы тезелә башладылар. Көчле сугыш башланып китте. Бу хәлне күреп, шәһәр халкы, кан коюга сәбәпче булган өчен, патшага бик ачуландылар.

Бер сәгать эчендә патша гаскәрләре чигенә, кача башладылар. Әбүгалисина патшага хат язды: «Йә безнең белән килешеп, кызыңны бирәсең, йә бөтен шәһәреңне харап итәрсең!» — диде.

Патша кызын бирергә риза булды.

Сугыш туктатылды. Әбүгалисинаның гаскәрләре хәлвә кибетенә кереп югала бардылар.

Әбүгалисина патша сараенда

Патша үзенең кызын гади бер хәлвә пешерүчегә бирергә хурлана иде. Сарай халкы, ышанычлы бер кешене җибәреп, Әбүгалисинаны сарайга чакырырга, яхшылык белән үтенеп карарга киңәш бирде.

Киңәшкәннән соң Әбелхарисны җибәрергә булдылар.

Әбүгалисина үзенең туганын бик олылап каршы алды. Алар, бер-берсеннән аерылышканнан соң, башларыннан үткәннәрне сөйләшеп, озак утырдылар. Шуннан соң Әбелхарис монда ни өчен килүе турында әйтте. Аңа каршы Әбүгалисина:

— Изгелекне белми торган, кире беткән патшагыз өчен түгел, туган кардәшем чакырырга килгәнгә генә барам,— дип җавап бирде.

Патша, Әбүгалисинага кул биреп күрешеп, аны үз янына утыртты:

— И мәмләкәтебезнең бөек акыл иясе! Сез үзегезнең хикмәтләрегездән кайберләрен сарай халкына күрсәтә алмассызмы? — диде.

Әбүгалисина бер ләгән су китерергә кушты. Китергәч:

— Менә шул суга карагыз,— диде.

Патша үзе карамакчы булды. Ул үзен ком сахрасында эссе кояш астында күрде. Кояш шулкадәр көйдерә, кереп хәл алырлык кечкенә генә бер күләгә дә юк. Бик эчәсе килгәч, су эзләп китте... Бик куе агачлы урманга барып җитте. Анда челтерәп су ага иде. Кызу-кызу атлап, су янына барса, җиде башлы аждаһа тора. Аждаһа аның өстенә ташланды. Патшаның коты очып, кычкырып җибәрде. Аждаһа, йотарга теләп, авызын ачуга, бер яктан, Әбүгалисина килеп чыкты. Патша, күз яше белән елап, аңа ялына башлады:

— Кызган мине! Бөтен мәмләкәтемне ал, тик мине коткара күр! — диде.

Әбүгалисина аны биргән вәгъдәсен бозмаячагына ант иттерде, аннары таягын селтәгән иде, аждаһа юкка чыкты. Ул патшага:

— Теләгегез булдымы?! — дип сорау бирде.

— Артыгы белән, хәким. Бераз акылыбызны җыеп ял итик. Аннан соң туй ясарбыз,— диде.

Әбелхарис патша алдында үзен акламакчы була

Патша вәгъдәсен тагын бозарга уйлады. Ул, Әбелхарисны чакырып:

— Минем башыма килгән бу хәсрәтләрне җиңеләйтергә кулыгыздан килмәде,— дип, үзенең ризасызлыгын белдерде.

Әбелхарис бу сүзләрдән бик хурланды. Ул үз-үзенә болай диде: «Мин Багдадтагы кебек мунча салырмын һәм шуның аша Әбүгалисинаны кулга төшерермен».

Шулай итеп, Әбелхарис, патшага ярар өчен, үзенең туганына хыянәт итәргә уйлады.

Әбелхарис Багдадтагы кебек мунча өлгертте. Аны күрер өчен, шәһәрнең төрле почмакларыннан кешеләр килделәр. Хәлвәфрүш белән Әбүгалисина да мунчаны карарга килделәр. Мунчага кереп, чишенеп, юына башлау белән, Әбелхарис аңа үзенең гыйлеме белән тәэсир итте. Әбүгалисинаның акылы башыннан чыкты, һәм ул Мисырдан берничә айлык ераклыктагы бер сахрага барып төште.

Күп михнәтләр күргәннән соң, Әбүгалисина Мисырга кайтып җитте.

Хәлвәфрүшнең анасы ишек ачты, Әбүгалисинаны күргәч елап җибәрде:

— Улымны тотып алып киттеләр, бүген башын кисәләр,— диде.

Әбүгалисина бик кайгырды. Хәлвәфрүшне коткару өчен ничек тә сарайга керергә кирәк иде. Ул патшаның матур гөлләр яратуын белгән иде. Гөл сатучы булып, кыяфәтен үзгәртеп, сарайга керде.

Патша, гөлләрнең матурлыгына сокланып, арадан бик матур берсен алды һәм, исләме икән, иснәп карагыз, әфәндем, дип, Әбелхариска бирде. Әбелхарис гөлне борыны янына китерү белән егылды һәм шул минутта ук үлде. Чөнки бу гөлләрнең чәчәкләре агулы иде. Әбүгалисина моның өчен үкенде, борчылды: үз

туганын болай һәлак итәргә һич тә теләмәгән иде. Әбүгалисина шул ук минутта күздән югалды.

Бераздан Хәлвәфрүшне җәза мәйданына китерделәр. Әбүгалисина аны җәлладлар кулыннан тартып алды. Хәлвәфрүш күздән югалды.

Хәлвәфрүшнең патша кызына өйләнүе

Патша, Хәлвәфрүшнең юкка чыгуын ишетеп, бик аптырады. «Бу эш гөл сатучы белән бәйләнгән булырга тиеш»,— дип уйлады. Ул аларны тагын кулга төшерү юлларын эзли башлады. Шул вакытта аңа бер хат китереп бирделәр. Бу хат Әбүгалисинадан булып, анда түбәндәгеләр язылган иде: «И киребеткән патша! Сезнең сараегызга гөл сатарга килгән кеше мин идем. Ләкин, кызганычка каршы, сез иснәргә тиешле гөлне минем туганым Әбелхарис иснәп һәлак булды. Хәлвәфрүшне сезнең җәзалаудан мин коткарып калдым...

Соңгы мәртәбә сорыйм: үзегезнең ихтыярыгыз белән кызыгызны Хәлвәфрүшкә бирегез, юкса башыгызга зур һәлакәт килер!..»

Патша тагын бер мәртәбә талпынып, сынап карарга уйлады: Әбүгалисинага каршы көрәшү өчен, сихерчеләр эзләргә чит илләргә кешеләр җибәрде.

Патшаның бу уе да Әбүгалисинага билгеле булып, аның соң дәрәҗәдә ачуын чыгарды. Ахры, бу юньсез белән болай гына эш чыкмас дип, тагын бер чара күрергә уйлады.

Менә һавада болыт күренә. Озак та үтми, һавадан гөберле бакалар ява башлый. Алар бакылдаша-бакылдаша төшәләр. Җиргә төшкән берсе үлеп барып, шәһәрне сасы ис баса. Шәһәрдә чыдау мөмкинлеге калмый.

Шәһәр халкы бу эшләрнең патшага ачу итеп Әбүгалисина тарафыннан эшләнгәнлеген беләләр һәм, патшага барып, болай диләр:

— Әгәр кызыгызны Хәлвәфрүшкә биреп, безне бу бәладән коткармасагыз, үзегезне һәлак итәчәкбез...

Патшаның башкача эшләргә җае калмый. Ул, үзе халык алдына чыгып, кызын Хәлвәфрүшкә бирергә риза булганлыгын белдерә.

Әбүгалисина, халыкның үтенечен кабул итеп, шул ук минутта бака яңгырын туктата. Шәһәр урамы үлек бакалардан чистара.

Патша, шәһәрдәге барлык кешеләрнең катнашы белән, зур туй ясады. Хәлвәфрүшкә асыл киемнәр киендереп, аны патша белән һәм сарай кешеләре белән күрештерделәр. Кияүнең матурлыгын һәм акыллылыгын күргән һәрбер кеше гаҗәпкә калды.

— Шаһзадәләр арасында берәү дә кызга бу кадәр тиң була алмас иде! — диделәр.

Хәлвәфрүш үзенең сөйгән яры белән матур гына тора башлады. Шулай итеп, Әбүгалисина үзенең дуслык бурычын ахырына кадәр үтәде.

2. Сюжетның башка өлешләрен табыгыз.
3. Сюжет хәрәкәтен ачыклыйк.
4. Әсәргә анализ ясагыз.
5. Үзегезне шушы әкият эчендәге Әбүгалисина дип уйлагыз. Шулкадәр белемегез, һөнәрләрегез булса, сез ниләр эшләр идегез? Бу әкият өчен теләсә нинди башка вакыйга да уйлап таба аласыз.

Шәүкәт Галиев

Сәер кеше

Казан тирәсендәге
Урманнарның берсендә
Юлыкканнар туристлар
Бик шикле бер кешегә.

Һәркем кара күзлектән,
Тик ул кара күзлексез,
Як-ягына текәлеп,
Күзәтә, ди, өзлексез.

Болай карап торышка
Безнең кебек, ди, үзе.
Ныклабрак карасаң,
Түгел кебек, ди, үзе.

Күпне күргән туристлар
Бер карауда сизенгән,
Белдермичә үзенә
Атлаганнар эзеннән...

Шомырт күргән — иснәгән,
Сирень күргән — кисмәгән,
Кырмыска оясына
Таяк тыгып китмәгән!

Гөмбәләргә типмәгән,
Кошларга таш атмаган,
Көне буе йөреп тә
Хәтта учак якмаган!

Сәер кеше, бик сәер...
Болай булмый тормышта,
Димәк ки, ул эзләрен
Калдырмаска тырыша!

Күзләп барган туристлар
Аның тагын нишләрен.
Менә теге берзаман
Салып куйган биштәрен.

Утырып сөт эчкән, ди,
Тәмәке дә тартмаган.
Алып киткән шешәсен —
Төпкә бәреп ватмаган!

Кыен түгел төшенү
Моның исәпләренә —
Җыеп, төреп алган ул
Кәгазь кисәкләрен дә!

Оргсинтез янына
Чыккан да ул урманнан,
Троллейбуска утырган
Шунда эзе югалган.

Чөнки карап торырга
Безнең кебек, ди, үзе.
Ныклабрак карасаң,
Түгел кебек, ди, үзе.

Үзем аны күрмәдем,
Сөйләгәнне ишеттем.
Булды микән ул кеше —
Ышандырмый ничектер...

Биремнәр

1. Шигырьгә анализ ясагыз.
2. Яхшылык эчендәге яманлыкны автор бик кыска итеп әйтеп биргән. Шул җөмләне табыгыз.

Әхсән Баян

Язгы чәчәкләр

Язның елмаеп-көлеп торган мәлендә хәерсез хәл килеп чыгар дип кем уйлаган. Шундый да матур көндә, җитмәсә, укытучыбыз Лилия апаның туган көнендә!

Белдерүләр тактасына барлык укытучылар, барлык укучылар исеменнән Лилия апаны котлап язылган кәгазь күргәч, без сыйныфыбыз белән аптырап калдык. Башкалардан алда, иң беренче булып, без укытучыбызны котларга тиеш идек ләбаса.

Башта кызлар, аннары малайлар да җыелышып, баш ватарга керештек. Уйлый торгач, шундый фикер туды: Лилия апаны котламый калу ярамый, соңгы дәрескә кергәндә, аны чәчәк бәйләме белән каршы алырга кирәк. Тик менә чәчәкне кайдан табарга? Бакча турында әйтмәстән, кырда, урманда да чәчәкләр әле юк диярлек. Аннары вакыт та бик аз — соңгы дәрескә ике генә сәгать калды. Хәер, тора-бара анысы да хәл ителде. Үзенең чаялыгы белән арабызда дан тоткан Рәшит, һич икеләнергә урын калдырмыйча:

— Мин табам чәчәкләрне,— дигәч, бөтенебез бертавыштан кычкырып җибәрдек:

— Ничек? Кайдан аласың?

— Табам булгач табам. Тик менә нишләргә? Миңа бер дәресне тозларга туры килә бит — чәчәкне җыярга, алып килергә...

Нишлисең инде, үзе риза булгач, аның бер сәгать дәрес калдыруына без дә каршы килмәдек. Изге юлда әзрәк гөнаһ кылына икән, гафу ителер әле, дип уйладык. Рәшит китте. Ул бер сәгатьтән әйләнеп тә килде. Менә хикмәт! Кулында язның бөтен-бөтен ямен балкытып торган кып-кызыл чәчәкләр! Рәшит үзе дә кулындагы лаләләр кебек кызарып, янып тора. Авызы колагына җиткән. Менә ичмасам уңган малай, менә ичмасам булдырган!

Кызлар, банка табып, тиз арада чәчәк бәйләмен өстәл уртасына бастырып та куйдылар. Нәкъ үзебез теләгәнчә килеп чыкты.

Лилия апабыз соңгы дәрескә керүгә, аягүрә торып, дәррәү кул чабарга керештек. Барыбыз да бая Рәшит елмайганча елмаябыз, шатланабыз. Апа, әлбәттә, чәчәкләрне ишек төбеннән үк күреп, хикмәтнең нәрсәдә икәнен тиз аңлады, чәчәкләрне күкрәк турысына күтәреп, сөйгәндәй итеп, безгә күптин-күп рәхмәт яудырды... Ләкин тантанабыз бер сәгатькә генә барды. Дәрес беткәнче генә. Алда безне бүтән сабак көткән икән. Ул сабакны бирергә тиешле кеше — пенсионер

Кәбир абый — ишекне ачты да, Лилия апа рөхсәт иткәч, туп-туры өстәл янына узды. Кар төсле чәчләрен сыйпап, кем өчендер оялгандай кызара төшеп, шундый яман хәбәр китерде: безнең чая, уңган Рәшитебез лаләләрне шушы Кәбир абый бакчасыннан чәлдереп чыккан икән ләбаса.

Лилия апа, бер агарып, бер күгәреп дигәндәй, беравык тын торгач, Рәшиткә сүз кушты:

— Кәбир абый сүзе дөресме?

Рәшит торып басты. Бите баягыча ук кып-кызыл булып янса да, бит кызыллыгы лалә төсенә бик тә охшаса да, бу юлы һич тә бәхетле уңыш аркасында түгел иде...

Рәшит җавап бирә алмыйча интеккән арада, Кәбир абый аны бәладән коткарырга ашыкты... Ул болай диде:

— Мин шуны теләр идем, балалар, җәй көне бөтен сыйныфыгыз белән минем бакчага килегез... Мин сезгә ышанам. Сез ризамы шуңа?

Бөтенебез берьюлы: «Риза!» — дип кычкыргач, Лилия апа да, сүзне куертмыйча, безгә таралырга рөхсәт бирде. Үзе Кәбир абыйны озата китте. Өстәлдәге лалә чәчәкләре дә, нидер сизенгәндәй, моңаеп, каралып калдылар.

Килешү шартын без, әлбәттә, онытмадык. Җәй уртасында Кәбир абый бакчасына килдек...

Биремнәр

1. Чәчәкләрнең мәгънәсен әйтегез.
2. Рәшит холкы турында сөйләгез.

Фатих Кәрим

Якынайганераклык

Ерагаясың, дип кайгырма син,
Без дошманны куып барабыз,
Ни кадәрле ерак куа алсак,
Шул кадәрле якын арабыз.

Бирем

Шигырьгә анализ ясагыз.

Нәҗип Думави

Шәфәкъ чабуы

Әкрен-әкрен сунә кичке шәфәкъ[1],
Тарта бугай кояш чабуын.
Караңгы төн, көчкә-көчкә сөйрәп,
Алып килә калын ябуын[2]...

Бирем

Дүртьюллыкны мәгънәләрен аңлатып сөйләгез.

Ференц Моро

Өч мати

(Хикәя)

Мин белем алган мәктәп ярлы да иде соң! Нәкъ әкияттәге кебек: ишеге дә, тәрәзәсе дә юк. Тәрәзәсе барын бар иде болай, ләкин шундый кечкенә, аңа каршында үскән көләч көнбагыш башы да сыярлык түгел иде. Аның каравы ишеге шундый зур иде, ничек итеп безнең бөтен сыйныф бүлмәсе урамга чыгып китмәгән икән аннан дип, әле дә гаҗәпләнәм. Шуның өстенә әле ул искенең дә искесе, ярыклары шундый киң — укытучы әфәнденең Бодри кушаматлы эте өргән саен, мәчесе бүлмәгә шул ярыклардан гына сикереп керә иде.

Парталарны үзебез әтмәлләдек. Икешәр кеше җыела идек тә парта әзер булганга кадәр кисә, турый, ышкылый, юна идек. Бер укучы — бер якта, икенче укучы икенче якта утыра иде. Үзебез ясаган парталарга, әлбәттә, хәзерге мәктәпләрдә сез утырган кебек уңайлап утырып булмый иде, шулай да без грифель такталарына «г» хәрефен шундый дәү итеп төшерә идек,

---

[1] Шәфәкъ — кояш баеганнан соң, күктә кояш нурларыннан була торган кызыллык.

[2] Ябу — *бу урында*: бит япкычы. Элек татар кызлары битләренә пәрәнҗә ябып йөргәннәр.

тактага чак-чак кына сыя иде. Берчакны «г» хәрефен тактага язганда шундый мавыгып киткәнбез, ишек шакыганны да ишетми калганбыз. Башларны күтәреп караганда, ишектән кергән малай укытучы әфәнде каршында басып тора иде инде. Ябык, ап-ак йөзле, яланаяклы малай иде ул. Монда килеп җиткәнче ничек җил очырып китмәгәндер.

— Сиңа нәрсә кирәк, балакай? — дип сорады укытучы.

— Мәктәптә укыйсым килә,— дип пышылдады малай кыюсыз гына.

— Кем буласың соң син? Безнең авылга ничек килеп чыктың?

— Ятим мин, анам да, атам да юк. Сезнең авылда яшәүче бер кардәшем алып килде.

— Кардәшең кем була соң?

— Икмәк пешерүче Банош карт.

Банош карт кебек сәләмә киемле кеше безнең авылда бүтән юк иде. Малайлар һаман да аннан көлеп кызык табалар иде.

— Ә исемең ничек?

— Өч Мати.

Мондый әкәмәт исемне әкиятләрдә дә ишетмәссең. Хәтта укытучы әфәнде дә елмаеп куйды, зур түгәрәк күзлеген борынына элде дә, малайга күзлеге аша карап:

— Син, балакай, Өч Матига түгел, бер Мати өчен дә кечкенә әле. Берьюлы Өч Матига урын табып булыр микән соң? — диде.

Ә без әкрен генә сукрана башладык:

— Кертмибез сыйныфка. Урын юк!.. Үзе өчен үзе парта ясасын!

Өч Мати каушап калды, кулына тоткан бүреген әйләндерә-әйләндерә, аска карап тора бирде.

— Беләсеңме нәрсә, балакай? — диде укытучы.— Мич артына, почмакка урнаш. Кыш көне җылы булыр!

Безнең мәктәптә зур саман[1] мич бар иде. Мати шул мич белән стена арасына кереп урнашты. Мич арасының моңарчы бу кадәр уңай кешене күргәне юк иде әле. Ә минем Мати кадәр ярдәмчесез мәхлукны гомердә күргәнем булмады. Без аңардан көлдек тә көлдек. Өч Мати безгә бер тапкыр да җавап бирмәде.

Аның каравы укытучы әфәндегә Матиның җавапларын еш ишетергә туры килде. Яңа ел җитүгә, Мати алдынгы укучыга әверелде. Нинди дә булса берәр сорауга без беребез дә җавап бирә алмасак, укытучы: «Йәле, Өч Мати, син нәрсә диярсең?» — ди иде. Арифметика дәресендә берәр мәсьәләне чишү юлын беребез дә таба алмасак, тагын: «Әйтеп бир инде, Мати»,— дигән сүзне ишетә идек. Сәйләп тезгән кебек матур итеп яза, дәрестә челтерәп аккан чишмә тавышыдай тигез тавыш белән җавап бирә иде Мати.

Әмма бервакытны Мати бөтенләй тып-тын калды. Укытучы сорауларына көчкә-көчкә генә җавап бирә башлады. Нәрсәдер мыгырдый шунда, тыңласаң күңелләр болгана хәтта. Язганына карыйсы да килми: хәрефләре кырдагы башаклардай чуалган була! Укытучы чакырган чакта, Мати такта янына элеккечә туп кебек сикерә-сикерә чыкмый, канаты сынган чыпчык сымак өстерәлеп кенә килә иде.

— Нәрсә булды сиңа, Мати? Нәрсә булды, балакай? — дип сорый иде аннан укытучы әфәнде еш кына һәм аның батып кергән яңагыннан сыйпап куя иде.

— Берни дә булмады,— ди Мати сүлпән генә һәм үз почмагына көч-хәл белән өстерәлеп китә иде.

Без дә аны бик кызгандык.

Без инде аңа ачу тотмый идек, чөнки ул бездән артык яхшы укымый иде. Укытучы әфәнде дә аны мактамый башлады.

Ә Мати, башланган икмәктәй, һаман сыза, һаман ябыга барды. Бервакытны ул, дәрес вакытында йоклап

---

[1] Саман кирпеч — балчыкка салам кушып ясаган кирпеч.

китеп, китабы кулыннан шап итеп төшкәч тә уянмады. Мичкә башын куеп йоклый бирде, тик укытучы әфәнде селки башлагач кына уяныл китте.

— Балакай, әйберләреңне җый да өеңә кайтып кит. Кулына китап тотып йоклый торган кешегә сыйныфта урын юк.

Малай кызарган күзләрен укытучыга төбәде, ләкин бер сүз дә әйтмәде. Китапларын, дәфтәрләрен җыйды да күзләре яшьләнгән хәлдә сыйныфтан чыгып китте.

Укытучы әфәнде аны хәсрәтле караш белән озатып калды, аннары, кәефе кырылган кыяфәт белән, сыйныф буйлап йөрергә тотынды. Шуннан соң ул:

— Балалар, тыныч кына утырыгыз. Мин Өч Матиның өенә барып кайтам,— диде.

Ә безнең бер дә шаярасы килмәде. Матига нәрсә булыр икән инде дип сөйләшеп кенә утырганда, һич искәрмәстән укытучы әфәнде кайтып керде. Ул, авыру кошчыкны күтәргәндәй, Матины күтәргән иде.

— Урыннарыгыздан торыгыз, балалар! — диде ул.— Иптәшегезгә ихтирам күрсәтегез. Пал Кинижи[1] кебек үк герой булып чыкты ул безнең Мати. Пал Кинижи баһадир булган, сугышта куркуның ни икәнен дә белмәгән. Ә безнең Мати уалырга торган камыш кебек. Менә шушы йомшак, нечкә күңелле бала бер ай буена төннән таңга кадәр керфек тә какмаган. Икмәк пешерүче Банош карт авырып киткән дә, шул көннән бирле Мати аның өчен икмәк пешергән. Балалар, кечкенә геройны хөрмәт итегез! Кем аны үз янына утыртырга тели?

Барыбыз да аякларыбызга бастык:

— Мин! Мин!..

Өч Матиның үз яныма утырырга теләве белән гомерем буена горурланам мин.

---

[1] Пал Кинижи — Венгриянең милли герое.

Бирем

Сюжеттагы киеренкелек төенләнү белән башланып, киеренкелеге арта-арта кульминацион ноктага җитәргә һәм кинәт чишелергә тиеш. Ләкин Өч Мати белән сыйныфташлары арасында бернинди дә конфликт юк. Чөнки Өч Мати кыерсытучыларга җавап бирми. Димәк, киеренкелек персонажларның күңелендә генә була ала. Кем күңелендәге хисләр хәрәкәткә киләләр, үзгәрәләр һәм чишеләләр?

Мәхмүт Газизов

Парикмахер

Күрше дустым Минтаһир
чәч алырга бик маһир:
җилкәңә җәймә салыр,
чәчеңне җайга салыр.
Кулга кайчысын алыр
яки пәкесен алыр:
алай итәр,
болай итәр,
ничек кирәк
шулай итәр,
үзе көләр,
үзе кыркыр,
бераз кисәр,
бераз йолкыр.
Чәчең җитсә кайгырма,
тот та чәчтараш чакыр;
килеп җитәр Минтаһир —
иң маһир парикмахер...
....
чәчең мап-матур калыр.

Биремнәр

1. Ноктлалар урынына нинди сүзләр куяр идегез.
2. Шигырь әдәбиятның кайсы төренә, кайсы жанрына карый? Исбат итегез.

ӘЙДӘГЕЗ, ӨЙДӘ УКЫЙБЫЗ!

Гамил Афзал

Кышкы урман

Рафинадтай аксыл зәңгәр юлдан
Ат юыртып бара бер көйгә.
Йокымсырап утыра кышкы урман,
Кышкы урман гүя төш күрә.

Айлы төндә бәсле урман юлы
Бер карасаң хәйран калырлык,
Гүя монда сихри әкият тулы,
Җем-җем итеп торган матурлык.

Фирүзәдәй зәңгәр күк фонында
Чыршылар ак бүрек кигәннәр.
Тирән уйга талып ай нурында
Күрәзәлек[1] итә имәннәр.

Гүя монда туйга зиннәтләнгән
Әкиятләрдә күргән патшалык,
Тылсым көче белән бизәкләнгән
Ак киемнән тора бар халык.

Яшь ботаклар кинәт уянгандай,
Иңнәремә энҗе койдылар,
Ә күңелдә калды серле моңдай,
Әйтеп булмый торган тойгылар.

Бирем

Әсәргә анализ ясагыз.

Ханс Кристиан Андерсен

Чакматаш

(Әкият)

Юл буйлап солдат бара икән: бер-ике! бер-ике! Аңа юлда убырлы карчык очраган. Карт һәм куркыныч булган ул карчык. Аскы ирене күкрәгенә кадәр салынып төшкән икән аның.

[1] Күрәзәлек — алдан күрү, фараз итү.

— Нихәл, егеткәй! — дигән карчык.— Телисеңме, солдат, мин сиңа акча бирәм?

— Рәхмәт, карт убыр! — дигән солдат һәм кесәсенең авызын ачарга әзерләнгән.

— Ә, юк,— дигән убырлы карчык,— бераз гына сабыр ит. Әнә теге зур агачны күрәсеңме? Эче буш аның. Агачның очына менгәч, эчтә бер куыш күрерсең. Шул куышка кер дә аска кадәр төш. Ә мин синең биленә бау бәйләрмен дә, син кычкыруга, өскә тартып чыгарырмын. Түбәнгә кадәр төшеп җиткәч, озын җир асты юлына тап булырсың. Анда бик якты — көндез дә, төнлә дә йөзләгән утлар яна. Анда-монда борылмыйча гына, җир асты юлыннан туры бар. Азагына барып терәлгәч, каршыңда өч ишек булыр. Һәр ишектән ачкычлар чыгып торыр. Шуларны бор, һәм ишекләр ачылып китәр. Беренче бүлмәдә зур сандык тора. Сандык өстендә эт утыра. Ул этнең күзләре ике чынаяк тәлинкәсе сыман. Тик син курыкма. Мин сиңа үземнең шакмаклы зәңгәр алъяпкычымны бирермен. Син шуны идәнгә җәй дә, шикләнмичә, этне эләктер. Эләктереп ал да тизрәк минем алъяпкычка утырт. Аннан соң инде сандыкны ач та акчаны күңелең теләгән кадәр ал. Тик ул сандыкта бары тик бакыр акчалар гына. Көмеш акчалар теләсәң, икенче бүлмәгә кер. Анда да сандык өстендә шулай ук зур эт утыра. Ә күзләре аның тегермән ташлары кадәрле. Тик син курыкма гына — этне эләктер дә алъяпкычка утырт, аннан соң көмеш акчаларны ал. Әгәр дә инде алтын акчалар кирәксә, өченче бүлмәгә керерсең. Өченче бүлмәнең уртасында алтын белән түбәләмә тулы дәү сандык тора. Бу сандыкны этләрнең иң зурысы саклый. Аның бер-бер күзе генә дә бер өй түбәсе кадәр! Әгәр дә инде анысын да минем алъяпкычка утырта алсаң — синең бәхет: эт сиңа тимәс. Ул вакытта инде алтынны җаның никадәр теләсә, шулкадәр алырсың!

— Боларның барысы да яхшы, әлбәттә,— дигән солдат.— Тик моның өчен син миннән нәрсә алырсың

икән соң, карт убыр? Сиңа миннән ни дә булса кирәктер ләбаса?!

— Миңа синең сукыр бер тиенең дә кирәкми! — дигән карчык.— Тик син миңа борынгы чакматашны гына алып чык. Соңгы тапкыр кергәндә, минем әбием онытып калдырган аны.

— Ярар, алайса, бәйлә бавыңны! — дигән солдат.

— Булды! — дигән карчык.— Менә сиңа минем шакмаклы алъяпкычым.

Һәм солдат агач башына үрмәләгән. Андагы куышны табып, түбәнгә төшеп киткән.

Убырлы карчык ни әйтсә, нәкъ шулай булып чыккан да: солдат каршында җир асты юлы сузылып ята, ди. Эчтә көндезге кебек яп-якты — меңнәрчә утлар балкып тора икән.

Солдат шушы юл буйлап киткән. Барган, барган да бу, ниһаять, аның азагына барып чыккан.

Ары барыр чама юк икән. Каршыда өч ишек, өчесеннән дә ачкычлар тырпаеп тора, ди.

Солдат беренче ишекне ачкан да эчкә узган, уртасында сандык, ә сандык өстендә эт утыра икән. Күзләре — ике чәй тәлинкәсе диярсең. Эт үзе солдатка карый, үзе куркыныч күзләрен әле бер, әле икенче якка әйләндерә.

— Котсызларның да котсызы бу! — дигән солдат һәм, этне әләктереп, күз ачып йомганчы убырлы карчык алъяпкычы өстенә утыртып та куйган.

Эт шунда ук юашланган, ә солдат сандыкны ачкан да тотынган тегеннән акча сосарга!

Кесәләрен бакыр акчалар белән дыңгычлап тутырган да, сандыкны ябып, аның өстенә этне кабат менгереп утырткан, ә үзе икенче бүлмәгә юл тоткан.

Убырлы карчык дөрес әйткән икән — бу бүлмәдәге сандык өстендә дә эт утыра, ди.

Тегермән ташы да тегермән ташы, моның күзләре дә тегермән ташы.

— Йә, нәрсәгә дип миңа текәлдең шулкадәр? Күзләрең атылып чыкмагае! — дигән солдат һәм, этне эләктереп, аны убырлы карчык алъяпкычына утырткан, ә үзе тизрәк сандык янына килгән.

Сандык көмеш белән туп-тулы. Солдат, бакыр акчаларын идәнгә бушатып, ике кесәсе белән биштәренә, тәя-тәя, көмеш тутырган. Аннан соң солдат өченче бүлмәгә дә кергән. Кергән дә, авызын ачып, өнсез калган. Могҗиза дисәң дә могҗиза!

Бүлмә уртасында алтын сандык тора, ә сандык өстендә чын мәгънәсендә коточкыч нәрсә утыра. Күзләре артык та түгел, ким дә түгел, ике өй түбәсе кадәр. Үзләре иң тиз йөрешле карета тәгәрмәчләре сыман берөзлексез әйләнеп тора, ди

— Сәламәтлек телим! — дигән солдат һәм, генерал каршында торгандай, уң кулын фуражка козерегына китергән.

Хәер, озак уйлап тормаган солдат. Этне кочагына күтәреп алган да карчык алъяпкычына утырткан, ә үзе сандыкның капкачын ачкан.

Йа Хода, никадәр алтын булган монда! Бу алтынга зур бер башкала шәһәрен, барлык уенчыкларны, барлык кургашын солдатларны, барлык агач атларны һәм дөньядагы барлык прәннекләрне сатып алырга мөмкин булырлык икән. Барына да җитәрлек, ди!

Солдат шунда ук кесәләр һәм биштәрендәге көмешне бушаткан да ике куллап сандыктан алтын акчаларны көри башлаган. Кесәләрен, биштәрен, фуражкасын, итек кунычларын да алтын белән тутырган ул. Шулкадәр төягән ул алтынны, хәтта баскан урынында да көч-хәл белән генә тора икән. Менә хәзер инде чыннан да бай булган ул!

Солдат этне кабат сандык өстенә утырткан, шапылдатып, ишекне япкан һәм, агач төбенә килеп:

— Әй, син, карт убыр, тарт әйдә! — дип кычкырган.

— Тарт әйдә! Таптым чакматашыңны! — дип кычкырган ул убырлы карчыкка.

Убырлы карчык, баудан тартып, солдатны өскә чыгарган.

— Йә, бир минем чакматашны! — дигән убырлы карчык.

— Нигә сиңа чакматаш, карт убыр? — дигән солдат.— Хәзер үк әйт, нигә сиңа чакматаш? Юкса кылычымны суырып чыгарырмын да башыңны чабып өзәрмен!

— Барыбер әйтмим! — дигән убырлы карчык.

Шулчак солдат кылычын суырып чыгарган да убырлы карчыкның башын чабып төшергән, ди. Убырлы карчык егылган һәм шунда ук җан биргән. Ә солдат үзенең бөтен акчаларын, аның шакмаклы алъяпкычына төйнәп, аркасына аскан да туп-туры шәһәргә юл тоткан.

Хәзер инде солдат чын хуҗага әверелгән. Аңа шәһәрдә булган бар могҗизалар хакында да бәйнә-бәйнә сөйләгәннәр. Король белән аның гүзәл кызы — принцесса турында да әйтергә онытмаганнар.

— Ул принцессаны ничегрәк күрергә мөмкин булыр икән? — дип кызыксынган солдат.

— Җиңел эш түгел бу,— дигәннәр аңа.— Принцесса зур бакыр замокта яши, замок исә биек стеналар, таш манаралар белән уратып алынган. Корольнең үзеннән башка берәү дә анда ни керергә, ни чыгарга базмый, чөнки корольгә аның кызына гади солдат хатыны булу язган дип юраганнар. Ә корольнең гап-гади бер солдат белән туганлашып торасы бик килми, әлбәттә. Менә шунлыктан бикләп асрый да инде ул принцессаны.

Принцессаны күрә алмаячагын уйлап, бик уфтанган солдат. Хәер, озак кайгырып та тормаган.

Билгеле инде, солдат, бай булгач, матур киенеп, күңелле яшәгәч, аның дуслары да күбәйгән...

Акчаларын туздырган, туздырган да солдат, көннәрнең берендә күргән — кесәсендә нибарысы ике тәңкә бакыр калган лабаса! Шуннан соң солдатка затлы,

зиннәтле бүлмәләрдән түбә астындагы иң кысан чардакларның берсенә күчәргә туры килгән.

Шулай бер кичне ул үзенең чардагында утыра, ди. Инде караңгы төшеп килә, аның исә шәм алырлык та акчасы калмаган. Убырлы карчыкның чакматашы нәкъ менә шунда исенә төшкән дә инде аның. Солдат чакманы алган да ут чыгара башлаган.

Чакманы чагып җибәрүе булган, бер-бер күзе өй түбәсе кадәрле эт каршысында фәрман көтеп утыра, ди. Эт аңа алтын акчалар ташый башлаган һәм солдат тагын баеп киткән, кунакханәнең иң зиннәтле бүлмәләренә күчкән, затлы киемнәр киеп, кабат көязләнеп йөри башлаган. Элекке дуслары кабат әйләнеп кайткан һәм аны тагын хөрмәтли, зурлый, ярата башлаганнар.

Бервакыт солдатның башына шундый уй килгән: «Нишләп әле миңа принцессаны күрмәскә? Барысы да аны шундый гүзәл дип сөйли... Гомере буена шулай бакыр замокта, биек стеналар белән очлы манаралар артында утырса, аннан ни мәгънә? Йәле, кая минем чакматашым?!»

Менә аның чакматашын чагып җибәрүе булган, каршына әлеге эт килеп баскан.

— Менә нәрсә, акыллым! — дигән солдат.— Дөрес, хәзер инде төн уртасы. Әмма минем принцессаны күрәсем килә. Бер генә минутка монда китер әле шуны. Йә, шагом марш!

Эт шунда ук чыгып югалган һәм, солдат исенә килергә өлгергәнче, кайтып та җиткән. Аркасында йоклаган принцесса ята, ди. Принцесса искиткеч гүзәл икән. Безнең солдат аны үпмичә берничек тә булдыра алмаган. Аннан соң эт принцессаны ничек алып килсә, шулай илтеп тә куйган.

Иртәнге чәй вакытында принцесса король белән королевага бу төндә гаҗәеп төш күрүе хакында сөйләгән: башта ул ниндидер эткә атланып йөргән дә, соңыннан аны ниндидер бер солдат үпкән, имеш.

— Менә сиңа маҗара! — дигән королева.

Бу төш аңа бик үк ошап җитмәгән, билгеле.

Икенче төнне, моның төшме әллә башка берәр нәрсәме икәнлеген тәгаен ачыклар өчен, кызның ятагы янында бер ялчыларын калдырганнар.

Ә солдатның исә тагын гүзәл принцессаны күрәсе килгән. Һәм төнлә белән, нәкъ кичәге кебек үк, бакыр замокка әлеге эт килеп кергән һәм, принцессаны эләктереп, бар көченә солдат яшәгән йортка кабат элдерткән.

Фрейлина карчык та югалып калмаган, дым үткәрми торган итекләрен кигән дә этне куа чыккан. Принцессаны күтәргән этнең зур йортларның берсенә кереп югалуын күреп: «Хәзер инде син безнең кулда, тәти егет!» — дип, йортның капкасына акбур белән зур тәре сурәте төшергән дә тыныч күңел белән өенә йокларга кайтып киткән.

Тик ул юкка гына тынычланган: принцессаны кире илткәндә, эт капкадагы тәрене күреп алган һәм эшнең нидәлеген бик тиз төшенгән. Ул, акбур кисәге табып, шәһәрдәге барлык капкаларга да шундый ук тәреләр ясап чыккан.

Иртә таңнан король белән королева, хезмәтче карчык һәм корольнең барлык офицерлары принцесса төннәрен эт өстендә кая барып йөрүен карарга киткәннәр.

Ләкин кайсы гына капкага барып кагылмасыннар, аларның барысына да тәре сугылган икән. Шулай итеп, алар берни дә майтара алмаганнар.

Әмма королева бик зирәк хатын, каретада йөрергә генә түгел, кирәк чакта эшкә дә, хәйләгә дә оста икән. Ефәктән кечкенә генә матур капчык теккән. Бу капчыкка ул карабодай тутырган һәм аны сиздерми генә принцессаның аркасына бәйләп куйган. Аннан соң принцесса үзенең солдаты янына барганда, ярма азазлап юлга коелып барсын дип, капчыкка бәләкәй генә тишек тишкән.

Төн җиткәч, эт тагын патша сараена очып кергән, принцессаны аркасына утырткан да солдат янына алып чапкан. Ә солдат принцессаны шулкадәр яратып өлгергән икән ки, чын ихластан аңа өйләнергә тели, ди. Принц булып алу да комачауламас, дип уйлаган, билгеле.

Эт бик тиз чапкан, капчыктагы ярма исә бакыр замоктан алып солдат торагына кадәр юл буена коелып барган. Ләкин эт берни дә сизмәгән.

Иртән король белән королева сарайдан чыкканнар, юлга караганнар һәм төннәрен принцессаның кая китеп югалуын шунда ук төшенеп тә алганнар. Солдатны тапканнар да төрмәгә япканнар.

Озак утырган солдат рәшәткә артында. Төрмәдә караңгы һәм күңелсез икән. Һәм көннәрдән бер көнне төрмә сакчысы солдатка:

— Иртәгә сине асачаклар! — дигән.

Икенче көнне иртән солдат кечкенә тәрәзә янына килгән һәм рәшәткә аша урамны күзәтергә керешкән. Халык төркемнәре, өерелеп, шәһәр читенә ничек итеп солдатны асуларын карарга ашыга. Барабаннар кагалар, саф-саф булып гаскәрләр уза. Һәм төрмә яныннан гына, тыраклый-тыраклый, яланаякларына туфли кигән, күн алъяпкычлы итекче малай йөгереп килә икән. Кинәт аның бер туфлие аягыннан ычкынып киткән дә солдат басып торган рәшәткәле тәрәзә янындагы стенага килеп бәрелгән.

— Һәй, егеткәй, ашыкма! — дип кычкырган солдат.— Мин монда бит әле, ә минсез анда берни дә булмаячак. Ә менә син тиз генә минем өйгә барып, чакматашымны алып килсәң, мин сиңа аз да түгел, күп тә түгел, дүрт көмеш тәңкә бирер идем! Йә, тизрәк кыймылда, бер аягың монда, икенчесе тегендә булсын!

Малай дүрт көмеш тәңкәле булуга каршы килмәгән, билгеле, һәм ул чакматаш артыннан ук булып очкан, күз ачып йомганчы аны солдатка китереп тә биргән һәм...

Моннан соң тагын ниләр булганын тыңлагыз әле менә.

Шәһәр читенә зур гына дар агачы куелган икән. Аның тирәсенә гаскәрләр тезелгән, җыелган халык шаулашкан. Король белән королева вәкарь белән[1] зиннәтле тәхетләрдә утыра, ди. Каршы якка хөкемдарлар белән бөтен дәүләт советы урнашкан. Менә солдатны баскычка менгергәннәр, палач аның муенына элмәк ташларга җыенган.

Әмма шулчак солдат аз гына сабыр итүләрен үтенгән.

— Рөхсәт булса, мин трубка көйрәтеп алыр идем,— дигән ул.— Гомеремдә иң соңгы тартуым булачак ул минем.

Ә бу илдә шундый йола яшәп килә икән: үлемгә хөкем ителгән кешенең соңгы теләге үтәлергә тиеш, бик җитди теләк булмаса инде.

Шунлыктан король солдатка берничек тә каршы килә алмаган. Менә солдат авызына төрепкәсен капкан, менә үзенең чакматашын алган һәм ут чыгара башлаган.

Бер тапкыр чаккан ул чакманы, ике, өч тапкыр чаккан, һәм аның алдына өй түбәсе кадәр күзле эт килеп баскан.

— Йә әле, элмәктән котылырга булыш әле миңа! — дип боерган солдат.

Эт шунда ук хөкемдарлар һәм дәүләт советы өстенә ташланган: берсен аякларыннан, икенчесен борыннарыннан эләктерә дә һавага шундый итеп чөя, җиргә төшкәч, юеш урын гына кала тегеләрдән.

Эт король белән королеваны да икесен берьюлы күккә чөеп җибәргән.

Моны күргәч, гаскәрләрнең коты чыккан, ә халык кычкырырга керешкән:

---

[1] Вәкарь белән — җитди, үз дәрәҗәсен белеп.

— Яшәсен солдат! Гүзәл принцессаны үзеңә хатынлыкка ал да безнең королебез бул, солдат!

Солдатны король каретасына утыртканнар да король сараена алып киткәннәр. Эт карета алдыннан юл буена биеп, «ура!» кычкырып барган. Малайлар сызгырганнар, гаскәрләр честь биреп калганнар. Принцесса, ниһаять, бакыр замоктан чыккан һәм королева булган.

Туй тантанасы атна буе дәвам иткән.

Биремнәр

1. Әкиятне вакыйгаларга бүлеп сөйләгез.
2. Ике генә өлешкә калдырып гомумиләштерегез.

Хәсән Туфан

Ялкау, Иренчәк һәм Кире турында әкият

Борын заманда торган
Бер авылда өч туган:
Берсе кире, берсе ялкау,
Берсе иренчәк булган.

Ялкау сузыла, киерелә,
Иренчәге иренә,
Киресе кушкан эшнең
Барысын эшли кирегә.

Әтиләре аларга
Бик әйбәт йорт салдырган,
Әниләре бик күп итеп
Камыр басып калдырган.

Карт әйткән: «Сез шул өйдә
Тыныч кына яшәрсез».
Карчык әйткән: «Шул камырдан
Ипи пешереп ашарсыз».

«Безгә вакыт җитте»,— дип,
Икесе дә үлгәннәр,
Ялкау туганнар аларны
Иренә-иренә күмгәннәр.

Өйгә ягылган булган,
Өскә ябынып зур юрган,
«Әйдә, йоклап алабыз»,— дип,
Сузылып яткан өч туган.

Йоклап туйгач, туганнар
Өч көннән соң торганнар;
Ипи пешерү турында бик
Озак киңәш корганнар.

Ялкау сузыла, киерелә,
Иренчәге иренә,
Алар иренгәнгә күрә
Иренә, ди, Кире дә.

Болар өч көн талашкан,
Карыннары да ачкан.
Камыр әчеп, ташып аккан
Ләгән чаклы табактан.

Агып барып бер читтән
Ишеккә барып җиткән,
Ишек кинәт ачылып киткән!
Суык кергән ишектән.

Элек кергән баласы,
Бераздан соң анасы,
Аннан соң кергән суыкның
Ак сакаллы бабасы.

Кире, Ялкау туганнар,
Бабай кергәч, туңганнар,
Чыдый алмыйча суыкка,
Сикерешеп торганнар.

Бабай болардан сорый:
«Бии беләсезме? — ди,—
Белмәсәгез бик әйбәтләп
Өйрәтәм мин сезне»,— ди.

Чыдый алмый өч туган:
«Биибез!» — дип кычкырган.
Бияләен шапылдатып,
Бабай кул чабып торган.

Тыпыр-тыпыр биегәндә
Кул чабакларга кирәк,
Җылынып булмый биеп кенә,
Мичкә ягарга кирәк.

Мич астыннан ялкаулар
Чыбык-чабык тапканнар,
Мичләренә якканнар да
Тагын сузылып ятканнар.

Йоклап туйгач, туганнар
Өч көннән соң торганнар.
Мич сүрелгән, өй суынган,
Ачыкканнар, туңганнар.

Өчесе дә ишектән
Бәхет кергәнне көткән;
Йөзен чытып, кашын җыерып,
Ачлык кергән ишектән.

Ачлык бик усал булган,
Эчләрен чеметеп борган,
Чыдый алмыйча, өч туган:
«Үләбез!» — дип кычкырган.

Аларның тавышын читтән,
Әллә инде ишеткән,
Җиңен сызганып, елмаеп,
Хезмәт кергән ишектән.

«Әнә,— диган,— тегендә,
Сезнең ишек төбендә
Үлем чират тора,— дигән,—
Сезнең янга керергә.

Әгәр дә сез бүгеннән
Тырышып чын күңелдән
Эшләсәгез, сезне,— дигән,—
Коткарам мин үлемнән».

«Әйдә,— дигән,— туганнар,
Киттек хәзер урманга.
Кире, син дә бар,— дигән ул,
Балтаң, пычкыңны ал да...»

Бирем

Ялкауны, Иренчәкне кем яратсын, Кире белән кем дус булсын! Автор өч туганны кызганамы, алардан көләме, нәфрәтен белдерәме әллә шул өч туган мисалында безгә ни дә булса әйтергә телиме?

Әсәрен язар алдыннан автор болай уйлаган: «Ялкау, иренчәк, кире балалар үзләрен читтән торып күрә алмыйлар. Күрә алсалар, башкалар алдында нинди көлке хәлдә калуларын белерләр иде. Яман гадәт, бик кечкенә генә булса да, читтән бик зур булып күренә. Яман гадәтнең кешеләрне нинди кызганыч хәлгә китерүен, нинди ямьсез булуын болай да беләбез. Ялкау, иренчәк, кире балалар билгеле инде, безнең арада юк та, була да алмый. Шуңа күрә Хәсән Туфан әкиятен андагы персонажлардан көлә-көлә дәвам итегез. Туганнарга тагын, тагын эш табыгыз. Эшләсеннәр».

Данис Хәбибуллин

Эләкте

Елга буенда
Кармак салабыз,
Әледән-әле
Тартып алабыз.

Җиме дә яхшы,
Белмибез генә:
Балык дигәнең
Эләкми нигә?

Шулвакыт энем
Әйтте дә салды:
— Кулмәкләр белән
Тотыйк без аны.

Инде икәүләп
Суда йөзәбез,
Кулмәкләр белән
Балык сөзәбез.

Ләкин ни хикмәт,
Үч иткән кебек,
Сыңар балык та
Эләкми килеп.

Ә вакыт уза,
Инде кич була,
Киемнәребез
Манма су гына.

— Бүгенгә җитәр,
Кайтыйк,— ди энем.
— Сабыр ит, бәлки,
Эләгер,— дим мин.
Ничек соң шулай
Дөрес әйтелгән:
Кичен эләкте...

Биремнәр

1. Катнашучыларны санап чыгыгыз.
2. Төп катнашучыларны табыгыз. Малай белән энесеме? Малай белән балыкмы? Балык белән җимме? Кармак белән балыкчылармы? Әллә башкачамы?
Шигырьне дәвам итегез.

Шәрәф Мөдәррис

Сукыр лампа

Сугыш тынса, көйри-көйри йөрәк!
Читен дә соң, читен кайвакыт...
Сукыр лампа дөрли төтәп-төтәп,
Ялкын телен читкә чайкатып.
Үткән юллар, узган сугышларны
Уйлый-уйлый хискә чумганда,—
Рәхәт тә соң шунда, сукыр лампа
Яктыртучың, нурың булганда!
Төтеннәрен күпме төтәтмәсен,
Сөремнәрен күпме сипмәсен,—
Сукыр лампа минем көрәштәшем

Саклаганда яктым чишмәсен!
Матур ал таң көнне тудырганчы
Янсын шулай минем каршымда —
Иптәш безгә газиз сукыр лампа
Землянкада, төнге салкында.
Сугыш тынар иркен канлы кырда,
Дөнья тагын нурга капланыр!
Сукыр лампа минем сандыгымда
Ядкәр булып һаман сакланыр!

1943 ел

Биремнәр

1. Шигырьне бүлү өчен, нигез итеп, заманны алыйк. Әсәрне үткән, бүгенге һәм киләчәк заманнарга бүлегез.
2. Үткән заманга караган өлешләрен үз сүзләрегез белән аңлатыгыз.
3. Шигырь язылган вакытка караган өлешендәге «Сукыр лампа минем көрәштәшем / Саклаганда яктым чишмәсен!» юлларын үз сүзләребез белән болай аңлатыйк: сукыр лампа күңелем тулы хәсрәт арасында сүнми калган шатлык хисен саклап калырга булышты.
Хәзер шуны башкача әйтик: сукыр лампа иң авыр вакытларда минем юанычым булды.
Бу өлештә тагын нәрсә әйтелә?
4. Киләчәк заманга караган өлешне дә үз сүзләрегез белән сөйләгез.
5. Сукыр лампа караңгы, салкын окопта яктылык бирүче генә түгел. Ул сугышчыларга башка яктан да кадерле. Ни өчен сөремле, исле, ава-түнә янучы сукыр лампа татар сугышчысын юата алырлык көчкә ия? Уйлап табыгыз.

Шәрәф Мөдәррис турында

Шәрәф Мөдәррис (1919—1963) — Бөек Ватан сугышының башыннан ахырына кадәр катнашкан шагыйрь. Баштан минометчы булып сугыша, аннан соң фронт газеталарында хезмәт итә.

Шулай ук авыр сугыш юлы үткән профессор Хатип Госман шагыйрь белән бер үк газетада эшли. Шәрәф Мөдәррисне ул менә ничек искә ала:

«Газетага кирәкле җанлы материалны без ут эченнән кереп алабыз.

Шәрәф уттан-нидән курыкмый. Тәҗрибәле солдат. Бер-ике атнага югала. Берзаман ишек ачылып китә дә, Шәрәф килеп керә: сакал-мыек баскан, өс-башы карарлык түгел — кер. Ул таушалып беткән шинеленә нәрсә генә сыланмаган да, нинди генә балчык катмаган, башында пилотка түгел, әллә нинди гөмбәгә охшашлы бернәрсә, ә иңендә каешланып беткән солдат капчыгы, ул бик буш күренә. Ләкин соңрак мәгълүм була: капчыкта бер кыерчык икмәк булмаса да, актара башлагач, аннан тузып беткән блокнот кисәге, дәфтәр калдыгы, ниндидер ташландык китап бите чыга. Аларның һәммәсендә дә Шәрәфнең үзе генә таный ала торган язмалар. Берничә сәгать үтүгә, шуннан туа башлый инде ут бөркеп торган хәбәрләр, очерклар, шигъри парчалар!..

Ул ишек катындагы почмакка посып утыра да тезенә каты нәрсә куеп (бусы — «өстәл») язарга керешә. Проза язса, мыштым гына эшли. Шигырь булса пышылдый. Ул кайчакта сәгатьләр буе үз зиһене, үз күңеле белән сөйләшеп утыра...

Шәрәф солдат тормышының бөтен якларын да үз язмышында кичереп үтте. Шуңа күрә аның әсәрләрендә солдатның чын үз рухи дөньясы ачыла барды: ул аны шигъри табигатьле, нечкә күңелле чын кеше итеп күрсәтте».

«Сукыр лампа» шигыре дә шундый шартларда үз күңеле белән пыш-пыш сөйләшеп язылган дия алабыз. Бу шигырьдә, чыннан да, «солдатның чын рухи дөньясы»н күрү кыен түгел.

Мөхәммәт Гали

Габдулла Тукай белән күрешүем

1911—1912 елларда мин Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укыдым. Шунда укыганда, без иптәшләр белән хәлфәләрдән качып-посып кына «Шәрык клубы»на һәм янган шәһәр театрына спектакльләргә йөри идек. Шул вакытта мин бер-ике тапкыр читтән генә Тукайны күрдем. Беренче тапкыр миңа иптәшләр антракт

вакытында «Шәрык клубы»ның фойесында кыска буйлы, чандыр гәүдәле, бөдрәрәк җиткән чәчле яшь бер егетне, «Менә Тукай шул инде» дип, читтән төртеп күрсәттеләр. Ул Фатих Әмирхан коляскасы[1] янына җыелган яшьләр белән көлеп сөйләшеп тора иде. Аның өстендә ябык якалы кыска тужурка, аяк йөзенә үк төшеп торган озын тар чалбар, аягында тәбәнәк үкчәле, балтырыннан тотып кия торган шнурсыз резинлы ботинка иде. Без аны иптәшләр белән антракт беткәнче читтән карап тордык.

Икенче тапкыр без аны антракт вакытында театр фойесында кешеләр белән йөргәндә күрдек. Ләкин таныша алмадык.

Минем белән бергә мәдрәсәдә укучы шагыйрь Габдулла Харис, үзенең язган шигырьләрен укып консультация алу өчен, Тукайның номерына баргалап йөри иде. Тукай белән танышасым бик килгәнгә, алып барып таныштыруны аннан үтенергә туры килде. Кешегә әйтмәү шарты белән, бер барганда ул үзе белән мине дә ияртеп барды.

Без барганда, «Болгар»ның өченче катында Тукай тора торган 41 нче номерның ишеге ярык кына булып ачылып тора иде. Г. Харис шакылдатмый-нитми ишекне зуррак ачып башын тыкты да:

— Мөмкинме, Габдулла әфәнде? — диде.

— Ә, синмени әле бу, Харис? Әйдә кер! — дигән тавыш ишетелде эчтән.

Ишекне яртылаш ачып, ул кереп китте, мин ишек төбендә калдым.

Бераз торгач, Харис:

— Минем бер иптәшем дә бар иде әле анда,— диде.

— Кая соң ул, ник әйтмисең аңа, керсен,— диде Тукай.

---

[1] Аяклары йөрмәгәнгә Фатих Әмирханны коляскага утыртып, малайлар этеп йөртәләр иде. *(М. Гали искәрмәсе.)*

Харис, ишектән башын тыгып, мине чакырып алды.

Бер кровать, бер-ике урындык сыярлык кечкенә генә бүлмә. Ашъяулык япкан өстәл, җыелмаган кровать һәм ишек янындагы чөйгә элгән кыска сөлге белән вак-төяк киемнәр һәм ике урындыктан башка бүлмәдә бер җиһаз да юк.

Без килгәндә, Тукай яткан булган икән. Мин кергәндә, ул, яңа урыныннан торып, өстенә ябынып яткан пальтосын чөйгә элеп маташа иде. Тужуркасын иңбашына салып, урынын рәтләп куйды да:

— Мәдрәсәдәшме? Шәрик[1] үкме әллә? — дип, Хариска карап алып, минем белән күреште.

— Ул миннән бер сыйныф түбән, мин игъдади өчтә[2], ул игъдади икедә укый,— диде Харис.

— Син дә шигырь язмыйсыңдыр бит? — диде Тукай, миңа карап.

— Юк, Габдулла әфәнде,— дидем мин.

— Ярый әле андый гөнаһың юк икән. Менә Харис сабагын да укымый, кыш буе шуның белән саташып йөри бит,— диде көлеп Тукай.

— Алай дәрес ташлап ук йөргән юк ла, Габдулла әфәнде. Менә Мөхәммәт белә инде минем ничек укыганны,— диде Харис, миңа күрсәтеп.

— Юк, сине, малай, начар укый, диләр, ялкауланасың, ди. Алай ярамый бит ул. Русча да бер дә белмисең бугай син? Частный урок алып булса да, русча укырга кирәк. Болай синең каләмең өметле генә күренә. Укымасаң, рәт чыкмас бит, малай,— диде Тукай.

Харис башын иеп дәшми торгач, ул, тагын өстәп:

— Пушкинның берәр шигырен булса да русча оригиналыннан укыганың бармы синең? — диде.

— Бар,— диде бик әкрен генә Харис.

— Ай-һай, бик әкрен әйтәсең, укыганың юктыр. Ичмаса, тәрҗемә аша булса да мәшһүр рус шагыйрь-

---

[1] Шәрик — хәзер «сыйныфташ» дияр идек.

[2] Игъдади сыйныф — ул чактагы югары сыйныфлар.

ләренең әсәрләре белән танышырга кирәк, шунсыз рәтле шигырь язу буламыни ул,— диде Тукай.

Шул арада ишектән без белмәгән ике кеше килеп керделәр дә, без урыннарыбыздан кузгалып аларга урын бирдек. Тукай безгә үзенең кроватена утырырга әйтсә дә, без утырмадык.

Күрешеп чыкканда, Тукай безгә:

— Тагын килегез шулай. Мин әйткәнгә үпкәләмә син, Харис! Минем шундый турырак әйтә торган гадәт бар. Һәрвакыт килеп йөр! — дип калды.

Без чыгып киттек. Шуннан соң мин Тукайны күрә алмадым.

Биремнәр

1. Матур-матур хикәяләр авторы Мөхәммәт Гали бу истәлегендә Габдулла Тукайның кыяфәте, торган җире, холкы турында яза.
Шул сыйфатлар турында төкми-чәчми тулы итеп сөйләргә тырышыгыз.
2. Мөхәммәт Гали күргән-белгәнен генә яза, шагыйрьгә бәясен бездән таптыра. Шагыйрьгә бәяне мин язган сыйфатлардан табыгыз, ди. Шулай итегез.

Нәҗип Мадьяров

Имән

Бар агачлардан да шәбрәк
Үскән баһадир имән,
Югыйсә ул да ныклыкны
Алган шушы ук җирдән.

Бирем

Бу шигырьдә имән кешегә метафора булып килә. Димәк, әсәрнең бер өлеше — имән, икенче өлеше кеше турында. Автор имән турында яза, үзе бездән: «Метафора гына ул имән. Кешеләргә метафора. Мин нинди кешеләр турында яздым?» — дип сорый. Шул сорауга җавап бирегез.

Әхәт Дибаев

Дәрестән соң

(Хикәя)

Равил мәктәптән кайткач ашап-эчте. Тимераякларын тагып, урамга чыкты. Тирә-ягына каранып алды. Якын-тирәдә милиционерлар күренмәгәч, кузгалып китәргә торган автобус артына ябышты да шуып китте. Әкрен генә кузгалган автобус, бара торгач, йөрешен кызулатты. Бу кызулыктан Равилнең хәтта сулышы кысыла башлады. Аяк астыннан бөтерелеп кар тузаны күтәрелде.

Киләсе тукталышта автобус йөрешен әкренәйткәч, Равил кулларын ычкындырды, юлның икенче ягына шуып чыкты һәм каршысына килгән йөк машинасын күрми калды.

Кинәт, җир астыннан калкып чыккандай, машина алдына килеп баскан баланы күргәч, зур тәҗрибәле шофер да каушап калды. Чөнки шактый кызулык белән килгән машинаны туктатырга соң иде инде. Читләтеп узарга мөмкин түгел — сул якта автобус тора, ә уңда тротуар, баганалар, кешеләр...

Равилнең гомере кыл өстендә иде. Шоферның башыннан, яшен тизлеге белән «Нишләргә?» дигән уй узды. Шунда ул бөтен гәүдәсе белән рульгә ятты һәм, барлык көчен җыеп, машинаны кинәт тротуарга борды. Машина дөп итеп баганага килеп бәрелде. Шофер бераз вакыт кабинасыннан чыга алмый торды. Ә моның сәбәпчесе Равил исә, коты очып, алдына-артына карамыйча чабып китте.

Икенче көнне мәктәпкә килгәндә Равилнең күңеле тыныч, кәефе яхшы иде. Кичәге вакыйганы ул исенә дә төшермәде, әйтерсең кичә бернәрсә дә булмаган. Менә ул, өстен чишенеп, сыйныф бүлмәсенә кереп утырды. Күп тә үтми, звонок шалтырады. Җиденче «Б» сыйныф укытучысы Мәрьям апа кереп, балаларны барлап чыкты да дәресне башлап җибәрде.

— Йәгез, балалар! — диде ул.— Бүген без үтелгән дәресне, «Диңгезләр» темасын кабатларга тиешбез, кем сөйләргә тели?

Барысы да дәррәү кулларын күтәрделәр.

— Сөйлә, Равил! — диде укытучы.

Сыйныф тынып калды. Равил диңгезләр һәм андагы тереклек турында укытучыдан ишеткәннәрен, дәреслектән укыганнарын тулы һәм ачык итеп сөйләп бирде һәм ахырда:

— Кара диңгезнең суы,— диде,— йөз илле, ике йөз метр тирәнлектән башлап күкертле водород белән агуланган, шуңа күрә ул түбәнлектә тереклек юк. Ә менә Азов диңгезе аңа караганда ун тапкыр кечерәк һәм бер йөз җитмеш мәртәбә сайрак булса да, балык Азов диңгезендә күбрәк. Азов диңгезе балыкка байлыгы ягыннан бөтендөнья күләмендә беренче урында тора...

Укучылар колакларын шәмрәйтеп... «Карале, нинди кызык нәрсәләр сөйли, боларның барын да каян белә бу?» — дип гаҗәпләнеп утырдылар.

Равил сөйләп бетергәч, укытучы, балаларга карап:

— Равил дөрес сөйли, бу турыда Карелинаның «Безнең илебезнең диңгезләре» исемле китабында матур һәм аңлаешлы итеп язылган. Барыгызга да бу китапны укып чыгарга тәкъдим итәм,— дип, Равилгә «биш»ле билгесе куйды.

Зур тәнәфес вакытында Равил коридорда бер төркем иптәшләренең ни турындадыр кызу-кызу сөйләшеп торганнарын күрде һәм алар янына килде.

— Хәзер инде әтине эштән чыгаралар,— диде почык борынлы Сәлим, күңелсезләнеп.

— Нәрсә булды, ни өчен? — дип сорады Равил.

— Әй, шул сезнең урамда инде. Кичә тимераякта шуган бер малай машина астына килеп керә язгач, Сәлимнең әтисе машинасын тротуарга борган икән, машина баганага бәрелгән дә ватылган. Хәзер инде аңа: «Син машинаны исерек баштан ваткансың, сине эштән чыгарабыз»,— дип әйтәләр, ди...

— Ә теге малай үзе качкан. Кем белә, бәлки ул син булгансыңдыр,— дип өстәде икенчесе.

Кыек атып туры тигән сүздән Равил кинәт әсәрләнеп китте, кемдер авызына суккан төсле булды.

Әгәр шулвакыт иптәшләре аңа игътибар белән караган булсалар, Равилнең ничек үзгәргәнен күргән булырлар иде. Ләкин Сәлимнең кайгысын уртаклашу белән мавыгып, алар Равилгә карамадылар. Ул арада звонок шалтырады һәм балалар сыйныфка юнәлделәр.

Равилнең күңелен борчу басты.

Сәлимнең әтисен эштән чыгаралар дигән тынгысыз уй, өйгә кайткач та, бер генә минутка да башыннан китмәде. Равил йөрәгенә ул авыр таш булып ятты. Бу бәйләнчек уйлардан арынырга теләп, дәрес хәзерләргә утырды. Ләкин нихәтле тырышып караса да, укыганы башына кермәде. Укыса да, язса да, хәтта уйнаса да аның күз алдында әлеге машина һәм Сәлимнең әтисе булды. Ничек кенә булса да, гаепсез шоферга ярдәм итәсе килде аның. Ә ничек? Моны уйлап таба алмады.

Ахырда Равил йокларга ятты. Тик, башка вакыттагы шикелле, мендәргә башын кую белән йокыга китә алмады. Әле бер, әле икенче ягына әйләнеп, бик озак аунап ятты. Йокыга киткәч тә, йокысы тыныч булмады. Төшендә әллә нинди машиналар, атлар, кешеләр күреп саташып чыкты.

Иртәгесен Равил мәктәпкә иртәрәк килде. Аның һәрвакытта да шат күренгән йөзе бүген уйчан иде. Ул, тиз генә чишенеп, сыйныф бүлмәсенә керде дә күзләре белән Сәлимне эзләде. Сәлим әле килмәгән иде. Равил аны түземсезлек белән көтә башлады. Күп тә үтми, Сәлим дә килеп керде. Равил, аны күрү белән:

— Сәлим, кил әле, бер сүз әйтәм! — диде. Сәлим ашыкмый гына аның янына килеп басты.

— Кара әле,— диде Равил, җитди төс белән,— синең әтиең кайда эшли?

— Әй, сиңа нигә кирәк ул? — диде Сәлим, кул селтәп.

— Әллә әтиеңнең кайда эшләгәнен дә белмисеңме?

— Нишләп белмим, ди, баламыни мин,— диде Сәлим һәм этисенең кайда эшләгәнен әйтеп бирде.

«Барырга. Бүген үк Сәлимнең этисе эшләгән җиргә, директорына барырга да әйтергә»,— дип уйлады Равил. Аннары: «Ә нәрсә дип әйтергә? Минә минем аркада Сәлимнең этисе машинасын ватты, дияргәме? Әгәр дә бу эш этигә ишетелсә, мәктәп белсә? Моның өчен бит баштан сыйпамаслар. Әллә бармаскамы, беркем дә белми ич...»

Дәрестә Равилне «Барыргамы, юкмы?» дигән уй газаплады. Дәрес сәгатьләре бик әкрен узган сыман тоелды. Хәтта тәнәфес вакытларында да ул әүвәлге шикелле уйнап, шаярып йөрмәде.

Ниһаять, дәресләр бетте. Тиз генә киенде дә урамга чыкты.

Тышта чатнама суык. Кышкы зәһәр салкын битләрне чеметә һәм сулыш алганда тамакны кытыклый, тырный, тынны кыса.

Равил ашыга-ашыга трамвай тукталышына килде һәм вагонга кереп утырды, йөрәге белән ул никадәр алга омтылса да, вагон көпчәкләре бүген нигәдер башка көндәге кебек җитез тәгәрәмиләр шикелле иде. Салкыннан зарлангандай, шыгырдап, ыңгырашып, теләр-теләмәс кенә әйләнәләр.

Равил, трамвайдан төшеп, трест конторасын эзләп китте. Ишек читенә «Трест» дип язылган бина ишеген ачып, эчкә узды. Директор кабинетын да эзләп тапты. Ләкин ишек төбендә туктап калды. Хәзергә кадәр ташып торган кыюлык кинәт югалды. «Нишләргә? Ничек керергә? Нәрсә булыр икән? Әллә керми генә кире кайтып китимме?» — дип уйлана башлады. Аннары: «Юк, җебеп торма, Равил, бар, кер!» — диде үзенә үзе һәм «Кер!» дигән фәрманы җиңде.

Кабинет ишеген әкрен генә ачып, эчкә керде һәм өстәл артында утырган таза гәүдәле бер абый каршысына килеп басты.

— Исәнмесез, абый!

— Саумы, энекәш, ни йомыш? — диде директор.

Равил, сүзне нәрсәдән башларга белмичә, бер директорга, бер кулындагы бүрегенә карап торды. Аннары бөтен кыюлыгын җыеп:

— Бари абыйны эштән чыгармагыз, директор абый! — диде дә, башын түбән иеп, аяк очларына карап тора башлады.

Директор каршысында басып торган соры күзле, киң кара кашлы бу малайга сәерсенеп карады.

— Нинди Бари ул?

— Сәлимнең этисе инде, Бари абый... Сөләйманов... шофер ул,— диде Равил, кабалана-кабалана.

— Ә, Сөләймановмы? Әйе, менә приказга кул куярга торам. Ник сорыйсың, син аның кеме?

— Директор абый, аның гаебе юк ич. Мин... Минем аркада ул...— диде Равил, ишетелер-ишетелмәс кенә. Үзе куркудан һәм оятыннан колак очларына хәтле кызарды һәм барысын да сөйләп бирде.

Аны тыңлап утырган директорның йөзе бер яктырды, бер караңгыланды. «Һм... Эх син, иптәш укучы,— диде директор, шактый шелтәле тавыш белән,— менә ничек икән эле, менә кем икән... инде хәзер исәпләп кара: машинага ремонт күпме тора һәм шушы вакыт эчендә күпме эш башкарылган булыр иде. Ә машина борылып өлгермәгән булса?..»

Равил дәшмәде. Ул хәзер эссе мунча ләүкәсендә парланганнан бер дә ким түгел иде: бит урталары яна, яңаклары буйлап тир ага.

Бүлмәдә күңелсез тынлык урнашты.

Директор телефон трубкасын алып кирәкле номерны җыйды да:

— Гаражмы? Иптәш Сөләймановны чакырыгыз әле! — диде.

Ул инде ватылган машинага ремонт ясауны Сөләймановка тапшырырга дигән карарга килгән иде.

Алтын бабай

Алтын бабай турында сезнең дә ишеткәнегез бардыр, бәлкем. Безнең авылда аны һәркем белә. Әле бик нәни чагымда ук Алтын бабайның безнең урамнан узганын күзәтә идем. Ул уң кулына тоткан имән таягын юлдагы ташларга яки коймаларга так-ток итеп бәрә-бәрә йөри. Мин бервакытны:

— Бабай, бабай, сез нигә таяк белән урамдагы ташларны санап йөрисез? — дип кычкырган идем, аны әнием ишеткән. Әй, орышты да соң үземне: «Нигә бабаңнан көләсең, аның бит күзләре бөтенләй күрмиләр, кулына тоткан шул таяк белән кармаланып кына йөри ала ул».

— Әни, әни, нигә соң аның күзләре күрмиләр? — дип сорадым мин.

— 1914 елда немецлар безгә каршы сугыш башлаганнар, йортларны яндырганнар, кешеләрне үтергәннәр. Безнең авылны, күрше авылларны һәм безнең башка җирләрне саклау өчен, Алтын бабаң да сугышка киткән. Ул чагында тап-таза, яшь-яшь егет булган. Немецлар газ җибәреп аның күзен сукырайтканнар,— дип, әни миңа аңлатып бирде. Сезнең юри генә сукыр булып караганыгыз бармы? Менә мин күзләремне кысып йомам да бер бүлмәдән икенче бүлмәгә чыкмакчы булам. Берни күренми, кап-караңгы. Аякка урындык бәрелә. Мин сөртенеп егылам. Кинәт күзләремне ачып җибәрәм. Менә мин яңадан кояшны, әнине, әбине, бүлмәне күреп шатлыгымнан нишләргә белмим... Ләкин шунда минем күз алдыма имән таягын тоткан Алтын бабай килеп баса. Ул мескен мәңгегә сукыр. Аңар зәңгәр күк тә, кояш та, яшел агачлар да, үләннәр дә, төрле-төрле чәчәкләр дә, безнең авыл да күренми. Күз алдында гел караңгылык, караңгылык...

Алтын бабай — зур гәүдәле, инде карт булуына да карамастан, таза кеше. Аның алтын сакалы кояш нур-

ларында җем-җем итә, әллә кайдан күренеп тора. Шуңар күрә аны Алтын бабай дип атаганнар да. Ул өстенә ап-ак кием, башына зур салам эшләпә киеп йөри. Алтын бабай һәр көнне диярлек безнең янга балалар бакчасына килә. Ул безгә алма, чия, җиләкләр һәм кечкенә корзинкалар алып килә.

Аның таяк тавышын без еракта ук ишетәбез һәм аны каршы чыгып алабыз. Ул безнең барыбызны да белә. Беребезне кочаклый, икенчебезне үбә. Без биибез, сикерәбез, ә Алтын бабай безнең биегәнне күрә алмый бит. Ә шулай да: «Сания, Сания, нигә бер ягың белән генә сикерәсең?» — дип дәшә. Ничек соң ул үз тирәсендә тыраклап йөргән Санияне белә?..

Мин җырлый башлыйм. Алтын бабай миңа: «Бигрәк тә яхшы җырлыйсың инде, Зөлфә»,— ди. Ничек соң ул җырлаучының мин икәнен белә?.. Мин аптырыйм. Алтын бабайга һәр аяк тавышы, һәрбер тамак кыру, һәрбер көлү таныш, ахрысы. Ул безнең аны һәр яктан әйләндереп алуыбызны сизә дә, урындыкка утырып, берсеннән-берсе кызыграк әкиятләр сөйли башлый.

Беркөнне, аның тезенә утырып, кечкенә Әнвәр:

— Бабам, бабам, сукыр булу бик уңайсыз түгелме? — дип сорап куйды.

— Элек заманда бик уңайсыз иде. Хәзер минем турыда барысы да кайгырталар. Зурлар һәм сез, балалар, һаман да минем белән. Биегез, җырлагыз, уйнагыз, ләкин тәүфыйклы, тәртипле булырга, укырга онытмагыз. Әгәр сез шулай эшләсәгез, мин һәрвакыт шат булырмын,— диде Алтын бабай. Без барыбыз да аны кочакладык, ап-ак битен, алтын сакалын үптек.

Көннәр бер-бер артлы уза тордылар. Ләкин менә инде үткән атнадан бирле Алтын бабайның безнең яныбызга килгәне юк. Без бабакайны бик сагындык. Нигә килми икән соң ул?.. Авырый микән әллә?.. Ул безне бик сагынгандыр. Алтын бабай янына үзебез барыйк, хәлен белик, ярдәм итик, диештек. Без Алтын

бабай янына киттек. Ул авыл читендәге күл янында тора икән. Бик зур җиләк-җимеш бакчасы бар. Без, төрле-төрле чәчәкләр белән бизәлгән юллардан бара торгач, һәр яктан зур-зур имәннәр белән уратылган нәни генә сап-сары йорт янына килеп чыктык. Безне, «һау-һау» дип өреп, бик зур ап-ак эт каршы алды. Өй эченнән:

— Кем бар анда, кем бар?.. Акбай, тимә!..— дигән тавыш ишетелде. Бу — Алтын бабай тавышы иде. Без, шаулаша-шаулаша, ачык ишектән эчкә атылдык. Ләкин талчыбыкларыннан үреп эшләнгән урындыкта утыручы Алтын бабайны һәм аның тезе өстендә 5—6 яшьлек ниндидер кызчыкны күреп, бик аптырап калдык. Зур зәңгәр күзле, сары чәчле, түгәрәк битле кызчык бабакайның тоныкк күзләренә елмаеп карап тора иде.

— Килдегезме, минем акыллыларым?! — диде Алтын бабай, безгә кулын болгап.— Нигә тынып калдыгыз?.. Карагыз, карагыз, сеңлегезне күрегез...

— Кем соң ул?.. Нинди кыз?..— дип, без яңадан шаулаша башладык.

— Ул — бабагызның күзләре,— дип елмаеп куйды Алтын бабай һәм, безнең берни дә аңламавыбызны сизеп, салмак кына сөйли башлады:

— Ул ятим кыз — Тамара. Аның әнисен немец илбасарлары яндырып үтергәннәр. Ул анасыз, атасыз калган. Аны минем янга солдат улым сугыш барган җирдән алып кайтты. Без аның анасы да, атасы да булырбыз. Ул миңа бөтен күргәннәрен, илебезнең матурлыгын сөйләп торыр, ул минем нурлы күзләрем булыр... Ә сез, балалар, аның апалары, абыйлары булырга ризамы?

Без Алтын бабайның «яңа күзләр»енә — нәни Тамарага карадык. Безнең кадерле анабыз, атабыз, туганнарыбыз бар, ә Тамараның беркеме дә юк бит. Без:

— Әйе, ул безнең сеңлебез булсын, кадерле бабабыз,— дип җавап бирдек.

«Яңа күзләр», нәни Тамара, Алтын бабайның мөлаем йөзенә һаман элеккечә елмаеп карап тора.

1945 ел

Бирем

Хикәяне укыганда сезнең күңелегездә кызгану хисе уянды. Ләкин ул соңыннан үзгәрде. Ике төрле хисегезнең сәбәпләрен әйтегез.

Габдулла Тукай

Ятлау өчен

Пар ат

(Өзек)

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.
Кич иде. Шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый;
Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый.
Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый;
Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам баскан йокы...
Бер тавыш килде колакка, яңгырады берзаман:
«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдыбызда бит Казан».
Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна;
«Әйдә чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на-на!»
Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан:
И Казан! дәртле Казан! моңлы Казан! нурлы Казан!..

Хәсән Туфан

Яз килә, яз

...Җылы җилнең өске катлавыннан
Сагыну тулган җырлар сибелә;
Кышларга дип киткән якларыннан
Кошлар кайта туган иленә...

Таллар әле яфрак ярмаганнар,
Шәрә әле тополь, каеннар.
Тик кичләрен сулап яз һавасын
Үтсәң әгәр шулар яныннан,

Сизелә сиңа:
Бар да хәрәкәттә,
Бар да яши, бар да тереләр.

Табигатьнең язгы яшьлек исе
Сибелә сиңа һәрбер бөредән.
Йөрәкләрне әллә нишләтә яз,
Өметләргә канат куела.
Син дә шулай, таллар, каеннар күк,
Яфрак ярасың күк тоела.

Сибгат Хәким

Туган җир

Туган җир, ахры, күңелемнән
 Кайчан да китмәс,
Ул хакта җырлап, сөйләп тә
 Сүзләрем бетмәс.

Утыра кырыйда ялгыз
 Җил тегермәне.
Күренә инде авылга
 Кәтү кергәне.

Ишетелеп куя таныш җыр:
 Дәрт белән тулган.
Кибәнпәр өстенә шәфәкъ
 Нурлары кунган.

Үткәнем күзгә хәзер дә
 Тутырып карый.
Монда бит сине кырдагы
 Һәр үлән таный.

Син ул — барасы юлыма
 Яктылык сипкән.
Өзелмәс җепләрем сиңа
 Бәйләнгән күптән.

ЭЧТӘЛЕК

ӘДӘБИ ТӨРЛӘРГӘ АНАЛИЗ ЯСАУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Кереш 3

5 НЧЕ СЫЙНЫФТА ӨЙРӘНГӘННӘРНЕ ИСКӘ ТӨШЕРҮ

Өлешләрне бөтен итүче сүзләр 7
Безнең безләр. *Шәүкәт Галиев* 7
Өлге. *Фәннур Сафин* 8
Зәйтүн җиргә бөгелгән. *Хәсән Туфан* 8
Бәйләнеш 9
Туган тел. *Габдулла Тукай* 10
Туган тел. *Хәсән Туфан* 13
Предмет. Сыйфат. Вакыйга 13
Кечкенә генә бер көйле хикәя. *Габдулла Тукай* 14
Карлыгач белән Чыпчык. (*Төрек халык әкияте*) 15
Бәхет. (*Әкият*) 17
Хикмәтле бүрек. (*Әкият*) 18
Мәгънә 20
Моржа. *(Мәсәл) Феликс Кривин* 21
Имән. *Муса Җәлил* 21
Җиз кыңгырау моңнары. *Әнгам Атнабаев* 24
Җиңәсем килде. *Марсель Галиев* 25
Ялганчы. *(Әкият) Ованес Туманян* 30

ТЕЗМӘ ТӨР ӘСӘРЛӘР ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Гөлчирә. *(Халык җыры)* 32
Кыр казы. *(Халык җыры)* 33
Кыш көннәре. *Дәрдемәнд* 35
Әй, җырлыйсы килә шушы җырны. *Һади Такташ* .. 35
Кайтып барыш. *Роберт Әхмәтҗанов* 38
Өзелмә. *Илдар Юзеев* 38
Тезмә әсәр өлешләрен бәйләүче чаралар 39
Сүзләрдәге авазлар охшашлыгы. Рифма 39
Бел. *Шәүкәт Галиев* 40

Кабатланулар тәртибе. **Ритм** 41
Туган ил. *Гадел Кутуй* 41
Туган ягым. *Равил Фәйзуллин* 43
Строфа 44
Тик булса иде ирек. *Муса Җәлил* 44
Ай һәм Кояш. *Габдулла Тукай* 45
Чишмә. *(Миф)* 46
Файдалы җиләк. *Шәүкәт Галиев* 47

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Әкият сюжеты 49
Акыллы Каюм бабай. *(Әкият)* 50
Шомбай. *(Әкият)* 51
Әдәби әсәр сюжеты 54
Хикәяне ничек язарга? *Һади Такташ* 55
Төнбоек. *(Хикәя) Нәбирә Гыйматдинова* 56
Аллы-гөлле күбәләк. *(Хикәя) Андрей Платонов* 58
Чәчмә әсәрләр эчтәлегендә хис 64
Әкият эчтәлегендәге хис 64
Коштай. *(Әкият)* 64
Хикәяләр эчтәлегендәге хис 67
Чатыр тау җиле. *Марсель Галиев* 67
Җиз кыңгырау. *(Хикәя-истәлек) Әмирхан Еники* 71
Тәүге соклану. *Габделхәй Сабитов* 78
Хикәя геройларының холкы 85
Ачылган йозак. *(Хикәя) Шамил Усманов* 85
Алсу чәчәк. *(Хикәя) Фәнис Яруллин* 91
Көтүчеләр. *(Хикәя) Галимҗан Ибраһимов* 100
Йөзек кашы. *(Повесть) Фатих Хөсни* 112

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Сүнгән йолдызлар. *Кәрим Тинчурин* 131
Әлдермештән Әлмәндәр. *Туфан Миңнуллин* 148

ЮМОРИСТИК ҺӘМ САТИРИК ӘСӘРЛӘР ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

Килешкән булып шуның капма-каршысын әйтү алымы 172
Озак яшәүнең сере. *Шәүкәт Галиев* 175
Юмор әсәрләрендә арттыру алымы 175
Өч аучы һәм бер балыкчы. *(Әкият)* 177
Баһадир. *Эрих Распе* 179
Артур һәм аның Гарри исемле аты турында. *Дональд Биссет* 180

Сәмигулла абзый. *Фатих Әмирхан* 182
Каршы якларның урыннарын алыштыру алымы ... 191
Диюләрне җиңгән. *(Әкият)* 191

БЕЛЕМЕБЕЗНЕ НЫГЫТУ ӨЧЕН КҮНЕГҮЛӘР

Күздән чәчрәгән ут. *Эрих Распе* 195
Чикерткә һәм Әкәм-төкәм. *(Әкият) Дональд Биссет* 196
Мыек борам. *Гамил Афзал* 198
Әбүгалисина. *Каюм Насыйри* 199
Сәер кеше. *Шәүкәт Галиев* 215
Язгы чәчәкләр. *Әхсән Баян* 216
Якынайган ераклык. *Фатих Кәрим* 218
Шәфәкъ чабуы. *Нәҗип Думави* 219
Өч Мати. *(Хикәя) Ференц Моро* 219
Парикмахер. *Мәхмүт Газизов* 223
Әйдәгез, өйдә укыйбыз! 224
Кышкы урман. *Гамил Афзал* 224
Чакматаш. *(Әкият) Ханс Кристиан Андерсен* 224
Ялкау, Иренчәк һәм Кире турында әкият. *Хәсән Туфан* 233
Эләкте. *Данис Хәбибуллин* 236
Сукыр лампа. *Шәрәф Мөдәррис* 237
Габдулла Тукай белән күрешүем. *Мөхәммәт Гали* .. 239
Имән. *Нәҗип Мадьяров* 242
Дәрестән соң. *(Хикәя) Әхәт Дибаев* 243
Алтын бабай. *Җәвад Тәрҗеманов* 248
Пар ат. *Габдулла Тукай* 251
Яз килә, яз. *Хәсән Туфан* 251
Туган җир. *Сибгат Хәким* 252

Учебное издание

Яхин Альберт Гатинович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник по татарской литературе
для 6 класса татарской средней
общеобразовательной школы

Третье, переработанное издание

Казань. Издательство «Магариф». 2006

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатинович

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
6 нчы сыйныфы өчен дәреслек

Яңадан эшләнгән өченче басма

Редакторы *З. М. Гыйниятова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Р. Ф. Мөбарәкҗанова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*
Корректорлары *Г. Г. Мөхәммәтҗанова, А. А. Дәүләтова,*
С. З. Гыймалетдинова, Р. Ә. Фәйзуллина

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 26.05.2006.
Форматы 60×90 $^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 16,0 + форз. 0,25.
Нәшер-хисап табагы 13,98 + форз. 0,39. Тиражы 4400 д.
Заказ К 6/128.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (843) 292-57-48.
http://magarif.kazan.ru
E-mail://magarif@mail.ru

ДУП «Полиграфия-нәшрият комбинаты».
420111. Казан, Бауман урамы, 19.

Хис дәрәҗәсе